# ШУРА

№35
2022



**2022 ел – Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы**

2000999960406

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Шөкер итеп яшик . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Рамазан аена әзерлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Раҗәб ае – Аллаһы Тәгалә бөекләгән ай . . . . . . . . . . . . 26
Зикер Аллаһыга якынаю юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Мөселман – һәрьяклап камиллеккә омтылучы кеше . . . . . . . 44
Пәйгамбәребезнең бөек сәяхәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Хәзрәти Хәдичә анабыз үрнәгендә . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Рамазан аен каршы алабыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Ни өчен вакытның бәрәкәте бетте? . . . . . . . . . . . . . . . 72
Намазда хошугълыкны саклау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Рамазан ае якынлаша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Өмме Руман радыяллаһу ганһә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98

ТАРИХ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Швециядә беренче татарлар: мөселман татар
җәмәгатьчелегенең барлыкка килүе . . . . . . . . . . . . . . . 113
Габделхәмид солтан сараенда: татар
укытучысының хатирәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Татар имамының Госманлы империясе ордены
белән бүләкләнүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119

МИРАС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123

«Мине кемнәр нәрсәгә өйрәттеләр?» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124

ФӘН . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Мәзһәбләргә иярмәүчеләрне кире кагу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

УРАЗА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Рамазан – кадерле кунак. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

ТӘРБИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Күркәм холык – җәннәткә илтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Идрис галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Коръән сүрәләренең мәгънәви тәрҗемәләре . . . . . . . . . . . . . . . 154

НӘСЫЙХӘТ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Үзен күңел төшенкелегендә дип уйлаучылар хакында . . . . . . . . . 179
Җәннәт рәвеше һәм җәннәт әһелләре бүлеге . . . . . . . . . . . . . . . 184
Адәм баласының биш сыйфаты. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 196

ӘДӘБИ СӘХИФӘ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199
Расүлебезнең тормышыннан сабак алырлык
гыйбрәтле кыйссалар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200

**«ШУРА» дини альманах, №35**

*гыйнвар–март 2022*
*җөмәдәл ахыр-шәгъбан 1443*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе иректә
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Ленар Хамматов

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 17.12.2021
Чыгу көне: 30.12.2021

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

______________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ❁ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ❁ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ❁

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ❁ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ❁ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ❁ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ❁ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ❁ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ❁

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ❁ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ❁ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ❁ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً❁ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ❁ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ❁ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ❁ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ❁ كَمَا

بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞
اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللَّهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وَهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

---

1 Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусҙмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыйҙү билләһи: ____________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________
______________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галлләәми, кәмәә каалəллаһу тәбәәракә вә тәгаалә филкәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мүʼминиинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә

вә Галийййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәйййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәйййидинәл Хәсәни вә сәйййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мүʼминиинә вәл мүʼминәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гааибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йәʼмүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[1] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары, элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

> **«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

---

1 3 тапкыр әйтелә.

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

> **«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

> **«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә

сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән,**

**[көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*14 нче гыйнвар вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Шөкер итеп яшик

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, безне акыл нигъмәте белән бүләкләп, барлык мәхлүкълардан өстен кылган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәгаләнең хәбибе һәм хак Расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Рухи яктан пакьләнеп, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Аллаһы Раббыбыз барчабызга Үзенең чиксез сәламен, рәхмәтен һәм бәрәкәтен насыйп итсә иде!

Ике гаеттән олуграк булган изге җомга бәйрәмебез барчабызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә иминлек, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфикъ-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен!

Билгеледер ки, һәр адәми зат үз исәнлеген үзе кайгыртырга тиеш. Белгәнебезчә, пакь су белән тәһарәтләнеп, һәркөнне башкарыла торган биш вакыт намаз – сәламәт булуның иң беренче чыганагыдыр. Хезмәт, шулай ук, кешегә көч һәм гүзәллек өсти. Туганнарың, күршеләрең белән аралашу – җанга тынычлык, күтәренке рух бирә.

Дөресен әйткәндә, соңгы елларда һәр җомга вәгазендә сүзләрне сәламәтлек хакында сөйләүдән башлау гадәткә керде кебек. Илебез буй-

лап йөргән аяусыз чирләр моңа этәргеч ясагандыр.

150 йорттан торган җыйнак кына авылыма, аның кешеләренә күз салам. Моннан якынча 77 ел элек 300-400 йорттан торган зур авыл кешеләре гөр килеп, тырышлык белән хезмәт куеп, тынычлыкта яшәгән. 139 авылдашым сугыш кырында ятып калса, исән-сау кайтканнары да инде мәрхүмнәр.

Авылда 90 яшен тутырган картлар бер-ике генә калса, 70 не узып, 80 яшькә таба атлаучылар җитәрлек әле. Шулар арасында тырышып хезмәт куеп, мәчеткә намазга йөреп, үз туганнарының сәламәтлеген саклау өчен бөтен мөмкинлекләрне файдаланучы ачык йөзле, киң күңелле картларыбыз бар. Әмма, кызганычка, 75 тулса да, мәчет юлын белмәүче, өйдә генә мәш килеп хәрәкәт итүче адәми затларны да күрергә була шул. Андый бәндәләргә ничек кенә дәгъват кылсаң да, үзләрен авыруга санап йә булмаса харам сулар кулланып, өйдә генә ятарга тырышуларын әйтми булмастыр.

Бу – Аллаһы коллары сәламәтлеккә илтә торган юлларны үзләре үк өзә баралар. Андый адәмнәр: «Без инде картайган, өйрәнергә соң инде» – дип, үзләрен аклап куялар.

Ләкин чын күңелдән Аллаһы Тәгаләне мактап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлламнең хәдисләрен өйрәнеп мәчеткә йөрүчеләр арткannan арта баруына шатмын. Ул гына да түгел 50-60 яшьтәге ханымнарыбыз мәчеткә йөреп намаз, Коръән, догалар укырга өйрәнәләр. Аллаһы Раббыбыз тел ачкычлары насыйп әйләсен.

Әмма «Бөртек кылчыксыз булмый», дигән кебек, арада имамнан риза булмаучылар да табыла. Мәсәлән, 30 яшьлек имам җомга вәгазе сөйли. Көнчелек, мин-минлек һәр адәмнең күңел төбендә ята. Кайбер чакта түзмичә сикереп чыга һәм белер-белмәс имамга каршы: «Син дөрес әйтмәдең. Кем син шундый? Юк, алай түгел ул», – дип, үз сүзен тәкърарлый башлый. Сүзе дөрес булмаса да, хәзрәтнең: «Каян укыдыгыз

мондый фетнәләрне?» – дигән соравына: «Яшел китаптан, яшел китаптан», – дип җавап бирә. Авторын да белми, нәшер итүчесен дә.

Ирексездән Хуҗа Насретдин мәзәге искә төшә. Берәү: «Әссәләмү галәйкүм, мулла абзый!» – дип сәлам биргән. Мулла йөгереп кенә өенә кергән дә «яшел китап» алып чыккан һәм аннан укып: «Вә галәйкүм әссәләм», – дип җавап биргән, имеш. Бу мәзәк мулланың наданлыгын тасвирласа, теге агай үз томаналыгын ачып бирә. Менә шулай итеп, үзеннән 30-35 яшькә яшьрәк мулланың акыл өйрәтеп ятуын күтәрә алмаучы күнче бәндәләр үзләренең генә түгел, тирә-яктагыларның, бигрәк тә имамның сәламәтлегенә зыян салалар. Күп авылларда (бигрәк тә татар авылларын күз алдында тотып) гомер-гомергә яшәп килгән гади гореф-гадәтләр, йолалар бар. Егет кеше өйләнә, улы туып, үсеп, мәктәп тәмамлый, армия сафларында хезмәт итеп кайта, тормыш кора, балалар үстерә. Бабайларыбыз яшәгән чорда кеше гомере 50-60 яшь була. Шул чор эчендә ул барын да башкарып чыга. Ул чорда сәламәт яшәү рәвеше алып барганга күрә, кешеләр авыр хезмәтне дә башкарган, шуңа да карамастан, сәламәт тә булган. Мәсәлән, бәрәңгене генә алыйк. Бернинди бөҗәксез, дарусыз үскән бәрәңге ашалган. Дару сибелмәгән кырларда йөргән сыерның тәмле сөте, каймагы, мае ашалган. Тегермәне, чиста оннан пешкән мич ипие, кабартмасы. Бернинди кушылмалар салынмаган казылыгы, тутырмасы – менә болар бар да сәламәтлек өчен кирәк булган ризыклар.

Ә бүген без ашаган ризыкларны үзебез үк күреп торабыз. Нәрсә генә ясалса да, матурайту, күбәйтү өчен төрле кушылмалар өстәлә. Бигрәк тә шәһәр кешеләре бу ризыкларны күп кулланыла. Яшерен батырын түгел, күп кенә шәһәр кешеләре, авылга кайтып, йомырка, ит, май, каймак һ.б. нәрсәләр сатып алып китәләр. Бу – Аллаһы биргән ризыклар. Шулай итеп үзләренең сәламәтлекләрен сакларга тырышалар. Ни әйтсәң дә, берни кушылмаган чиста ризыкка ни җитә?!

Дөрес, яшереп булмый, моннан бер гасыр элек кеше гомере озын булмаган дигән идек. Элегрәк, бәлки, тагын да аз булгандыр. Ашау яхшы, чиста, әмма авыр хезмәт бар: җир сөрү, чәчү, өй артындагы 25 сотый бакчаны көрәк белән казу. Сыерыңны, атыңны кыш чыгару өчен берәр гектар кул чалгысы белән печән чабу, урманнан агачлар ташып, утын әзерләү планга кертелгән. Янә бик күп эшләр. Хатын-кызына да эш җитәрлек. Иртүк чиләк-көянтә асып чишмәгә бару, инештән терлекләргә су ташу, көл селтесе белән керләр юу (ул вакытта порошок булмаган), камыр изеп мич тулы ипи пешерү, гел хәрәкәттә булу, чиста ризык ашау – исәнлеккә зур файда ясаган. Хәләл эш – хәләл ризык. Әмма берни эшләп тә булмый, ул чорда кеше гомере бары тик 50 тирәсендә генә иде. Чыннан да, ул чорда кеше гомеренең кыска булуы гаҗәпләндерә.

Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасын искә төшерик: Бәдри – Галиябануның әтисе, 40 яшьлек ак сакаллы карт. Бу әсәрне укып, авылдагы хәзерге 40 яшьтәге ир-атларга күз салсак, аларның кайберләре хәтта өйләнмәгән дә, буйдак булып йөриләр. Кая монда аксакал?! Алар түгел, әле сиксән яшьлеге дә сакал үстерми, тыныч кына яши бирә. Ә нигә яшәмәскә ди?

Бакчаны трактор сөрә, печәнне машинадан тәгәрәтеп кенә төшерәләр. Утынны (мунча өчен) кискән, ярган килеш китереп бирәләр. Өй эчендә су, тәһарәтханә, кер юу машинасы, газ янып тора. Кул белән эшли торган бер генә эш калмаган. Хәрәкәт юк! Ашарга, эчәргә муллан, әмма исәнлек нигәдер чигенә бара. Кеше учлап даруын каба-каба һаман яшәүне дәвам итә. Якты дөньядан кем туйган? Безгә бары тик Аллаһы Раббыбызга шөкер кылып, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар әйтү, хәдисләрен өйрәнү кирәк. Биш вакыт намазны калдырмыйча мәчеткә йөрергә, ярдәмгә мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга, туганнарың, күршеләрең белән дус тату яшәргә тиешбез. Галәмнәребезнең Хуҗасы булган Аллаһы Тәгалә бүләк иткән гомеребез-

не исраф итмичә яшәсәк иде. Көн саен мәчеткә өйлә намазына йөрибез. Шулчак кайберәүләр: «Бүген төнлә йоклап булмады әле», – дип зарлана. Сәбәбен белсәк тә, елмаеп сорап куям: «Көндез дә черем итеп алмагансыздыр инде?» «Алдым», – ди теге кардәш. «Өйләгә чаклы бер сәгать, өйләдән соң ике сәгать черем иттем», – ди. «Соң, – мин әйтәм – нормаң тулган бит. Төнлә йокларга йокың калмаган», – дим. Шуңа күрә көндез саф һавада йөрергә, туганнарның хәлен белешергә, яшьләр белән аралашырга, иң кирәкле галимнәребезнең, остазларыбызның китапларын укырга, тирән белем бирә торган «Шура» журналын укып чыгарга кирәк. Белемле кешенең йокысы да тирән була ул.

Төнлә йоклый ала икән, димәк, ул көнен бушка уздырмаган.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә риза булырлык хезмәт башкарырга насыйп әйләсен, чөнки сәламәт булу – бары тик үзебездән тора. Аллаһы кушканча дөрес яшәп, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә ияреп, тормышыбызны киләчәк буынга җиткерик. Әәмин!

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәнис хәзрәт Низамов,*

*Аксубай районы,*

*Яңа Дума авылы имам-хатыйбы*

*21 нче гыйнвар вәгазе,*
*җөмәдәл-ахыр аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Рамазан аена әзерлек

Галәмнәрне юктан бар итеп, аларны Үзенең хикмәте белән тәрбияләп торучы, безне шушы дөньяга төрле сынаулар белән сыналыр өчен җибәргән Аллаһы Тәгаләгә дан-мактауларыбыз булса иде. Шул сынауларны дөрес итеп үтәргә өйрәтер өчен җибәрелгән, мөэминнәрне җәннәт белән сөендергән, имансыз һәм монафикъларны җәһәннәм белән кисәткән хак расүл – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Җәмәгать, менә Рамазан-шәриф ае башланырга да өч ай калды. Һәрберебез дә белә: әгәр дә берәр җиһазны, автомобильне яки берәр самолетны берәр завод, җитештерә торган оешма ясаган икән, аларга билгеле бер график куела: мәсәлән, күпмедер вакыт очканнан соң, самолетны тикшертергә кирәк, чөнки билгеле бер вакыттан соң, аның очуы һәм имин булуvы шик астында кала. Һәрберегез дә белә: яңа автомобиль аласыз икән, анда: «Шуның кадәр чакрым үткәннән соң, машинагыз сервиска керергә, белгечләргә күрсәтелергә тиеш», – дип язылган була. Җәмәгать, әгәр боларны үтәмәсәк, машинабызда имин халәттә йөрүебезне дәвам итеп булмас. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә адәм баласын бу дөньяга ашауэчү, йоклау, йорт салып яшәү өчен генә яратмаган. Раббыбыз Ахирәт алдыннан безгә берничә дистә ел вакыт бирә, безнең җәннәтле булуыбызны тели. Безнең бу дөньядагы төп максатыбыз турында Коръәндә болай дип әйтелгән:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Унбер ай буена кеше рухи яктан, тән (физиологик яктан), гыйлем ягыннан, ихласлыгы ягыннан туза. Төрле очраклар булырга мөмкин: бәхәсләшеп тә алу, гайбәткә дә керү, ялган да... Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә шуңа күрә безгә төзәлергә, яңарырга, пакьләнергә, тәнне сәламәтләндерергә, акылны ачырга, гыйлемне арттырып, калебне пакьләп, киләсе унбер айда да рухи көч, гыйлем белән тагын бер башка күтәрелү өчен, Рамазан аен җибәргән.

Ничек уйлыйсыз, җәмәгать: без быелгы Рамазан аена әзерме? Кемдер бу Рамазан аенда беренче тапкыр ураза тотачак, кемдер инде биш елдан артык, кемдер ун елдан артык ураза тота. Тыйб (медицина) ягыннан карасак, без бүгеннән үк Рамазан аена әзерләнергә тиеш. Бездә: «Ничек әзерләнергә соң?» дигән сорау туарга мөмкин. Мәсәлән, бүгенге көннән башлап, үзебезнең ашау ягын үзгәртергә тиешбез: аз ашарга, камыр ризыкларын сирәгрәк кабарга, өстәлләребездә хөрмә, яшелчә һәм җимешләр күбрәк булырга тиеш. Шулай ук, табиблар янына барып, организмыбыз өчен авырлыклар килеп тумасын өчен, алдан ук тикшеренеп куюыбыз хәерле.

Тиздән раҗәб ае башлана һәм менә шушы раҗәб аеннан башлап, без нәфел уразаларын тота алабыз. Һәм шулай ук һәр атна саен пәйгамбәребез Мөхәммад Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте буенча, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә дә нәфел уразаларын тота алабыз. Әгәр дә без атнага ике көн нәфел уразасын тотсак, иншәАллаһ, аннары Рамазан аенда 30 көн ураза тоту җиңел булыр, чөнки безнең организмыбыз ураза тотарга ияләшкән була. Шуңа күрә: «Тән ягыннан (физиологик яктан) Рамазан аена ничек әзерләнергә?» – дигән сорауга җавап шундый була: аз ашауга ияләшү һәм нәфел уразаларын тоту.

Шулай ук тән ягыннан гына түгел, Рамазан аена рухи яктан да әзерләнергә тиешбез. Һәм иң беренчесе – ул Коръәни Кәримне ешрак уку, ә укый белмәгәннәргә – укырга өйрәнү. Ни өчен Рамазан аенда Коръәнгә шундый игътибар бирелә? Бу сорауга Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә Үзе җавап бирә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ

**«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Аллаһының Расүле, сәхабәләр һәм алардан соң килгән мөселманнар да Рамазан аеның кичләрен Коръән укып үткәрергә тырышалар иде. Ә без – хәзерге мөселманнар, күбрәк социаль челтәрләрдә утырырга тырышабыз, ә Коръәни Кәримне ачмыйбыз да: ул безнең киштәләребездә тузан җыеп ята. Бу бик начар хәл, җәмәгать. Без Аллаһы каршында зур дәрәҗәләргә ирешергә хыялланабыз, әмма Аллаһының Кәламен – Коръәни Кәримне укымыйбыз. Уйлап карыйк, җәмәгател-мөслимин, Коръәнне укуның күпме фәзыйләтләре бар икән? Шуларны карап үтик.

Беренчесе: Коръәннең һәр хәрефе өчен әҗер булыр. Пәйгамбәребез үзенең бер күркәм хәдисендә болай дип әйткән: «Кем Аллаһының китабыннан бер хәреф укыса, аңа бер изгелек язылыр. Ә бу изгелек тагы ун тапкырга арттырылыр. Мин «Әлиф Ләм Мим бер хәреф дип әйтмим, әмма «Әлиф» – ул бер хәреф, «Ләм» – ул бер хәреф, «Мим» – ул бер хәреф»[1]. Уйлап карыйк, җәмәгать, Коръәндәге бер хәреф укыган өчен Аллаһы Тәгалә безгә ун изгелек яза. Сөбеханәллаһ! Әгәр Кадер кичәсендә укысак, 10 ны

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

1000 гә тапкырлаган кадәр савап языла, иншәАллаһ.

Икенчесе: Коръән укучы янында фәрештәләр булыр. Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Коръәнне оста укучы белән илче фәрештәләр булыр. Ә кем инде Коръәнне тотлыгып, авырлык белән укыса, аңа ике әҗер булачак»[1].

Өченчесе: Коръән укучысына шәфәгатьче булыр. Пәйгамбәребез: «Коръәнне укыгыз, чөнки Кыямәт көнендә ул укучыларына шәфәгатьче булыр»[2], – дип әйткән.

Шуңа күрә без Коръәнне Рамазан аенда гына түгел, һәркөнне дә укырга тиешбез. Иң кимендә, бер-ике бит укуны барыбыз да булдыра ала. Әгәр дә бүгенге көннән башлап, Коръәнне һәр көн укысак, Рамазан аенда без аны тулысынча укып бетерербез (хәтем кылырбыз). Әгәр дә берәрегез Коръәнне укый белмәсә – өйрәнә аласыз, чөнки хәзерге вакытта Коръәнне укырга өйрәнү мөмкинлекләре бик күп. Шуңа күрә, җәмәгать, Рамазан аена әзерләник, күп вакыт калмады, әгәр дә хәзер үк әзерләнә башламасак, аннары авыр булырга мөмкин.

Аллаһы Тәгалә шушы сөйләгәннәребез белән гамәл кылырга язсын. Әәмин!

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып

---

1 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Айназ хәзрәт Зарипов,*

*«Габдерәхим Утыз Имәни» мәчете имамы*

*28 нче гыйнвар вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Раҗәб ае – Аллаһы Тәгалә бөекләгән ай

Барча галәмнәрнең Раббысы, Тәрбиячесе, Яратучысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез ирешсен. Шулай ук йөрәкләребезнең иң нечкә җирләреннән шытып чыккан салават-шәрифәләребез юлбашчыбыз, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирешсен. Хөрмәтле мөселманнар, шушы изге җомга көне белән сезне тәбрик итәм. Аллаһы Тәгалә барчабызга да күңелләребездәге изге ният, морад-максатларыбызга ирешергә, күңелләребездә булган барча начар сыйфатларыбыздан арынырга насыйп итсен. Безләрнең бүгенге көнебезне кичәгеләреннән, иртәгесе көннәребезне бүгенгесеннән хәерлерәк кылса иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бүгенге мәүгыйзәбез – «Раҗәб ае – Аллаһы Тәгалә бөекләгән ай» дип атала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләре бер хәдистә: «Раҗәб — Аллаһының ае, шәгъбан — минем аем, ә Рамазан — өммәтемнең ае», – дип әйткән. Берәү Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Йә, Расүлуллаһ, ни өчен раҗәб Аллаһы ае соң ул?» — дип сораган. Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу айда чын күңелдән тәүбә итүчеләргә Аллаһы Тәгаләнең мәгъфирәте иңә, бу айда сугышлар тыелган, бу айда Аллаһы Тәгалә бөтен пәйгамбәрләрнең догаларын кабул кылган һәм күп кенә әүлияләрне (изгеләрне) дошман кулларыннан коткарган», – дип аңлаткан. Раҗәб аенда кылган изге гамәл-гыйбадәтләр өчен Аллаһы Раббыбыз савапларны арттырып бирә, шул сәбәпле, изгелекләрне күбрәк

кылу бик тә әһәмиятледер. Бу форсатны кулланган кешеләр – уңыш казанучылар һәм чын алыш-биреш кыйммәтенә төшенүчеләр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләре раҗәб аеның беренче җомгасына каршы булган кичтә уяу булырга киңәш иткән. Фәрештәләр аны Рәгаиб кичәсе дип атаганнар. Күп гасырлар дәвамында мөселманнар бу кичәгә зур әһәмият бирәләр. Әлеге кичәдә догалар кабул була. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче бер хәдисендә болай дип әйткән: «Биш кичәдә Аллаһы Тәгалә Үз колларының үтенечләрен кабул кылыр: Рәгаиб, Бәраәт, Җомга киче, Рамазан һәм Корбан гаетенә каршы кичәләр». Ошбу кичәләр белән бүләкләнгән ай гади буламы? Догалары кабул кылыначак кеше бәхет ачкычы тоткан кешедәй түгелме, кардәшләрем?

Бу кичәләрдә мөселманнар Раббылары һәм тормышлары турында уйланалар, фикер йөртәләр, Коръәнне күп итеп укыйлар, догалар кылалар. Аллаһы Тәгалә безгә гөнаһлардан пакьләнергә, изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә зур мөмкинлекләр бирә. Без шушы фазыйләтләргә игътибарлырак булырга, аларны шатланып, сөенеп каршы алырга тиешбез.

Нинди көн соң ул Рәгаиб кичәсе? Бу — сөекле Пәйгамбәребезнең әтисе хәзрәти Габдулла белән әнисе Вәһеб кызы хәзрәти Әминәнең никахлашкан көннәре. Әле ул гына түгел, раҗәб ае тагын бер мөбарәк кичә белән бизәкләнгән – ул Мигъраҗ кичәсе. Мигъраҗ кичәсе раҗәб аеның 26 нчы көненнән 27сенә каршы кичтә була.

Әйе, ошбу изге вакыйга да раҗәб аенда була. Моңа дәлил Коръәннең әлеге аятендә китерелә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

**«Аятьләребездән кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне [бик кыска бер вакытта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм колын Харам мәчетеннән [алып] Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әкъса мәчетенә күчерүче [булган Аллаһы ниндидер бер урында булудан һәм бөек Затына килешми торган төрле түбән сыйфатлардан ерак һәм бөтен] кимчелекләрдән пакь. Һичшиксез, Ул – [һәрнәрсәне] Ишетүче, Күрүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1

Нәтиҗә булып, ошбу кичәдә:

– биш вакыт намаз фарыз кылына;

– «Әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы аятьләре иңә (285-286 нчы аятьләр);

– Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Кыямәт көнендә өммәтен яклау хокукы бирелә, ягъни Пәйгамбәребез Кыямәт көнендә гөнаһлы мөселманнар өчен Аллаһы каршында шәфәгать итәчәк.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Ошбу олы фазыйләтләре булган айдан да файда алып, Аллаһының ризалыгына ирешергә омтылмасак, гафилләрдән булуыбыз ихтимал.

Аллаһы Раббыбыз ошбу вәгазьләребездән разый булсын. Аларны файдаланырга, күңелләребездәге барча начар сыйфатлардан арынырга насыйп әйләсен. Чын мәгънәсендә мөселман кешесе булып яшәргә, вә чын мәгънәсендә мөселман кешесе булып Аллаһы Раббыбыз хозурына күчәргә насыйп итсен. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*

*ТР МДНнең «Зәкят» хәйрия фонды хезмәткәре*

*4 нче февраль вәгазе,*

*раҗәб аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Рәгаиб кичәсен искә алып

Галәмнәрнең Раббысы булган, мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкераналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават, сәламнәр әйтәбез.

Әссәләмү галәйкүм хөрмәтле мөселман дин кардәшләрем! Көннәрнең иң хәерлесе булган җомга көне һәрбарчабызга мөбарәк булсын. Җомга көненең фазыйләтләренә, вәгъдә ителгән әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсен. Изге булган раҗәб ае мөбарәк булсын. Рәгаиб кичәсендә кылган догаларыбыз, теләк-максатларыбыз кабул булсын. Рәгаиб кичәсе – ул изге раҗәб аеның беренче җомгасына каршы булган мөбарәк кичә. Бу кичә Аллаһының Расүле – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе хәзрәти Габдулла белән әнисе хәзрәти Әминәнең никахы булып, тәүге тапкыр кавышкан көне дип әйтелә. Пәйгамбәребез үзе үк бу төн турында болай дип әйткән: «Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы төнне ваемсызлыкта үткәрмәгез, чөнки бу төнгә фәрештәләр Рәгаиб дип исем кушканнар». «Рәгаиб» сүзе гәрәпчәдән – «теләкләр», «өметләр» дип тәрҗемә ителә. Шуңа күрә аны «теләкләр, догалар кичәсе» дип тә атап булыр иде. Гомумән, һәрвакыт күңелдә яхшы теләкләр, ниятләр һәм өметләр белән яшәү мөселман кешесенең әхлагы булып тора. Һәм шушы максатларыбызны Аллаһы Тәгаләдән сорап, аларга омтылып яшәү кешене яхшылык, изгелек юлыннан алып бара.

Рәгаиб кичәсен искә алу безнең өчен Пәйгамбәребез белән бәйле булганы өчен дә бик якын, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең өчен олы үрнәк иясе булып тора. Аның белән бәйле булган

вакыйгаларны искә алып, без дөньябыз һәм Ахирәтебез өчен зур файдалар алабыз. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе хәзрәти Габдулла белән әнисе хәзрәти Әминәнең кавышып гаилә коруы һәм шуның сәбәбендә Пәйгамбәребезнең дөньяга килүе – гаиләнең, ир һәм хатын булуның, гаилә җимешләре – балаларның булуы, Аллаһы Тәгаләнең безгә карата рәхмәте һәм тормыш кануны икәнен аңлата. Җиһанда һәрбер әйбернең парлы булып яратылуында, аларның берберсен тулыландырып, парлы булуында күп файдалар һәм тормыш рәхәте ачыла. Бәндәнең дә парлы булып, бер-берсенә ярдәмче, терәк, бер гаилә булып яшәве сәбәбендә, аңа тормышның күп кенә нигъмәтләрен күрү, аларга ирешү насыйп була, Ахирәттә аның дәрәҗәләре арта.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُمْ مِنْ أَنْفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُمْ مَوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ

**«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яратуы һәм арагызда сөю [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] белән бер шәфкать [чарасы булган бала] бирүе дә – Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:21

هُنَّ لِبَاسٌ لَكُمْ وَأَنْتُمْ لِبَاسٌ لَهُنَّ ۗ

**«Алар – сезгә кием һәм сез – аларга кием».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:187

Бу аятьләрдән аңлашылганча, ир белән хатынның бер гаилә булып никахлашып яшәве – Аллаһы Тәгаләнең кануны. Ир һәм хатын, ата һәм ана, бала, әби һәм бабай булу бәхете һәм гаилә бәхете – барысы да Аллаһы

Тәгаләнең бәндәләргә бу дөньялыкта биргән нигъмәтләреннәндер. Ошбу канунны бозып башка төрле яшәү рәвеше булдырырга тырышу, кеше өчен, җәмгыять өчен бик зыянлы һәм һәлакәткә илтә, бу очракта кеше үзе теләп, Аллаһының рәхмәтеннән ваз кичә. Кеше дөньялыгында да, Ахирәтендә дә бәхетсез була. Шушы рухи кыйммәтләрне саклау һәм аларны үстерү, аларга чакыру динебезнең бер максаты булып тора. Хәзерге вакытта да бу мәсьәлә бик актуаль булып кала. Динебезгә, халкыбызга хас булмаган, гаилә кыйммәтләрен җимерә торган, ата-ана төшенчәсен түбәнсетә торган ялган кыйммәтләр турында ишетергә, шундый яшәү рәвешен алга сөрүне очратырга туры килә. Безгә, үз чиратыбызда, динебез кушкан рухи гаилә кыйммәтләрен саклауда үз өлешебезне кертү тиешле буладыр. Дөньяда иң зур бәхетнең берсе – матур парлы гаилә булып, тормыш алып бару. «Җир йөзендә сездән бәхетлерәк кеше һич булмас», – дип Мөтәвәккил хәлифәгә кемдер әйткәч, ул җавап итеп: «Хата сөйлисез, яхшы йорты, изге хатыны һәм дә яхшы тормышы булган кеше бездән күп тапкыр бәхетледер», – дигән.

Шулай ук, аңларга кирәк: гаилә коргач, ул гаиләне саклау да мөһим, чөнки, никах – ул Аллаһы Тәгалә каршында сүз, ант биреп килешү төзү. Һәм бу килешүгә игътибарлы булу, аны саклау ошбу килешүне төзүчеләрнең бурычы. Белгәнебезчә, килешүне бозу – олы гөнаһлардан. Шуңа күрә аерылырга бер сәбәп эзләгәнче, гаиләне саклауның мең юлын эзләү тиеш була. Аерылып, яхшырак тормыш башлыйм дип әйтү күп очракта шәйтан коткысыдыр. Булганны саклап, аның рәхәтен күрү күпкә яхшырак. Шулай ук, гаилә бозылуы, күп очракта ике якны да күп кенә гөнаһларга этәрә, үз чиратында, гөнаһка илтә торган әйбер үзе дә гөнаһ була.

Берәү, хатыныннан зарланырга дип, хәлифә Гомәр радыяллаһу ганһе янына барган. Килеп житсә, хатыны Гомәр радыяллаһу ганһене пыр туздырып әрләп маташа, ә ул дәшми генә тыңлап тора икән. «Моның хәле минекеннән мөшкел икән», – дип, теге кеше кире борылып киткән. Гомәр

радыяллаһу ганһе аның артыннан куып җитеп: «Ни йомыш иде?» – дип сораган. «Хатынның холкыннан зарланып килгән идем, синең хәл дә мактанырлык түгел икән, ничек сабыр итәсең?» – дип сораган теге кеше.

Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе: «Хатыным мине зинадан саклый, ашарга әзерли, киемнәремне юа, өйне тәртиптә тота, балаларымны тәрбияли. Ничек инде мин аннан риза булмыйм?! Аллаһы Тәгалә хатын-кызга акылны ирләргә караганда кимрәк, хисне артыграк биргән. Җавап кайтарсам, аңа караганда да акылсызрак булам бит», – дип җавап биргән.

Тормышта төрле вакыт була, әмма мөселман бәндәсе иманлы, тәүфыйклы, акыллы һәм сабыр булып калырга тиеш.

«Хатынымны яратмыйм, шуның өчен талак кылам», – дип әйтүче кешене хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе: «Хатыныңны яратмасаң да, син килешүне сакларга һәм үтәргә тиеш түгелме? Юкса, дөньяда булган өйләрнең эчләре мәхәббәт белән тулганмы әллә?!» – дип җавап биргән.

Гаиләбез, хатыннар, балалар турында кайгырту, аларга шәфкатьле һәм мәрхәмәтле булу турында хәдис-шәрифләр санап бетергесез дәрәҗәдә күптер. Гаилә төзек булсын өчен һәр кешенең үз урыны булу шарттыр. Табигатьтә, җиһанда һәрбер әйбер үз урынында булган өчен тормышыбыз рәхәт, матур була. Гаиләдә дә шулай ук. Шушы урында Гәбделхәбир хәзрәт Яруллинның ир һәм хатын вазифалары турында әйтелгән сүзләрен җиткерәсем килә: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Бурычларга килсәк, хатын-кызның ике төп бурычы бар: Беренчедән, ул гаиләдәге җитәкченең акыллы киңәшчесе. Өйдә җитәкче – ир кеше һәм соңгы сүзне ул әйтергә тиеш. Хатын-кыз моны аңласа, әйтә алмый торган йомшак ир кешедән дә нык фикерле җитәкче ясый ала. Әгәр тели икән, ул моңа ирешә ала, юк икән, «Үзем эшлим, үзем башкарам», – дип, ир өстеннән таптап чыгып китә. Мондый гаиләнең таркалуын көт тә тор инде. Кечкенә генә бу сәясәтне хатын-кыз аңларга тиеш.

Хатын-кызның икенче бурычы: балаларына хәерле ана булу. Ул боларны үти алдымы, аңа башка зур таләпләр куярга, вак-төяккә бәйләнергә кирәкми.

Ә ир кешенең бурычы күбрәк. Югарыда әйткәнебезчә, ул гаиләдә җитәкче. Һәр җитәкченең төп вазифасы – үзенең хуҗалыгын саклау һәм үстерү. Димәк, ир кеше гаиләне саклау һәм үстерү турында уйларга тиеш, шулай ук хатын аш-су бүлмәсендә генә калмасын, укысын, гыйлем эстәсен, кирәк тапса, эшләсен. Балалар тәртипле, әдәпле, дини яктан иманлы булып үссен өчен, нигездә, ана җаваплы».

Аллаһы Раббыбыз безгә бәхетле, саф, матур тормыш итәргә боера. Гаилә кешегә бу мөмкинлекләрне бирә. Бәхетле гаилә – җирдә җәннәтнең чагылышы булып тора. Аллаһы Раббыбыз һәркайсыбызга хәерле гомерләр биреп, никахлы җәмәгатьләребез белән тигезлектә, татулыкта, саулык-сәламәтлек, өлфәт-мәхәббәт белән, бер-беребезгә терәк-таяныч булып, әти-әниләребезнең догасын алырлык итеп, балаларыбызның кайгы-хәсрәтен күрмичә гомер итәргә насыйп кылсын.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*

*«Динислам» мәчете имам-хатыйбы*

*11 нче февраль вәгазе,*

*раҗәб аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Зикер Аллаһыга якынаю юлы

«Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бер аятьтә болай дип әйтә:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ وَلَئِن كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ ﴿٧﴾

**«Раббыгыз: «Әгәр [иман китереп, изге гамәлләр кылып, Минем сезне дошманнарыгыздан коткару нигъмәтемә] шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә [нигъмәтләрне тагын да] арттырачакмын. Әгәр [динемне инкяр итеп, моның кадәр нигъмәтләремә карата] рәхмәтле булмасагыз, һичшиксез, Минем газабым бик каты», – дип игълан итте [һәм бернинди шиккә дә урын калдырмады]».**

«Ибраһим», 14:7

Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән: «Йә, Раббым, мин ничек итеп Сине зикер кылыйм?» – дип сорагач, Аллаһы Тәгалә аңа җавап итеп: «Синең зикер кылуың – Миңа шөкер итүең», – диде. Моннан шуны аңларга була: шөкер белән зикер бер-берсе белән нык бәйләнгән, зикер кылмаган бәндә шөкерсездер, ә шөкерсез бәндә зикерсездер, чөнки зикер – ул Аллаһы Тәгаләне искә төшерү булса, шөкер – Аллаһының нигъмәтләрен искә төшереп, Аңа рәхмәт әйтү.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә зикернең никадәр мөһим булуын ассызыклаган. Әбү Әд-Дәрда болай дип риваять итә: «Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Сезне иң хәерле гамәлгә өндимме? Раббыгыз каршында иң зәки (чиста, пакь) булган, дәрәҗәләрегезне күтәрә торган, Аллаһы юлында мал сарыф итүдән, алтын вә көмеш инфак[1] итүдән, тырышлык кылудан да хәерлерәк гамәлгә өндимме?» Шулвакытта сәхабәләр: «Әлбәттә әйт, ий Аллаһы Расүле!» – дип әйттеләр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһыны зикер кылу», – диде»[2].

Зикер – ул гыйбадәт. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөнья ләгънәт кылынган һәм дөньяда булган һәрнәрсә ләгънәт кылынган, өч нәрсәдән кала: зикер кылу, гыйлем алу һәм гыйлем бирү»[3], – дип әйткән. Шуңа күрә без зикергә, гыйлем алуга һәм гыйлем бирүгә игътибарыбызны юнәлтмибез икән, дөнья белән бәйләнгән һәр эшебез ләгънәт астында булырга мөмкин. Без шәригать гыйлемен алырга, зикер белән шушы гыйлемебезне калебтә ныгытуда тырышырга тиешле. Әгәр кеше шушы өч гыйбадәтне үтәсә, дөнья белән бәйле булган хәерле-изге эше ләгънәттә булмас, бәлки мәрхәмәттә булыр.

Аллаһы Тәгаләгә шөкер әйтеп, зикердә булу хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләренә сөйләгән кыйссасыннан беләбез. Расүлебез болай дип бәян иткән: «Исраил угылларының кавемендә өч кеше яшәгән, алар авыру булган. Берсе тән авыртуы (проказа) белән интеккән, икенчесе сукыр булган, ә өченчесенең башында чәче үсмәгән. Көннәрдән бер көнне алар бер-берсенә сүз катканнар. Тән чире белән авырган кеше: «Тән авыруым кайчан бетәр? Тәнем бигрәк ямьсез», – дигән. Чәче булмаган кеше: «Кайчан чәчем үсәр? Кеше миннән

1 Инфак – бүлеп бирү.

2 Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имамнар Әт-Тирмизи, Ибне Мәҗе, Әл-Бәйһакый хәдисләр җыентыгыннан.

көлә, мәсхәрә итә. Моңа түзеп булмый», – дип зарланган. Ә сукыры бер сүз дә дәшмәгән. Һәм болар аптырашып, сукырдан: «Син күзеңнең күрүен теләмисеңме әллә?» – дип сораганнар. Сукыр: «Иң мөһиме маңгай күзе түгел, ә Аллаһы Тәгалә минем күңел күзен алмавын телим, монысы иң хәерлесе, ә инде Аллаһы теләсә, маңгай күзе дә кайтыр», – дип җавап биргән. Бераз вакыт узгач, Аллаһы Тәгалә өчесенә дә кеше сурәтендә фәрештә җибәргән. Фәрештә иң әүвәл тән авыруы белән интеккән кеше янына килгән дә: «Әссәләмү галәйкүм!» – дип, сәлам биргән. Бу кеше, сәламгә җавап кайтармыйча: «Сиңа нәрсә кирәк?» – дигән. Фәрештә моңа: «Башта сәламгә җавап бир!» – дигәч, бу кеше: «Әйе, вә галәйкүм әссәләм! Нәрсә кирәк?» – дип, тупас кына җавап кайтарган. Фәрештә: «Мин сиңа ярдәм итәргә килдем, авырганыңны белдем», – дип әйткән. Авыру кеше: «Әйе шул, мин тән авыруы белән авырыйм, әгәр дә минем авыруым төзәлеп, тәнем матурайса, сәламәтләнеп китсәм, яхшы булыр иде», – дигән. Фәрештә кулы белән аның тәнен сыпыргач, бу кеше сәламәтләнеп, тәне матурайган. Шуннан соң фәрештә: «Тагын нәрсә телисең? Бәлки малдан берәр нәрсә телисеңдер?» – дип сораган. Ул: «Әйе, миңа бер дөя бирсәң, шушы дөядән күпсанлы дөяләр туар, миндә дөя көтүе булыр һәм баеп китәрмен», – дип әйткән. Шуннан фәрештә Аллаһының әмере белән моңа дөя биреп, китеп барган.

Аннан соң фәрештә чәче коелып, пеләш калган кеше янына килгән. Аңа да: «Әссәләмү галәйкүм!» – дип сәлам биргән. Бу кеше дә, тегесе кебек үк, сәламгә җавап кайтармыйча: «Сиңа нәрсә кирәк?» – дип дәшкән. Фәрештә моңа: «Башта сәламгә җавап бир!» – дигәч, бу кеше: «Әйе, вә галәйкүм әссәләм! Нәрсә кирәк?» – дип әйткән. Фәрештә: «Мин синең хәлеңне белергә, сиңа ярдәм итәргә килдем, авырганыңны белдем», – дип әйткән. Бу кеше: «Әйе шул, мин чәч коелу авыруы белән авырыйм, әгәр дә минем авыруым төзәлеп, чәчем үссә, чәчем матурайса, сәламәтләнеп китсәм, яхшы булыр иде», – дигән. Фәрештә кулы белән аның башын

сыпыргач, тегесе сәламәтләнеп, чәче үсеп, матураеп киткән. Шуннан соң фәрештә аннан: «Тагын нәрсә телисең? Бәлки малдан берәр нәрсә телисеңдер, сарыклар, тәкәләр кирәкме сиңа?» – дип сораган. Бу кеше: «Юк-юк, сарыклар-тәкәләр уңыш китерми, миңа бер сыер бирсәң, шушы сыердан күпсанлы сыерлар, үгезләр туар, миндә сыер көтүе булыр һәм баеп китәрмен», – дип җавап кайтарган. Шуннан фәрештә, Аллаһының әмере белән моңа сыер биргән дә китеп барган.

Болардан соң фәрештә сукыр кеше янына килгән. Аңа: «Әссәләмү галәйкүм!» – дип сәлам биргәч, сукыр кеше үзенең күркәм әхлагы һәм ихласлы булуы сәбәпле: «Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!» – дип, матур итеп җавап кайтарган. Фәрештә: «Мин синең хәлеңне белергә, сиңа ярдәм итәргә килдем, авырганыңны белдем», – дип әйткән. Сукыр: «Әйе шул, мин сукыр, әгәр дә минем күзләрем төзәлеп, яңадан күрү сәләтем кайтса, сәламәтләнеп китсәм, мин Аллаһының мәхлүкатьларына карап, Аллаһыны мактар идем, Раббымнан моның хакта күптән сорыйм», – дип әйткән. Фәрештә кулы белән аның күзләрен сыпыргач, сукыр сәламәтләнгән, күзләре яңадан күрә башлаган. Шуннан соң фәрештә: «Тагын нәрсә телисең? Бәлки малдан берәр нәрсә телисеңдер, сарыклар тәкәләр кирәкме сиңа?» – дип сораган. Бу кеше: «Сөбеханәллаһ, миңа күрү сәләте кайтты, моннан да зур нигъмәт, байлык бармы соң?! Инде шуннан соң мин Аллаһыдан нәрсәдер сорарга оялам, әмма кешеләрдән мохтаҗ булырга теләмим, чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Садаканы бирүче – алучыга караганда хәерлерәк», – дип әйткән. Шуңа күрә, миңа байлык буларак, тәкә булса да ярый», – дип әйткән. Шуннан соң фәрештә Аллаһының әмере белән аңа тәкә биргән дә, китеп барган.

Бу хәлләрдән соң фәрештә күпмедер вакытка югалып торган. Тән авыруы (проказа) белән авырган кеше баеп киткән. Дөя көтүе арткаскланнан артып, зур-зур йортлар төзегән, хезмәтчеләр тоткан. Ул: «Менә мин

бай, мин, мин, мин», – дип тәккәберләнеп, мактанып, бу байлыкларны хакыйкатьтә кем биргәнен онытып, сөйләгән. Аллаһы һәрнәрсәнең Хуҗасы, Ул әхвәлләрне үзгәртүче икәнен бөтенләй оныткан.

Чәчсез булган кешенең сыерлары артып, ул зур сәүдәгәргә әйләнгән, баеган. Чәче матур, озын булып үскән. «Минем чәчләрем матур, кеше хәзер миннән көлми, мәсхәрә итми, киресенчә, мин хәзер чәчсез кешеләр өстеннән көләм, мәсхәрә итәм», – дип куанган. Әмма бу нигъмәтләрнең хакыйкый хуҗасын – Аллаһыны оныткан.

Сукыр булган кешегә килгәндә, ул һаман догада, зикердә һәм шөкердә булган. Эшен дә эшләгән, баеган да, әмма һаман Аллаһының нигъмәтләренә шөкер итеп, Аңа хәмед-сәналәр әйтүдән туктамаган.

Берникадәр вакыттан соң фәрештә алар янына әйләнеп кайткан. Тән авыруы белән авырткан кешегә шул ук сырхау белән интеккән кеше кыяфәтенә кереп килгән дә: «Мин мескен мосафир. Тән авыруы белән интегәм, миңа ярдәм ит», – дип мөрәҗәгать иткән. Бу кеше тәкәбберләнеп: «Сезнең кебек мескеннәргә ярдәм итеп, малымны исраф итәсем килми минем. Болай да бик күп бурычларым бар, мине борчыма, кит моннан», – дип җавап кайтарган. Фәрештә: «Тукта, мин сине беләм, син күптән түгел тән авыруы белән интеккән кеше түгелме? Мескен хәлдә елап йөргән кеше син идең ахыры?» – дип сораган. Ул: «Юк, минем белән берни булмаган иде, бу мал вә мөлкәт ата-бабалардан калган мирас», – дип, ялган җавап кайтарган. Фәрештә кулын күтәреп: «Йә, Раббым, әгәр дә ул ялганласа, аны элеккеге халәтенә кире кайтар», – дип дога кылган. Аллаһы Тәгалә бу фәрештәне сынау өчен җибәргән булган.

Шуннан соң фәрештә элек чәчсез булган кеше янына, шул ук чәчсез кеше кыяфәтендә килгән дә: «Мин мескен мосафир. Авыру белән интегәм, миңа ярдәм ит», – дип мөрәҗәгать иткән. Элек чәчсез булган кеше, җавап итеп: «Синең башың ник сахра шикелле буш?! Башыңны берәр нәрсә белән каплап куй инде», – дип мәсхәрәләгән. «Сезнең кебек мескеннәргә

ярдәм итеп, малымны исраф итәсем килми, минем болай да бурычларым бик күп, миндә бернинди акча юк. Бар, мине борчыма, кит моннан», – дип дорфа итеп җавап биргән. Фәрештә аңа да: «Тукта, мин сине беләм ахрысы, син бит күптән түгел үзең чәчсез идең. Мескен хәлдә елап йөри идең түгелме?» – дип сораган. Теге кеше: «Юк, минем беләнберни булмаган иде, бу мал вә мөлкәт ата-бабалардан калган мирас», – дип, ялган җавап кайтарган. Фәрештә кулын күтәреп: «Йә, Раббым, әгәр дә ул ялганласа, аны элеккеге халәтенә кире кайтар», – дип дога кылган.

Соңыннан элек сукыр булган кеше янына сукыр кыяфәтендә килгән. Теге кеше сукырны күргәч: «Әссәләмү галәйкүм, керегез, рәхим итегез, нинди хаҗәтегез бар?» – дип каршы алган. Һәм: «Мин дә кайчандыр сукыр булдым, мохтаҗ хәлендә идем. Ни рәвешле миңа Аллаһы биргән нигъмәтне синең белән бүлешим?» – дип сораган. Фәрештә: «Аллаһы сиңа һәм синең малыңа бәрәкәт бирсен һәм Аллаһы синнән разый булсын», – дип әйткән.

Аннан соң фәрештә элек сукыр булган бу кешегә: «Мин фәрештә, мин өчегезгә дә сынау буларак килдем, икегез Аллаһыны онытты, шөкер итмәде, шуңа Аллаһы аларны кабаттан шушы авыру мескен халәтенә кайтарды. Ә син шөкер итүчеләрдән булдың, Аллаһының зикереннән ваз кичмәдең, Аллаһы сиңа малыңны тагын да арттырыр, бәрәкәт бирер, синнән разый булыр», – дип, китеп тә барган.

Ахырда шушы ике кеше бик нык үкенгән һәм: «Әй, Аллаһым, без шөкерсез идек, тәкәбберләндек, әгәр дә без шөкер итеп, Синең нигъмәтләреңне таныган булсак, мондый хәлгә төшмәс идек», – дип зар елаганнар.

Шуңа күрә, хөрмәтле кардәшләр, белегез, бер гөнаһ та җәзасыз калмый, кайчан булса да без кылган гамәлләребез өчен җавап бирәчәкбез.

Шуңа да Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَاذْكُرُونِي أَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوا لِي وَلَا تَكْفُرُونِ ﴿١٥٢﴾

**«Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын. Миңа шөкер итегез, [әмеремә буйсынмыйча, нигъмәтләремне күрмәгәндәй] Миңа карата шөкерсез булмагыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:152

Шушы ике шөкерсез кеше халәтендә каласыбыз килмәсә, тузан бөртеге хәтле нигъмәт өчен дә шөкер итик. Аллаһыга көферлек китермик. Кылган гамәлләребезгә хисап кылыйк. Кайда гына булсак та, Аллаһыдан куркыйк. Дөреслектә, Ул барысын да күреп һәм ишетеп тора. Шунысын да игътибардан читтә калдырырга ярамый: һәрвакыт Аллаһыны истә тоту, Аңа шөкерле булу, Аны зикер кылу безнең күңелебезгә тынычлык сала, тормышыбызга ямь өсти. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

أَلَا بِذِكْرِ ٱللَّهِ تَطْمَئِنُّ ٱلْقُلُوبُ

**«Күңелләр Аллаһыны зикер итү белән тынычланмыймы?»**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:28

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иң хәерле зикер: «Ләә иләәһә илләллааһү» вә иң хәерле дога «Әлхәмдүлилләһи» сүзләре», – дип әйткән. Шушы хәдисләргә таянып әйтсәк, дога кылуыбыз да зикер кылу булыр, чөнки дога кылганда без бар күңелебез белән Раббыбызга мөрәҗәгать итәбез, Аны олуглыйбыз, Аннан гына ярдәм сорыйбыз, бары Аңа гына мохтаҗ булуыбызны таныйбыз. Кеше иртән һәм кичен, ким дигәндә, 100 тапкыр «Ләә иләәһә илләллааһү» дип, зикер кылырга тиеш. Зикерне кылганда күзне йомып уку хәерлерәк вә зикер вакытында Аллаһының бөеклеге турында фикерләү мәслихәт. Бу халәт безгә бик зур көч бирә, күңелебезне тынычландыра, хәтта сәламәтлегебезгә дә уңай тәэсир ясый.

Зикернең әһәмиятен, дәрәҗәсен күрсәтеп Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اذْكُرُوا اللَّهَ ذِكْرًا كَثِيرًا

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыны күп итеп зикер кылыгыз».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:41

Аллаһы Тәгалә: «Күп итеп намаз укыгыз, күп итеп зәкят бирегез, күп итеп хаҗ кылыгыз», – димәде, ә күп итеп зикер кылыгыз, диде. Зикер калебне, сәламәтлекне ныгыта, дөньяда тынычлык-бәрәкәт, Ахирәттә бәхет вә җәннәт бирә, иншәАллаһ. Шунысы да бар: гыйбадәтләрнең күбесен тәһарәтсез үтәргә ярамый, ә зикерне (мунчадан вә бәдрәфтән кала) теләсә кайда кылырга ярый. Зикерләрнең төрләрен зикер кылуга багышланган берәр китапны алып өйрәнә алабыз.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй сәхабәләрем! Сезгә гамәлләрдән иң хәерле булган, Раббыгыз каршында иң чиста, дәрәҗәләрегезне күтәрә торган, Аллаһы юлында көрәшүдән дә хәерлерәк гамәлгә өндимме?» – дигән. Сәхабәләр: «Әлбәттә, йә Расүлуллаһ!» – дигәннәр. Расүлебез: «Аллаһыны зикер кылу барысыннан да хәерлерәк», – дип әйткән.

Имамнар Әл-Бохари һәм Әл-Мөслим тапшырган хәдистә Расүлебезнең әлеге сүзләре риваять ителә: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: «Мин, колым Минем хакта уйлаганча булам һәм Мин, ул Мине искә алганда, аның белән бергә. Әгәр ул Мине күңелендә искә алса, Мин дә аны шулай искә алырмын. Әгәр ул Мине башка кешеләр янында искә алса, Мин аны тагы да яхшырак булучылар янында искә алырмын. Әгәр ул Миңа бер карыш якынайса, Мин аңа терсәк озынлыгы кадәр якынаермын. Әгәр ул Миңа терсәк озынлыгы кадәр якынайса, Мин аңа сажин (элеккеге озынлык үлчәү берәмлеге) кадәр якынаермын. Ул Миңа атлап килсә, Мин аңа каршы чабармын».

Әлеге сүзләрдән без Аллаһы Тәгаләгә якынаюыбыз үзебездән дә торганлыгын аңлыйбыз. Әмма моның өчен, иң беренче чиратта, күңелебездә Аллаһыны һәрдаим истә тоту, Аны онытмау хисләре булырга тиеш.

Раббыбыз Аллаһы безне һәрдаим зикердә, шөкер кылуда булучылардан итсә иде. Үзенең киң рәхмәте белән кылган зикерләребез ике дөнья бәхетенә сәбәпче булса иде. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*

*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*18 нче февраль вәгазе,*

*раҗәб аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Мөселман – һәрьяклап камиллеккә омтылучы кеше

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Әмма бәгъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә, салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде. Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Камил мөселман – ул үз тормышын Аллаһы Тәгаләгә, үзенә, гаиләсенә, гомумән, башка мөселманнарга карата булган хокук һәм бурычларын үтәү өчен төзүче кеше.

Әлбәттә, һәр мөселман, мин чын күңелдән Аллаһы Тәгаләгә ышанам һәм камил мөселманмын, дип әйтер. Ләкин, чын һәм камил мөселман кешесе нинди сыйфатларга ия булуы турында бар кеше дә уйламый. Без мөселманнар, дип әйткәндә, үз өстебезгә зур җаваплылык йөклибез. Беренче чиратта, Раббыбыз каршысында, чөнки гамәлебез, сүзләребез, үз-үзебезне тотышларыбыз һәм яшәү рәвешебез белән җәмгыятьтә ислам динен саклау һәм яклау эшендә зур роль уйныйбыз, бигрәк тә халыкның күп өлеше мөселманнар булмаган җирдә.

Кеше диндар буларак, һәрвакыт камиллеккә омтылырга тиеш. Беренчедән, камил мөселман – ул үзенең Раббысы белән камил мөнәсәбәттә булган кеше. Бары тик шул вакытта гына ул әйләнә-тирәдәгеләр белән җылы, яхшы мөнәсәбәтләр төзи ала, шулай ук, үзен тиешенчә тотып, кешене үзе белән ияртә дә ала. Чыннан да, мөселман кешесе кайда

гына булмасын, ул юл күрсәтүче йолдыз кебек һәм үз сүзләре белән дә, гамәле белән дә башкаларны уңай якка үзгәртүдә үз өлешен кертә, белем чыганагы булып тора.

Тарихи яктан карасак та, ир-ат – сакчы һәм табучы, ә хатын-кыз – учакны саклаучы. Асылда ир-ат гаилә башлыгы буларак алып баручы, хатын-кыз, киресенчә, үзе янында ышанычлы булган кешегә таянып яшәүче. Шуңа күрә ир-атның төп бурычы – үзенең ярына дини белем бирү яисә гыйлем ала торган урыннарга йөрүне рөхсәт итү. Кызганычка, күп очракта хатыны намаз укый, ә ире юк. Ничек син ир-ат, гаилә башлыгы, имамы буларак, намаз укымыйсың, ураза тотмыйсың?! Синнән гаиләң үрнәк ала, син туры юлга өндәүче булып торасың.

Без – ирләр. Без – мөселманнар. Без ислам байрагын күтәрдек. Шушы ислам байрагын алып барабыз, әгәр дә без хата кылсак, урамда сүгенсәк, мөселманнар шундый икән дип, бармак төртеп күрсәтәләр. Шуңа күрә, җәмәгать, сезне туганнарыгыз, күршеләрегез, бөтен халык белә, сез мәчеткә йөрисез, намаз укыйсыз, әмма «ислам шундый» дип әйтергә шәйтан юлларын ачыр. Без ислам байрагын төшермик, аны күтәргәнбез икән, горурланып алып барыйк, динебезне төшермик, көлкегә калдырмыйк.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд сәлләллаһу галәйһи вә сәллам «Иман күзлегеннән иң камил мөселман – яхшы әхлаклы кеше»[1], – дип әйткән.

Аллаһы Тәгаләнең Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманның намуслы, көчле рухлы, ныклы иманлы, ихлас булуына, аның җитлеккәнлеге һәм камиллегенә игътибарын юнәлтте.

Тәкъва кешеләр: «Рухи яктан камилләшү – яхшы сыйфатларны үзләштерү һәм начар гадәтләрдән арыну ул», – дип әйтеп калдырган. Димәк, Аллаһы Тәгаләнең лаеклы колы булырга теләгән һәркем үз-үзенә хисап бирергә, үзенең тотышына игътибарлы булырга тиеш.

---

1 Әхмәд бине Хәнбәл, «Мөснәд», II, 250.

Безнең тагын бер мәсьәлә барлыкка килә. Ул да булса икейөзлелек. Без өйдә бер төрле, урамга чыккач, мәчеткә килгәч – без башка. Кеше мәчеттә әдәпле дә, тәртипле дә, сүгенми дә, тәмәке дә тартмый, бар яклап үрнәк мөселман. Өйдә ул талаша, хатынына кул күтәрә, сүгенә, харам ризык ашый. Безнең Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шундый булганмы?! Юк, ул бар җирдә мөселман булган: өендә дә, урамда да, дошманы белән дә әдәпле, тәртипле булган. Без дә шундый булыйк. «Бу динне тоту авыр икән», дип әйтүчеләр бар. Әйе, без икейөзле булсак, динне тоту авыр. Ләкин, без бөтен яклап камил булып, бар җирдә мөселман булыйк. Безнең өчен Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, галимнәребез мисал булып тора.

Әгәр дә кеше холкына тискәре сыйфатлар хас икән, ул тәүбә итәргә һәм алардан акрынлап котылу юлын табарга тиеш. Мөселман кешесе игелекле һәм ныклы рухлы булуга ирешү максатын күз алдында тотса гына теләгәненә ирешә ала.

Әгәр дә кешенең күңеле нәфрәт, ачу, көнчелек белән тулган булса һәм аңа үзен башкалардан өстен тоту гадәте хас булса, ул беренче чиратта, кеше җитешсезлекләре түгел, ә үз кимчелекләре өстендә эшләргә тиеш.

Кешелек дөньясы бәхетле булыйм дисә, иң элек камил кеше булуга омтылырга тиеш. Бүген дә пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күрсәтмәләре безгә маяк булып тора.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт

итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*25 нче февраль вәгазе,*

*раҗәб аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Пәйгамбәребезнең бөек сәяхәте

Галәмнәрнең Раббысы булган Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкераналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават, сәламнәребез булсын.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ

**«Аятьләребездән кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне [бик кыска бер вакытта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм колын Харам мәчетеннән [алып] Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әкъса мәчетенә күчерүче кимчелекләрдән пакь. Һичшиксез, Ул – [һәрнәрсәне] Ишетүче, Күрүче»,** – дип әйтә.

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1

«Әл-Исра» сүрәсенең беренче аяте Аллаһының шушы сүзләре белән башланып китә. Аллаһы шушы вакыйга белән Пәйгамбәребезне юатырга, аңа көч бирергә теләде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәрлегенең унынчы елында аның яраткан бабасы Әбү Талиб вафат була. Әбү Талиб Пәйгамбәребез белән Кораеш кабиләсе арасында бер киртә булып торды. Үзе исламны кабул итмәсә дә, Аллаһының рәхмәте белән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Кораеш кабиләсе кешеләренең явызлыгыннан саклады, шул сәбәпле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә үзенең вазифасын башкаруда ярдәм

итте. Озак та үтми, өч айдан бабасы артыннан аның иң яраткан кешесе – хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә дә вафат була. Хәдичә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аллаһының зур бер рәхмәте һәм бүләге булды. Ул иң авыр чакларда Пәйгамбәребез белән бергә иде, аңа рухи яктан көч биреп торды, аны сабырлыкка чакырды, күңел төшенкелегенә бирелмәскә өндәде. Шулай ук Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне пәйгамбәр дип танучы иң беренче кеше – хатыны Хәдичә булды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә хакында шундый сүзләр әйтеп калдырган: «Башкалар каршы килгәндә, ул иң беренче булып иман китерде, башкалар мине ялганчы дигәндә, ул миңа ышанды, башкалар миннән борылганда, ул үзенең булганы белән бүлеште һәм башка хатыннардан минем балаларым булмаганда, Аллаһы аннан миңа балалар бирде».

Кайгы артыннан кайгы килү сәбәпле, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөрәге сыкрады һәм авыртудан тетрәде. Шуңа өстәп, Әбү Талиб вафатыннан соң, имансызларның һөҗүмнәре, явызлыклары тагы да көчәйде һәм Мәккәдә дингә чакыру мөмкин булмый башлады. Гомумән, мөселманнарның хәле дә авырайды һәм бер төркем мөселманнар Хәбәшәгә (Эфиопиягә) күчеп китәргә мәҗбүр булдылар. Шушы авырлыклар сәбәпле, Пәйгамбәребез бу елны «Кайгы елы» дип атады һәм бу ел тарихка шушы исем белән кереп калды. Мәккәдә дингә чакыру эшләре кыенлашкач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Таиф шәһәренә барырга карар кылды. Бәлки андагы халык аны аңлар, иман китерүчеләр булыр дип өметләнде. Әмма Таиф халкы да аны кабул итмәде, аны ташлар атып кудылар: яраларыннан каннар акты. Пәйгамбәребезнең күңеле төште, кайтышлый бер агач күләгәсе астына утырып дога кылды һәм шул догасында: «Йә, Раббым, әгәр Син миннән разый булсаң, бу авырлыклар миңа берни түгел», – диде.

## Исра (Кичке сәфәр)

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Аллаһы шушы авырлыклар белән сынаса да, Ул аны Үз ярдәменнән калдырмады. Аллаһы Пәйгамбәребезгә күңелен юата, өмет һәм көч бирә торган бер могҗиза күрсәтте: аны бер төн эчендә Мәккәдән Кодес (Иерусалим) шәһәренә һәм аннан җиденче кат күккә – Үз хозурына күтәрде. Бу вакыйга пәйгамбәрлекнең унынчы елында – 27 нче раҗәб ае кичендә булды һәм, Коръәннән кала, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң зур могҗизасы иде. Бу хәл болай булды: Пәйгамбәребез төнлә, апасы Өмме Һәнинең йортында диварга сөялеп утырганда (икенче риваять буенча Кәгъбәгә сөялеп утырганда) аның янына ике фәрештә килә. Алар Пәйгамбәребезнең күкрәген ярып, аннан йөрәген алып Зәм-зәм суы белән юалар һәм пакьләп кире урынына куялар. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына Бурак исемле хайванны җитәкләп, Җәбраил галәйһиссәлам килә. Бу хакта ул үзе сөйли: «Төнлә белән минем яныма Җәбраил фәрештә килде. Ул Бурак белән иде. Бу – ишәккә охшаган, ләкин аннан бераз зуррак булган ак төстәге хайван иде. Аңа утырып, мин Бәйтел Мәкъдискә (Иерусалим шәһәре) китерелдем. Әкъса мәчете ишеге төбендә Буракны бәйләп куеп, эчкә уздым һәм барлык пәйгамбәрләр белән, аларга имам торып, намаз укыдым. Намаз укып чыкканда, минем яныма Җәбраил галәйһиссәлам ике савыт тотып килде: берсендә хәмер, икенчесендә сөт иде. Мин сөтне сайладым һәм Җәбраил галәйһиссәлам: «Син пакьлекне сайладың», – диде.

## Мигъраҗ (Күккә күтәрелү)

Шуннан соң алар күкләргә күтәреләләр. Һәрбер күккә күтәрелгән саен, ул пәйгамбәрләр белән очраша, аларга сәлам бирә һәм андагы серләрне күрә. Беренче күктә – Адәм галәйһиссәлам белән очраша. Икенче күктә – Гайсә һәм Яхъя галәйһимуссәлам белән, өченче күктә – Йосыф,

дүртенче күктә – Идрис, бишенче күктә – Һарун, алтынчы күктә – Муса галәйһимуссәлам белән күрешә. Җиденче күккә менгәч, пәйгамбәрләрнең атасын – Ибраһим галәйһиссәламне Бәйт Әл-Мәгъмурнең (күктәге кәгъбә) диварына аркасы белән сөялеп утырганын күрә. Җәбраил галәйһиссәлам аңа: «Бу синең атаң, аңа сәлам бир», – дип әйтә. Сәлам бирешкәч, Ибраһим галәйһиссәлам: «Хуш килдең, изге ул һәм изге пәйгамбәр», – ди.

Пәйгамбәребезнең нәсел ботагы Ибраһим галәйһиссәламгә килеп тоташа һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның оныгы булып санала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Мин Ибраһимны күрдем һәм мин аның балаларыннан аңа иң ошаганы».

## Сидратүл- Мөнтәһә

Ибраһим галәйһиссәлам белән очрашканнан соң, ул Сидратүл-Мөнтәһә исемле агач янына тукталды. Сидратүл-Мөнтәһә «соңгы тукталыш агачы» дип тәрҗемә ителә, чөнки бу агач җиденче күкнең чигендә урнашкан була. Шуңа күрә бер генә фәрештәгә дә бу агачтан ары үтү рөхсәт ителмәде. Әмма Пәйгамбәребезгә рөхсәт ителде. Хәдисләрдә килгәнчә, бу агачның күләгәсен атлы җайдак йөз ел эчендә генә үтеп чыга алачак. Бу агачның нигезеннән дүрт елга агып чыгадыр. Икесе яшерен елга, икесе өстән ага торган елгалар. Өстән ага торган елгалар: Нил һәм Фурат (Ефрат) елгалары, ә яшереннәре – алар җәннәттәге елгалар. Аның җимешләре зур чүлмәкләргә, ә яфраклары фил колакларына ошаган. Бу агач алтыннан булган җәймә белән капланган. Аны күргән кеше матурлыгын әйтеп, сыйфатлап бирә алмас.

Шуннан соң Пәйгамбәребез Раббыбыз белән сөйләште. Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Аллаһының Расүле Сидратүл-Мөнтәһә дигән агач янында тукталгач, аңа өч нәрсә бирелде: биш вакыт намаз, «Әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы аятьләре һәм аның өммәтеннән

Аллаһыга тиңдәшлек кылмаучының гөнаһлары ярлыкануы»[1].

Пәйгамбәребез Аллаһыдан үзенең өммәтен коткара торган бер гамәл сорады. Аллаһы аңа илле вакыт намаз әмер итте. Раббысы яныннан кайтканда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм алтынчы күктә Муса галәйһиссәлам янында тукталды, Муса галәйһиссәлам аннан: «Раббың сиңа нәрсә әмер итте», – дип сорады. Расүлебез: «Һәр көнне илле вакыт намаз», – диде. Муса галәйһиссәлам: «Синең өммәтең көненә илле намазны башкара алмас, мин Исраил уллары халкын дөресләр өчен бик күп тырышлык куйдым. Бар, кайт, Раббыңнан җиңеләйтүне сора», – диде... Шулай итеп, Муса галәйһиссәлам, җиңеләйтүне сорап, Пәйгамбәребезне ике тапкыр Раббысы янына кайтара. Намаз вакытлары беренче тапкырында – унга, икенчесендә бишкә төшерелә. Шуннан соң да Муса галәйһиссәлам Расүлебезгә кабат кайтып, Аллаһыдан җиңеләйтүне сорарга куша: «Мин Исраил уллары халкына моннан да азракны үтәргә чакырдым, әмма алар аны да калдырдылар. Раббыңа кайт, тагы да җиңеләйтүен сора», – дип әйтә. Әмма Пәйгамбәребез, оялам дип, кире кайтмый. Шуннан соң тавыш килә: «Намазларның саны биш булса да, алар илле булып калыр. Мин Үземнең Сүземне үзгәртмим», – диде. Шулай итеп, биш вакыт намаз укучы кеше илле вакыт намаз укыган булып саналыр.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Мигъраҗ вакытында җәннәт һәм аның әһелләре күрсәтелде. Ул җәннәттә булып, аңа биреләсе Кәүсәр елгасы китерелде, җәһәннәм һәм аның әһелләре, төрле гөнаһ кылучылар һәм аларның нинди җаза алулары күрсәтелде. Шулай ук аңа башка төрле күп могҗизалар күрсәтелде, күп серләр ачылды. Болардан соң Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кире кайтарылды.

### Кайтуы

Иртүк Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Кәгъбәгә сөялеп тирән уйларга чумып утырганда, аны Әбү Җәһел күреп ала һәм мыскыл

[1] Имам Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

иткәндәй: «Синең белән берәр нәрсә булмагандыр бит?» – дип сорый. Пәйгамбәребез аңа төнлә булган хәлләрне сөйләп бирә. Бу хәбәр бөтен Мәккә халкына тарала. Имансызлар, кызык ясарга теләп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына җыелалар. Алар Пәйгамбәребезгә: «Син нинди ахмак сүзләр сөйлисең?! Без Кодескә (Иерусалимга) бер ай барабыз, бер ай кайтабыз, ә син төннең бер өлешендә Мәккәдән Бәйт Әл-Мәкъдискә барып, аннан Аллаһы хозурына менеп төштем дип әйтәсеңме?» – дип әйтәләр. Пәйгамбәребез: «Әйе», – ди. Алар: «Алай булгач, безгә Бәйт Әл-Мәкъдисне сыйфатлап бир», – диләр. Әлбәттә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм төнлә шәһәр белән танышып йөри алмады, ләкин Аллаһы аны авыр хәлдә калдырмый: ул Пәйгамбәребезнең күз алдына шәһәр манзараларын китерә һәм Расүлебез шуннан карап, шәһәрне сыйфатлый башлый, имансызлар бу җавапка каршы бер сүз дә әйтә алмыйлар. Шулай ук Пәйгамбәребез аларга Мәккәгә кайтып бара торган кәрванны, алдан нинди дөя беренче баруын һәм бу кәрванның кайчан кайтып җитәсе хакында да хәбәр бирә. Бу әйткәннәр дөреслеккә туры килсә дә, имансызлар барыбер иман китерми. Аллаһы Коръәндә бу хакта болай дип әйтә:

فَإِنَّهُمْ لَا يُكَذِّبُونَكَ وَلَٰكِنَّ الظَّالِمِينَ بِآيَاتِ اللَّهِ يَجْحَدُونَ ﴿٣٣﴾

**«Алар [синең хаклыгыңны белгәннәре өчен, асылда] сине ялганчыга санамыйлар, ләкин залимнәр Аллаһының аятьләрен [хак булганын белә торып] инкяр итәләр».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:33

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһегә Исра вә Мигъраҗ вакыйгасы хакында җиткергәч, ул: «Әгәр ул шулай дип сөйләсә, бу хактыр. Мин әле моннан да өстенрәк нәрсәгә ышанам. Мин аңа бер мизгел эчендә күктән хәбәр килүенә ышанам», – дип әйтә. Шуннан соң аңа «Әс-Сиддыйк» (нык ышанучы, Расүлдән килгән хәбәрне раслаучы) дигән кушамат бирелә.

Бу вакыйга Пәйгамбәребезгә көч бирде, аны ныгытты һәм ул яңа дәрт белән чакыру эшен дәвам итте. Ясриб шәһәреннән килгән кешеләр аңа иман китерде һәм бу шәһәрдә Ислам дине әкренләп тарала башлады.

## Дәресләр

Бу вакыйгадан без бик күп гыйбрәтләр һәм дәресләр алабыз. Шулардан: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка расүлләрдән булган өстенлеге. Әлбәттә, Аллаһы һәр расүлгә бер өстенлек бирде. Нух галәйһиссәламне көймәдә коткарды, Ибраһим галәйһиссәламне уттан исән-имин килеш чыгарды, Үзенә якын дус итеп алды. Муса галәйһиссәлам белән Аллаһы сөйләште. Гайсә галәйһиссәламне Үз хозурына күтәрде. Ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләрнең соңгысы итте, аны бөтен дөнья халкына Расүл кылды һәм аңа моңарчы бер кешегә дә күрсәтмәгән күкләрнең серләрен ачты, аның белән турыдын-туры сөйләште. Беркем дә әле мондый өстенлекләргә ия булмады.

Ибраһим галәйһиссәлам үзеннән соң килгән пәйгамбәрләрнең атасы, Расүлебезнең ерак бабасы булып тора. Пәйгамбәребезнең нәселе Ибраһим галәйһиссәламнең улы Исмәгыйль галәйһиссәламгә, ә Исраил уллары халкына килгән пәйгамбәрләрнең нәселләре аның улы Исхак галәйһиссәламгә килеп тоташа. Аллаһы Ибраһим галәйһиссәламне үзенең дусты итеп сайлап алды һәм Коръәндә ул барган юл буйлап барырга безгә әмер итте. Шуңа да аның җиденче күктә булуы Аллаһыга якынлыгын күрсәтә.

Кайбер кеше Пәйгамбәребезнең Исра һәм Мигъраҗ вакыйгасын шик астына куя яки бөтенләй аңа ышанмый, аның Буракта очуында шикләнә. Аллаһының чиксез кодрәтенә ышанучы бу вакыйга хакында шикләнмәс. Әгәр дә без – кимчелекле кешеләр, тавыш тизлегеннән дә тизрәк оча торган очкычлар яки тагы да тизрәк хәрәкәт итә торган ракеталар бар итә ал-

ганбыз икән, Аллаһыга Пәйгамбәребезне бер кичтә Кодес шәһәренә алып барып, күкләргә күтәрүе нинди авырлык китерсен?!

Кодестагы Әл-Әкъса мәчете мөселманнар өчен Әл-Харам мәчете кебек изге урындыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу мәчеттә укылган намаз, башка мәчетләрдә укылган намазлардан, биш йөз тапкырга өстенрәк», – диде. Бу мәчетне беренче булып Ибраһим галәйһиссәлам һәм аның улы Исхак галәйһиссәлам төзиләр. Сөләйман галәйһиссәлам аны торгыза. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм берничә мөселман иң элек намазларын Әл-Әкъса мәчетенә юнәлеп укый, ә аннары Аллаһы кыйбланы Әл-Харам мәчетенә күчерә.

Әмма бу вакыйгадан ала торган иң зур дәрес – ул намазның әмер ителүе. Динебездә булган нинди генә фарызны, әмерне алсак та, алар Пәйгамбәребез җирдә булганда, Җәбраил фәрештә аркылы әмер ителде, ә намазны Аллаһы Пәйгамбәребезгә Үз хозурында булганда, турыдан-туры бирде. Шуңа күрә намаз Аллаһы каршында бик зур әһәмияткә ия. Намаз укучы кеше, Аллаһы хозурына күтәрелеп, Аның белән сөйләшкән дәрәҗәсенә ирешер. Намаз ислам динендә иң олы гыйбадәтләрдән санала. Биш вакыт намаз укучы кеше үзенең Раббысы белән гел элемтәдә тора, Аны һәрвакыт истә тота, менә шуның өчен Аллаһы Үзенең колларына бу олы гыйбадәтне әмер итте. Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

فَاذْكُرُونِي أَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوا لِي وَلَا تَكْفُرُونِ

**«Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын. Миңа шөкер итегез, [әмеремә буйсынмыйча, нигъмәтләремне күрмәгәндәй] Миңа карата шөкерсез булмагыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:152

Шулай ук намазның тагын бик зур көче бар: ул кешене бозыклыктан һәм гөнаһлардан тыя. Бу хакта Аллаһы Тәгалә:

وَأَقِمِ الصَّلَاةَ ۖ إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ

**«Намазны укы, чөнки [тышындагы һәм эчендәге бөтен шарт һәм әдәпләренә туры китереп, камил дәрәҗәдә укылган] намаз [зина кебек] әшәкелекләрдән дә, [шәригатьтә дә, акыл белән дә] гаеп саналганнардан да саклый»,** – дип әйтә.

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:45

Намаз – ул Аллаһының кыйммәтле бүләге, бу бүләкне Аллаһы Үзе сайлап алган колларына гына бирә. Намазны бүләк дип кабул итүчегә Аллаһы тагы да зуррак бүләк бирәчәк. Бу бүләккә ия булучылар – бәхеткә ия булучылар.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*

*Балтач үзәк мәчетенең икенче имамы*

*4 нче март вәгазе,*

*шәгъбан аенең 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Хәзрәти Хәдичә анабыз үрнәгендә

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

النَّبِيُّ أَوْلَىٰ بِالْمُؤْمِنِينَ مِنْ أَنفُسِهِمْ ۖ وَأَزْوَاجُهُ أُمَّهَاتُهُمْ ۗ ... ﴿٦﴾

**«Нәби мөэминнәргә үз җаннарыннан да якынрак. [Ул мөэминнәрнең атасы кебек булганы өчен] Аның хатыннары исә аларның аналары...»**, – дип әйтә.

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:6

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыннары хакында беләбез. Алар барысы да безнең – мөэминнәрнең аналары булып санала. Һәм шуңа күрә алар башка хатыннарга караганда Аллаһы каршында өстенрәктер. Коръәндә болай дип әйтелгән:

يَا نِسَاءَ النَّبِيِّ لَسْتُنَّ كَأَحَدٍ مِّنَ النِّسَاءِ ۚ إِنِ اتَّقَيْتُنَّ فَلَا تَخْضَعْنَ بِالْقَوْلِ فَيَطْمَعَ الَّذِي فِي قَلْبِهِ مَرَضٌ وَقُلْنَ قَوْلًا مَّعْرُوفًا ﴿٣٢﴾

**«Ий пәйгамбәр хатыннары! Сез [Минем өчен] хатыннардан һичберсе кебек түгелсез. Әгәр сез тәкъва булсагыз [сезнең савабыгыз Минем хозурымда башка бөтен изге хатыннарныкыннан бермә-бер артык булыр]. Сез [ирләр белән пәрдә артыннан сөйләшүегез кирәк булган вакытта] сүзне йомшартмагыз ки, күңелендә [зинага тартылу кебек] бер чир булган кеше [бушка] өметләнмәсен. Сез [мөрәҗәгать иткән затларга шиктән соң дәрәҗә ерак, бераз каты, ләкин дин һәм акыл ягыннан] яхшы дип беленгән сүз сөйләгез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:32

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең унбер хатыны булды. Пәйгамбәребез аларга ошбу тәртип буенча өйләнде: Хәдичә бинте Хөвәйлид, Сәүдә бинте Зәмга, Гайшә бинте Әбү Бәкер, Хафса бинте Гомәр, Зәйнәб бинте Хөзәймә, Өмме Сәләмә, Зәйнәб бинте Җәхеш, Җүвәйрия бинте Харис, Сафия бинте Һөйәви, Өмме Хәбибә, Мәймүнә бинте Харис – Аллаһы аларның барысыннан да разый булсын. Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мисырдан булган, аңа Ибраһим исемле бала тапкан Мәрийә Әл-Кыйбтыя исемле кәнизәге дә булды. Пәйгамбәребез исән чагында аның ике хатыны – Хәдичә бинте Хөвәйлид белән Зәйнәб бинте Хөзәймә вафат булалар. Үзе вафат булгач, аның тугыз хатыны тол кала. Бу хатыннарның күбесе инде олы яшьтә булалар, бары тик бер Гайшә радыяллаһу ганһә генә яшь була.

Дөрес, кайвакытта Пәйгамбәребезнең хатыннары арасында ихтилафлар да килеп чыга иде. Пәйгамбәребез алар арасын күркәм рәвештә хәл итә иде. Расүлебез һәм аның хатыннары матди яктан авыр хәлдә яшәгәннәр. Гайшә радыяллаһу ганһә әйтүенчә, аларның Пәйгамбәребез белән яшәгән бүлмәләрендә берничә ай буе ризык та пешерелмәгән чаклар булган. Алар бу чакларда хөрмә ашап һәм су эчеп кенә торганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм башка хатыннарының өендә дә шулай ук ашарга берни дә булмаганын белә иде. Әмма алар түзгәннәр һәм сабыр иткәннән. Шулай да берьюлы Пәйгамбәребезнең хатыннары Расүлебез аларга бирә торган нәфәканы (тәэмин итәр өчен түләнә торган акча) аттыруын сораганнар. Пәйгамбәребезне бу таләп борчуга салган. Һәм күпмедер вакыттан соң бу хәлгә әлеге аять иңгән:

يَا أَيُّهَا النَّبِيُّ قُل لِّأَزْوَاجِكَ إِن كُنتُنَّ تُرِدْنَ الْحَيَاةَ الدُّنْيَا وَزِينَتَهَا فَتَعَالَيْنَ أُمَتِّعْكُنَّ وَأُسَرِّحْكُنَّ سَرَاحًا جَمِيلًا ﴿٢٨﴾ وَإِن كُنتُنَّ تُرِدْنَ اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَالدَّارَ الْآخِرَةَ فَإِنَّ اللَّهَ أَعَدَّ لِلْمُحْسِنَاتِ مِنكُنَّ أَجْرًا عَظِيمًا ﴿٢٩﴾

**«Ий Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм! Хатыннарыңа әйт: «Әгәр сез дөнья тормышы һәм аның [фани] бизәген теләсәгез, килегез, сезне [аерган өчен түләп] файдаландырыйм һәм [зарар китермичә] яхшылык белән җибәрим. Әмма әгәр дә сез Аллаһыны, Аның Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмне һәм Ахирәт йортын теләсәгез, һичшиксез, Аллаһы арагыздан игелек кылучылар өчен зур әҗер әзерләгән».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:28-29

Шуннан соң, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатыннарына шушы аятьләрне укыды һәм алар барысы да Аллаһыны, Аның Расүлен һәм Ахирәтне сайладылар һәм сабыр иттеләр.

Пәйгамбәребезнең иң яраткан хатыны – Гайшә радыяллаһу ганһә иде. Бу берәүгә дә сер булмый. Пәйгамбәребезнең хатыннары үзләре дә моны бик яхшы белгәннәр. Бер хәдистә килгәнчә, Гамре бине Әл-Гас радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Әй Аллаһының расүле! Син кемне күбрәк яратасың», – дип сорагач, ул: «Хатыным Гайшәне», – дип җавап биргән. Әмма Пәйгамбәребезнең яраткан хатыны хәзрәти Хәдичә радыяллаһу ганһә дә бар иде. Белүебезчә, хәзрәти Хәдичә анабыз сәүдәгәр хатын иде, ә яшь егет, ягъни пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның сәүдә кәрваннарын җитәкләде һәм бу эштә әманәтле, намуслы булды. Бу егетнең күркәм холкын күргәч, хәзрәти Хәдичә радыяллаһу ганһә аңа тәкъдим ясады, ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу тәкъдимне кабул итте һәм алар никахлаштылар. Пәйгамбәребезгә ул вакытта – 25, хәзрәти Хәдичә анабызга 40 яшь иде. Яшь аралары унбиш ел булса да, алар бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яшәделәр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кырык яшь тулгач, Аллаһы аны Расүл итеп сайлап алып, Хира тавында беренче аятьләрне иңдергәч тә, ул куркуыннан хәзрәти Хәдичә анабыз янына йөгерде, ятагына ятып: «Каплагыз мине, каплагыз», – диде. Һәм

бераздан тынычлангач, бөтен булганны хәзрәти Хәдичә анабызга сөйләп бирде. Пәйгамбәребез бик курыккан иде, үзе белән ни булганын, аның янына килгән затның кем икәнен аңламады. Шулчак хәзрәти Хәдичә радыяллаһу ганһә аңа: «Юк, валлаһи, Аллаһы сине мәңге хур итмәс. Син бит туганнар арасын ныгытасың, хак сүзләр генә сөйлисең, көчсезнең йөген ташыйсың, мохтаҗга ярдәм итәсең, кунакны хөрмәтлисең, авыр, читен хәлгә калганнарга ярдәм күрсәтәсең», – дип, аны юатты. Шуннан соң Хәдичә радыяллаһу ганһә аны Тәүрат, Инҗил китапларын белүче абыйсы Вәрака янына алып бара. Вәрака аңа: «Синең яныңа килгән зат – ул Муса янына килгән заттыр», – дип, аның янына килгән затның фәрештә икәнен әйтә. Карагыз: Хәдичә радыяллаһу ганһә иренә нинди күркәм, акыллы сүзләр әйтә һәм Пәйгамбәребезгә төнлә белән, тау куышында янына килгән затның фәрештә икәнен ачыкларга ярдәм итә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә беренче булып иман китергән кеше дә аның хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһә булды. Һәм аннары да Пәйгамбәребезгә киңәшләр биреп, көч биреп торды, Расүлебезгә күп ярдәмнәр күрсәтеп яшәде, аның өчен ныклы терәк булды. Хәзрәти Хәдичә радыяллаһу ганһә белән булганда, ул бүтән бер хатынга да өйләнмәде. Пәйгамбәребез Хәдичә анабыз радыяллаһу ганһә хакында болай дип әйткән: «Башкалар каршы килгәндә ул беренче булып иман китерде, башкалар мине ялганчы дигәндә, ул миңа ышанды, башкалар миннән борылганда, ул үзенең булганы белән бүлеште һәм башка хатыннардан минем балаларым булмаганда, Аллаһы аннан миңа балалар бирде»[1]. Пәйгамбәребезнең җиде баласы булды, шуларның алтысы хәзрәти Хәдичә анабыздан иде.

Хәдичә радыяллаһу ганһәнең кылган изгелекләре сәбәпле Аллаһы каршында ул зур дәрәҗәгә ия булды. Хәтта Раббыбыз Аллаһы аңа Үзе сәлам җибәрде. Хәдистә килгәнчә, бервакыт Җәбраил галәйһиссәлам

[1] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

Пәйгамбәребез янына килеп: «Аллаһы хәзрәти Хәдичәгә сәлам тапшыра», – дип әйткән. Пәйгамбәребез Хәдичә анабыз радыяллаһу ганһәгә сәламне җиткергәч, ул: «Аллаһы Үзе Әс-Сәлам, Җәбраилгә дә Әс-Сәлам, сиңа да, әй, Аллаһының Расүле, Әс-Сәлам һәм Аллаһының рәхмәте һәм бәрәкәте булсын»[1], – дип әйткән.

Икенче хәдистә килгәнчә, Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребез янына килеп: «Әй, Аллаһының расүле, хәзрәти Хәдичә сиңа бер савыт салып тәмләткечләр белән ипи (яки ризык яки эчемлек) алып килер. Синең яныңа килгәч, аңа Раббысыннан һәм миннән сәлам әйт һәм аны җәннәттә энҗедән булган йорт белән шатландыр. Анда ул ят тавышлар ишетмәс һәм ару-талуны белмәс»[2], – дип әйткән. Уйлап карагыз, Аллаһы аңа Үзе сәлам әйтте. Бу күп нәрсә хакында сөйли.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Хәдичә анабыз хакында: «Җәннәттә иң зур өстенлеккә ия булган хатыннар: Хәдичә бинте Хөвәйлид, Фатыйма бинте Мөхәммәд, Мәрьям бинте Гыймран һәм Фиргавеннең хатыны Асия бинте Мөзәһим булыр»[3], – дип әйткән.

Шулай ук Пәйгамбәребез аның хакында: «Хәзрәти Хәдичә, хәзрәти Мәрьям бөтен дөнья хатыннарыннан өстен кылынган кебек, минем өммәтемнең хатыннарыннан өстен кылынды»[4], – дип әйткән.

Пәйгамбәребез хәзрәти Хәдичә анабыз белән 25 ел яшәде. Хәдичә анабыз радыяллаһу ганһә пәйгамбәрлекнең 10 нчы елында, Расүлебезнең абыйсы Әбү Талиб үлгәннән соң берничә көн үткәч, 65 яшендә вафат булды. Ул елны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өстенә кайгы өстенә кайгы килде, бу ел шуңа «кайгы елы» дип аталды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң яраткан кешесе үлеп киткәч, ул нин-

---

1 Имам Ән-Нәсаи хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имамнар Ән-Нәсаи, Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

4 Әл-Бәззар хәдисләр җыентыгыннан.

ди зур кайгы һәм авырлык кичергәнен аңларга буладыр.

Хәдичә анабыз радыяллаһу ганһә үлгәч тә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең аңа булган көчле мәхәббәте сүрелмәде. Ул аны еш искә ала, аның дусларын, якыннарын хөрмәтли иде. Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип әйткән: «Мин, Хәдичәгә көнләшкән кебек, бер хатынга да шулкадәр көнләшмәдем. Пәйгамбәребез гел аны искә ала иде. Әгәр ул сарык чалса, аны өлешләргә бүлеп, Хәдичәнең дусларына да җибәрә иде. Бервакыт мин Пәйгамбәребезгә: «Хәдичәдән башка бу дөньяда бүтән хатын юкмы әллә?» – дип әйттем. Ул миңа: «Ул шундый-шундый иде һәм аннан минем балаларым булды», – дип җавап бирде»[1].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәти Хәдичә анабыздан бик уңды. Ул көчле рухлы, нык иманлы, хикмәтле хатын иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә ирләргә: «Хатын алганда матурлыгына, байлыгына карамагыз, диненә, әхлагына карагыз – уңарсыз», – дип киңәш бирде.

Аллаһы безнең гаиләләребезне нык кылып, безгә дә Хәдичә анабыз радыяллаһу ганһә белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм арасында булган мәхәббәтне бирсә иде. Шуңа күрә Аллаһы безгә Коръәни Кәримдә шушы doганы кылырга кушты:

رَبَّنَا هَبْ لَنَا مِنْ أَزْوَاجِنَا وَذُرِّيَّاتِنَا قُرَّةَ أَعْيُنٍ وَاجْعَلْنَا لِلْمُتَّقِينَ إِمَامًا ﴿٧٤﴾

**«Ий Раббыбыз! Хатыннарыбыздан һәм нәселебездән [бер өлешен иман һәм итагатькә ирештереп] безгә күзләргә куаныч [китерә торган хатыннар һәм балалар] бир. Һәм безне [җитәрлек гыйлемгә һәм гамәлгә ирештереп] тәкъвалык ияләре өчен имам [һәм һидаятьтә үрнәк алырлык кешеләр] ит!»**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:74

[1] Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*

*Балтач үзәк мәчетенең икенче имамы*

*11 нче март вәгазе,*

*шәгъбан аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Рамазан аен каршы алабыз

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә болай дип хәбәр бирә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Рамазан аенда һәр көн ураза тоту, ягъни таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчыга кадәр ашамый, эчми һәм якынлык кылмый тору – балигъ һәм акыллы булган һәрбер мөэмин кешегә фарыз икәнен беләбез. Аллаһы Тәгаләнең: **«Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды»**, дип әйткән сүзләре безгә кадәр булган барча халык та уразалы булганлыгын раслый. Археология белгечләренең тикшерүләре безгә кадәр дә уразасыз халык яшәмәгәнен исбатлады. Сәгыйт бине Җөбәир рахмәтуллаһи: «Безгә кадәр исламның әүвәлге ва-

кытында да уразаны кичтән алып, икенче кичкә кадәр тоталар иде», ягъни безнеңчә әйткәндә, бер тәүлек. Әмма шушы аять иңгәч, бу йола туктатылды», – дип әйткән.

Аллаһы Тәгаләнең لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ягъни «шәт тәкъвалы булырсыз», дигән сүзләренә игътибар бирергә кирәк. Раббыбыз безгә: «Ураза тотып, әлбәттә, тәкъвалы буласыз», – дип әйтми. Белүебезчә, ураза тоту ашау-эчүдән, якынлык кылудан тыелып тору гына түгел. Уразалы кешенең гайбәт, харамга карау, сүгенү, кеше рәнҗетү, яла ягу, талашу, ялганлау кебек гөнаһлардан тыелуы мөһим. Бу, тәкъва мөэмин-мөселманнар өчен, зур сынау. Әлбәттә, шунысын белик: бер генә кеше дә кимчелексез, бар яктан да камил була алмый. Раббыбыз безне төрле итеп яраткан. Шул төрлелеккә безнең зәгыйфь булуыбыз да керә. Әмма монда сүз тән зәгыйфьлеге турында гына түгел, ә нәфесебезнең безгә каршы булуы һәм шул сәбәпле, кешенең хаталануы турында әйтелә. Коръәни Кәримдә Раббыбыз:

يُرِيدُ اللَّهُ أَن يُخَفِّفَ عَنكُمْ ۚ وَخُلِقَ الْإِنسَانُ ضَعِيفًا ﴿٢٨﴾

**«...кеше [шәһвәтле тойгыларга каршы] зәгыйфь буларак яратылган»,**

– дип әйткән.

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:28

Әмма, мөхтәрәм җәмәгать, адәм баласы: «Мин көчсез. Раббыбыз мине шундый итеп халык кылган, берни эшләтә алмыйм», – дип утырырга тиеш түгел. Кешене үзенең көчсез якларын белү көчле итә. Мәсәлән, берәүләр ялганларга, икенчеләр, гайбәт сөйләүгә, өченчеләр харамга карарга гадәтләнгән була. Кеше үзе дә сизмәстән шул сыйфатлары белән гомер итәргә мөмкин. Әмма көннәрдән бер көнне ул үзенең шул зәгыйфь якларын танырга һәм алар белән көрәш башларга мөмкин. Бу урында динебездә әлеге күркәм дога барлыгын онытмыйк. Мөселман кешесе (бигрәк тә көзгегә караган вакытта) әлеге доганы уку гадәтенә ияләшергә тиеш:

اَللَّهُمَّ أَنْتَ حَسَّنْتَ خَلْقِي فَحَسِّنْ خُلُقِي

Укылышы: «Аллааһуммә әнтә хәссәнтә халькый фәхәссин хулүкый».

Мәгънәсе: «Йә Аллаһы! Сурәтемне күркәм кылган кебек, холкымны да күркәм әйлә».

Әгәр без һәрдаим шушы доганы кылуны гадәткә кертсәк, Аллаһының рәхмәте белән, холкыбызны күркәм итә алырбыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр кеше бозык сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән тыела алмаса, Аллаһы Тәгалә аның ашау-эчүне ташлавына мохтаҗ түгел», – дип әйткән.

Шуңа күрә мөселман кешесе Рамазан аена әзерләнгәндә бозык сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән тыелырга тырышырга тиеш, әгәр шулай эшләмәсә уразаның әҗерен югалтуы бар. Шулай ук Рамазан аенда җиңелрәк булсын өчен, авыр эшләребезне алдан ук бетереп куярга тырышыйк. Мәсәлән, күптәннән ниятләп йөргән эшләребез бар ди, әйтик, кемгәдер барып килү, нәрсәдер сатып алу, өйдәге кайбер эшләнәсе эшләребез. Әгәр уразалы хәлдә бу эшләр безгә кыенлык тудырасын беләбез икән, аларны йә Рамазан аена кергәнче, йә аннан соң башкара алабыз. Әмма, кыен булмаса, туганнарыбызның хәлен белергә бару, аларны чакырып кунак итү кебек әҗер-саваплы эшләребезне Рамазан аена калдыру, киресенчә, күркәм гамәл булып санала.

Бүгенге заман кешесе ризык мул һәм төрледән-төрле булган заманда яши. Элек әби-бабаларыбызның сәхәр, ифтар табыннарын бүгенге көнге табыннар белән чагыштырып булмый, билгеле. Шуңа да Раббыбыз безнең мул заманнарда тоткан уразаларыбызны кабул кылсын дип сорыйк. Ризык төрлелегенең дә үз тәртибе бар. Кайберләрен ашау сәламәтлегебезгә начар тәэсир ясарга һәм шуңа да ураза тотуыбызны авырайтырга мөмкин. Әгәр без ураза тотканда кыенлык кичерәбез икән, бу ураза тоту сәламәтлек өчен зыянлы булганга түгел, әлбәттә. Кызганычка, кайбер кеше шушы ял-

гыш фикергә ышанып, ураза тоту кебек зур әҗер-саваплы гамәлдән үзен мәхрүм итә. Авырлык дөрес тукланмау, авыр, зыянлы ризыклар ашау аркасында килеп туа. Шуңа да сәламәтлегебезнең әманәт булуын исәптә тотып, Рамазан ае башланыр алдыннан саулыгыбызга тагы да игътибарлы булыйк. Ашказаны, эчәклекләр белән кыенлыклары булган кешеләр Рамазан ае алдыннан табибларга күренеп, сәламәтлекләрен тикшертсәләр яхшы булыр. Табиб нинди дә булса дарулар язып, кирәкле киңәшләрен бирергә мөмкин. Без, үз чиратыбызда, аның күрсәтмәләренә җитди карарга тиеш булабыз, чөнки уразабызны камил итеп тотарга телибез.

Шулай ук Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйткән:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۚ فَمَن شَهِدَ مِنكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ ﴿١٨٥﴾ ۖ

**«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]. Сездән берәү Рамазан аена ирешсә, аны ураза тотып үткәрсен».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Рамазан ае – Коръән иңдерелгән ай. Шуңа да Изге Китабыбызны Рамазан аенда күбрәк укуга игътибар бирсәк иде, чөнки, белүебезчә, аның әҗер-савабы да арттырып бирелә. Калган эшләребезне кайсы вакытта эшләнәсен алдан ук билгеләп куйган кебек, Коръән уку гамәленә дә тиешле игътибар бирик. Тәүлегебезнең бер вакытын Аллаһының Китабын кулыбызга алып укуга, Раббыбызның Сүзләре хакында уйлануга багышлыйк.

Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә болай дип әйтелгән: «Кыямәт көнендә ураза гамәле һәм Коръәни Кәрим Аллаһының колы өчен шәфәгатьче булырлар. Ураза гамәле: «Йә, Раббым, мин аңа көндез ашарга

да, эчәргә дә бирмәдем. Аның өчен шәфәгатьче булырга рөхсәт ит», – дияр. Коръәни Кәрим: «Йә, Раббым, мин аңа төннәрен йокларга бирмәдем. Аның өчен шәфәгатьче булырга рөхсәт ит, – дип әйтер».

Аллаһының ураза тотарга биргән әмере һәркемгә: ирләргә, хатыннарга, яшьләргә, картларга, байларга, ярлыларга, эшчеләргә, укучыларга – барлык кешегә дә йөкләнгән. Эшнең авырлыгы, тормышның мәшәкатьле булуы, балаларның күплеге, яшьләрнең мәктәптә яки югары уку йортларында укулары ураза тотмаска сәбәп булып тормый. Фәкать ятып авырган, мәшәкатьле озын сәфәрдә булган, картлык зәгыйфьлегенә ирешкән, тоткында булган һәм йөкле, хәезле хатыннар гына гозерле булып саналалар. Картлык зәгыйфьлегенә ирешкән һәм сәламәтлекләре булмаган кешеләр, көчләре җитмәү сәбәпле, ураза тотмыйлар һәм каза да кылмыйлар. Әмма маллары булса, фидия бирәләр. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

وَمَن كَانَ مَرِيضًا أَوْ عَلَىٰ سَفَرٍ فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ ۗ يُرِيدُ اللَّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلَا يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ وَلِتُكْمِلُوا الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ ﴿١٨٥﴾

**«...ләкин кем [ураза тота алмаслык дәрәҗәдә] авыру яки сәфәрдә булса, башка санаулы көннәрне [тотарга тиеш]. Аллаһы сезгә җиңеллек тели, сезгә авырлык теләми, [ураза тотарга кирәкле көннәр] санын тутырырсыз, һәм, сезгә туры юлны күрсәткәне өчен, Аллаһыны олыларсыз [дип]. Бәлки, [Аллаһының хисапсыз нигъмәтләренә, бигрәк тә шушы рөхсәтләренә] шөкер итүчеләрдән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Белүебезчә, Коръәни Кәрим Рамазан аенда иңә башлаган, шуңа күрә Рамазан аенда Коръән уку мөстәхәб гамәл һәм аны укыган өчен дә күп

әҗер-саваплар каралган. Риваятьләргә караганда, барча илаһи китаплар нәкъ менә Рамазан аенда иңгән. Зәбур китабы – Рамазанның алтынчы көнендә, Тәүрат – уникенче Рамазанда, Инҗил китабы – унтугызынчы Рамазанда һәм Коръәни Кәрим егерме җиденче Рамазанда иңгән.

Әл-Бәгави дигән галим: «Дөреслектә, «Рамазан» дигән сүз «Рамдаа» дигән сүздән алынган, ягъни кыздырылган ташлар мәгънәсендә, чөнки алар кызу көннәрдә ураза тотканнар», – дип әйткән. Ул замандагы гарәпләр берәр айга исем бирергә теләгәндә, алар беренче чиратта, вакыйгаларга яки фасылларга карый торган булган, әмма Рамазан ае кызу көнгә туры килгәч, алар ул айга «рамазан», дип исем биргәннәр. Икенче бер галим болай дип әйткән: «Ул айны, гөнаһларны яндырганга күрә, Рамазан дип атадылар».

Рамазан уразасы икенче һиҗри елында фарыз була. Ул динебездә зарури булып тора, ә аны инкяр иткән кеше көферлеккә төшә.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Рамазан ае кергәч, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, шәйттаннар баглана», – дигән сүзләрен тапшырган. Шушы хәдистән аңлашылганча, Рамазан аенда Аллаһының рәхмәте иңәр һәм шәйтаннар бикләнер, багланыр һәм ураза тотарга комачауламаслар. Күпләребезнең сизгәне бардыр, башка айлардан аермалы буларак, Рамазан аенда ураза тоту аеруча җиңел, һәм гөнаһлар да аз кылына.

Бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне – мәгъфирәт, өченче ун көне – җәһәннәмнән котылу. Берәү бу айда үзенең малын корбан итсә, Аллаһы аны уттан саклар», – дип әйткән. «Бу айда дүрт әйберне эшләргә тырышыгыз: икесеннән сез Раббыгызның ризалыгына ирешерсез, ә калган икесенә сез үзегез мохтаҗдыр. Раббыбызның ризалыгына ирештерә торган беренче ике гамәл: «Ләә иләәһә илләллаһ» («Аллаһыдан башка

илаһ юк»), кәлимәсен даими рәвештә әйтү һәм истигъфар кылу, ягъни Аллаһыдан гөнаһларыбызны гафу итүен сорау. Ә сез мохтаҗ булган икенче гамәл – ул Аллаһыдан даими рәвештә җәннәтне эстәү һәм җәһәннәмнән сыгыну».

Пәйгамбәребез бер кодси хәдистә болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә: «Адәм баласы кылган һәр гамәл – үзе өчен, уразадан кала, чөнки ураза Минеке һәм әҗерен дә Үзем бирермен», – диде[1].

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Рамазанда минем өммәтемә биш әйбер бирелде, башка өммәтләргә ул бирелмәде: ураза тотучының авызыннан чыккан ис, миск (ислемай) исенә караганда Аллаһыга күпкә күркәмрәк; авыз ачканчы фәрештәләр уразалы кешегә истигъфар укыр; Рамазан аенда шәйтаннар бағланыр; һәр көнне ураза тоткан кеше өчен Аллаһы җәннәтне бизәп торыр; Рамазанның соңгы төнендә Аллаһы Тәгалә тулысынча аны гафу итәр. Шунда сәхабәләр: «Йә, Расүлуллаһ, ә ул Кадер кичәсеме?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез җавап итеп: «Юк, һәр кеше берәр эшен тәмамласа, ахырда хакын алыр», – дип җавап биргән.

Пәйгамбәребезнең: «Ураза тотучы кешенең ике шатлыгы бар: берсе – авыз ачкан вакытта, ә икенчесе – гөнаһыбыз гафу ителгән хәлдә, Кыямәт көнендә Аллаһы белән очрашканда», – дип әйтелгән күркәм хәдисе бар. Ураза тотучы кешенең ифтар вакытында нинди хисләр кичергәнен беләбез. Бу көне буе нәфесебезне тыя алганга куану хисләре дә, ураза тоту мөмкинлеге биргән Раббыбызга шөкеребез дә, хәләл ризыклар белән тукланыр алдыннан кичергән шатлыгыбыз да. Менә бу ләззәтле мизгелләрне кичерә алсын өчен алдан ук Рамазан аена әзерләник, аның кадерен бөтен тормышыбызга сеңдерик. Рамазан ае гыйбадәте безне сәламәтлегебез белән сынаганга күрә, алдан ук сәламәтлекләребезне

1 Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

кайгыртыйк һәм, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгалә изге ниятләребезгә күрә, безгә җиңеллеген Үзе бирер һәм безне әҗер-саваплы итәр.

Аллаһы Тәгалә күңелләребезгә ихласлык, тәкъвалык, бер-беребезне ярату, үзара берләшү хисләрен салсын, һәр җирдә дә мөэмин-мөселман булып калуыбызны насыйп итсен. Раббыбыз Аллаһы уразаларыбызны кабул әйләп, гөнаһларыбызны гафу кылсын иде. Әәмин!

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*
*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

*18 нче март вәгазе,*

*шәгъбан аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Ни өчен вакытның бәрәкәте бетте?

Кешенең иң кыйммәтле әйбере – аның вакыты. Шуңа да карамастан, күбебез вакытыбызга тиешле игътибар бирми. «Ихтыяҗ тәкъдимне тудыра», – диләр. Күңел ачу индустриясенең үсүенә карап, вакыт сарыф ителүнең тормышыбызда ни дәрәҗәдә урын алуы хакында нәтиҗә ясарга мөмкин.

Миллионнарча кешеләр бүген асылда бердәнбер әйбер – вакытны «үтерү» өчен чаралар күрү һәм булдыру белән мәшгуль. Кино, телевидение, төрле комарлы уеннар, компьютер уеннары – болар барысы да безнең иң кыйммәтле ресурсыбыз – вакытыбызны юк итү кораллары булып тора.

Иблиснең безгә каршы куллана торган иң тәэсирле чарасы – алда әле яхшы гамәлләр кылу өчен күп вакыт булуына ышандыру һәм бездә, кулдан килгәнне теләсә кайсы вакытта кабат кайтара алуыбыз хакында фикер уяту. Ләкин без шуны онытабыз: һәр яңа көн безгә бик тирән мәгънәле сүзләр белән мөрәҗәгать итә: «Әй, Адәм баласы, менә мин – яңа көн, мин синең гамәлләреңә шаһит. Син мине яхшылык өчен файдалан, югыйсә, әгәр мин китсәм, Кыямәт көненә кадәр беркайчан да кайтмаячакмын».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дүрт нәрсә турында соралмыйча, Кыямәт көнендә кешенең аягы кымшанмаячак: аның гомере һәм аны ничек уздырганы турында; аның яшьлеге һәм аны ничек кулланганы турында; аның мал-мөлкәте һәм аны нәрсәгә сарыф иткәне, аның гыйлеме һәм аның белән нәрсә эшләгәне турында».

Бу хәдистән күренгәнчә, без узган көннәребез, аларны ничек һәм нәрсәгә сарыф итүебез турында аерым соралачакбыз. Бу – яшьлек

көннәренең ни дәрәҗәдә мөһим булуын күрсәтә.

Башка бер билгеле хәдистә җиде төркем кешеләр турында әйтелә: алар Кыямәт көнендә күләгә астында булачаклар, шул ук вакытта калганнар эсселектән һәм сусаудан интегәчәкләр. Бу төркемнең берсе – яшьлекләрен Аллаһыга хезмәт итүгә багышлаган мөэминнәр. Алар Иблиснең вәгъдәләренә бирелмәгән, Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итүне соңга калдырмаган. Ул бәндәләр тормышның иң яхшы көннәре өчен иң яхшы гамәлләр сайлады һәм Аллаһы Тәгалә аларны сайлады, башкалардан өстен итте.

Шулай булгач, яхшы гамәлләрне соңга кичектерү турында фикер килгән вакытта, бу уйның кемнән килгәнен белеп торыгыз һәм үзегезне югалтмагыз.

Вакытның мөһимлеген аңлаган кешенең һәр сәгате кадерле, әмма шуңа да карамастан, бу дөньяда тормышны әһәмиятсез максатларга сарыф иткән кешеләр дә бик күп. Мондый кеше тулысынча үз тормышын әһәмиятсез максатларга ирешүгә багышларга мөмкин, ләкин ул үзенең кем булуын, бу дөньяга ничек килүен, ни өчен монда булуын һәм тормыш вакыты тәмамланганнан соң кая юнәләчәген аңларга тырышу өчен хәтта бер сәгать тә таба алмый.

Безне Аллаһы Тәгалә яратты һәм Аннан башка һичкем кешенең тормышы өчен иң хәерле гамәлләрнең нинди буласын белә алмый. Әйдәгез, бу иң мөһим сорауга җавап табу өчен, Аллаһы китабына мөрәҗәгать итик.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу – кеше омтылырга тиешле булган бердәнбер максат. Гыйбадәт белән бәйле булмаган бар нәрсә мөэмин өчен мәгънәсез. Дин белән аз таныш булучылар өчен, тормышының максаты итеп гыйбадәтне сайлаган кешеләр шулкадәр сәер һәм заһид (аскет) итеп, бөтен тормышы газаплануларда узган кеше кебек күренә. Ләкин, чынлыкта, дөньяны үзенә табыну юлы итеп сайлаган дөнья колына караганда, чын мөэмин юлы күпкә бәхетлерәк.

Беренчедән, аңа дөньядагы барлык байлыклардан баш тарту кирәкми, ул бөтен дөньяның байлыкларына ия булырга һәм, шуңа да карамастан, Аллаһы Тәгаләнең тәкъва колы булып калырга мөмкин.

Хәдисләрдә күргәнебезчә, бу дөньяда үзен һәм гаиләсен тәэмин итү һәм башкаларга ярдәм итү өчен үз вакытын сарыф иткән бәндә Аллаһы Тәгалә юлында зур гыйбадәтләр кылучылардан санала. Бөтен хикмәт – ниятебездә, Кыямәт көнендә дә ниятебезгә карата әҗерләр бирелер.

Икенчедән, хәтта ул хәерчелеккә һәм бәхетсезлеккә дучар булса да, авырулар аңа боз яуган кебек коелып төшсәләр дә, шул вакытта да ул, иман иясе булганга күрә, бу дөньяда бәхетле булачак. Әгәр дә сез күп айлар дәвамында нинди дә булса ярышларда җиңәр өчен әзерләнеп, бөтен вакытын шуңа сарыф итүче спортчыны күрсәгез, сез аны бәхетсез кеше дип әйтә аласызмы? Ул үзенең җиңүче булачагын уйлап, максат куеп йөргәндә үк бәхетле булачак. Ләкин җәннәт белән чагыштырганда ниндидер ярышларда җиңү нәрсә соң ул?! Шулай булгач, ни рәвешле кайгы-хәсрәтләрне сабырлык белән кичереп, күп вакыт сәҗдәдә һәм гыйбадәттә булып, җәннәткә өметләнеп яшәүчене бәхетсез дип санарга мөмкин?!

Пәйгамбәребезнең хәдисендә болай дип әйтелә: «Аллаһы юлында булучының хәле нинди гаҗәп. Чынлап та, аның хәлендә бөтен нәрсә аның өчен яхшы һәм бу мөэминнән башка беркемгә дә бирелмәгән. Әгәр дә аны шатландырган берәр нәрсәгә төшенсә, ул Аллаһыга шөкер итә һәм бу аның өчен хәерле булачак. Әгәр дә ул бәхетсезлеккә дучар икән, ул сабыр-

лык күрсәтә һәм бу да аның өчен хәерле булачак».

Өченчедән, Аллаһы Тәгалә гыйбадәттә тырышлык күрсәткән колларының калебләрен нурландыра һәм яктырта. Йөрәге шул якты нур белән балкыган кеше дә киң күңелле була, төннәрен намазда үткәрә. Бер изге кеше әйтүенчә: «Гыйбадәт ияләренең төннәре, күңел ачкан кешеләрнең төннәренә караганда, ләззәтлерәк».

Калебләре авыру булганнар тәкъва һәм изге кешеләрнең сүзләрен аңламый, әмма моңа карап чынбарлык берничек тә үзгәрми. Чынбарлыкта, үз тормышларын Аллаһы Тәгаләгә багышлаучылар ике дөньяда да, һичшиксез, бәхетле булачак.

Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итү юлын сайлаган кешегә кирәк булган беренче нәрсә – белем. Белем белән эшләнгән хәтта аз санлы эшләрдән дә гаять зур файда алырга мөмкин, ә белемсез, күпме генә зур эшләр булса да, алардан файда булмаска мөмкин.

Белем алу зур тырышлык таләп итә һәм бу юлга баскан кеше, беренче чиратта, вакытны контрольгә алырга һәм аны юкка сарыф итмәскә тиеш. Бары тик шулай гына олуг галимнәр ирешкән уңышка ирешергә мөмкин. Кайсыбыз белем алуга көннең бер сәгатен сарыф итә алмый? Көн саен бер сәгать булса да сарыф итсәк, без бик күп нәрсәгә ирешә алабыз. Беренчедән, без белем алуга багышланган сәгать – гыйбадәттә уздырган сәгать ул. Алай гына да түгел, бу гыйбадәтләрнең иң яхшысы дип санала. Ислам галиме Әз-Зөһри әйтүенчә: «Гыйлем алу бөтен гыйбадәтләр арасында Аллаһы Тәгалә каршында иң яхшысы». Икенчедән, дөньяви булып күренгән эшләрне дә без белем ярдәмендә изге гамәлләргә әверелдерә алабыз. Өченчедән, белем белән эшләнгән гыйбадәтнең кыйммәте күп тапкырлар арта. Шуңа күрә вакыт нинди кыйммәткә ия булуын аңлаган кешегә белем алуга көненә берничә минут булса да вакыт бирергә кирәк.

Аллаһы каршында оттырганнар арасында калмас өчен, без изге гамәлләр кылуга күп игътибар итәргә тиеш. Әмма, изгелекләребез

уңышлы булсын өчен, безгә вакытны дөрес файдаланырга өйрәнү кирәк.

Эшнең кыйммәте күп шартларга бәйле һәм гамәлләрнең кыйммәтен сизелерлек арттыра торган шартларның берсе – гамәл кылынган вакыт.

Коръәндә билгеле вакыт кисемтәләре телгә алына, бу әлеге кисемтәләрнең кыйммәтләрен ачыклый. Аллаһы Тәгалә берничә урында вакыт белән ант итә. Мисал өчен, Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә көндезге вакыт белән дә, таң алды вакыты һәм төнге вакыт белән дә ант итә.

Шулай ук, Коръәни Кәримдә елдагы айлар телгә алына һәм алар арасында дүрт ай аеруча мөһим булып күрсәтелгән. Рамазан ае, ураза ае буларак, бик мөһим. Аннан башка күп игътибар җомга көненә һәм Кадер кичәнә бирелгән.

Болар барысы да безгә вакытның мөһим булуын җиткерә һәм аны дөрес кулланырга кирәк булуы турындагы фикергә этәрә.

Бер яктан караганда, безнең тормышыбыз сәүдәгә охшаган. Сәүдәдәге кебек үк, без төп сәрмаяга (капиталга) ия – ул безнең вакыт һәм аны ничек сарыф итүебезгә карап, үзебезгә зур табыш яки зыян китерәчәкбез. Теләсә кайсы эшмәкәр үз гамәлләрен планлаштырырга, аларны анализларга һәм анализ нигезендә алга таба гамәлләр кылырга кирәклеген аңлый. Шуның кебек, без дә гамәлләребезне планлаштырырга, контрольдә тотарга һәм тәмамлагач, анализларга тиеш.

Һәр инсан үз көнен тигез шартларда башлый. Бай булсак та, ярлы булсак та, безнең 24 сәгать вакытыбыз бар. Һәркем бу бәһасез байлыкны ничек тотарга икәнен хәл итә һәм аны ни рәвешле тотуыбыз, Кыямәт көнендә хәлебезнең нинди булачагына бәйле.

Ул көнне кешеләр, Аллаһыга иман китерү сүзләрен әйтер өчен, бу дөньяда җыйган бөтен мал-мөлкәтләрен бирергә әзер булыр. Ләкин аларның беркайчан да мондый мөмкинлекләре булмаячак. Башкалар бәхет ияләре булыр, чөнки, ниһаять, аларның йокылары, изге гамәлләре дә Аллаһы хозурында гыйбадәт булып язылачак. Бу, һичшиксез, тор-

мыш мизгелләренең кадерен белгән һәм аларны юкка сарыф итмәгән кешеләр булачак.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Саләхов,*
*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече*

*25 нче март вәгазе,*

*шәгъбан аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Намазда хошугълыкны саклау

Тәкъва иясе Хәтәм Әл-Әсәмнән: «Син намазга баскач нинди хисләр кичерәсең?» – дип сораганнар. Ул болай дип җавап биргән: «Намазга баскач, Кәгъбәтулланы үземнең алдымда, ә үлемне артымда итеп тоям. Әйтерсең лә, уң ягымда җәннәт, ә сул ягымда җәһәннәм, ә үзем Сират күперендә басып торам һәм Аллаһы Тәгаләнең мине күреп торганын беләм. Мондый рухи халәттә мин рөкүгъ, сәҗдәләремне һәм, гомумән, бөтен намазымны башкарып чыгам. Намазымны тәмамлаганнан соң аны Аллаһы Тәгалә кабул иттеме әллә юкмы икәнен белмим. Шуңа да һәрдаим курку һәм борчу хисләре кичерәм».

Аллаһының рәхмәте белән намаз укырга өйрәнүчеләрнең саны арта бара. Күпләр намазның төп рөкеннәрен, аның хәрәкәтләрен, Коръәнне, дога һәм зикерләрне өйрәнә, әмма намаздагы итагатьлелек хакында оныта. Шуңа да без кешенең намаз укыганда як-ягына карану, киемен рәтләү, кашыну, иснәнү кебек халәтләренә тап булабыз. Бу – аларның намазда итагатьлелек, басынкылык күрсәтмәүләренең сәбәбе. Ә тагын күпләргә шунысы да таныш: без намаз укыганда уйларыбызның еракка киткәнен, хәл ителәсе тормыш мәсьәләләренә яисә киләчәккә планнар коруга кереп югалганын күзәтәбез. Бу халәт намаз укыганда басынкылык булмаганнан килә – безгә намазларыбызда хошугълык җитми.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә намазларын итагатьлелек белән укучы мөэминнәр турында болай дип әйтә:

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ ﴿١﴾ الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ ﴿٢﴾

**«Иман китерүчеләр хәзердән уңышка иреште [һәм өметләре гамәлгә ашты]. Кемнәр [Аллаһының хозурында булган кебек] намазларында [карарга тиешле урынга карап, бөтен әгъзаларын да тыныч тотып һәм күңелләре белән Раббыларына юнәлеп] түбәнчелеклеләр».**

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:1-2

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Күп кеше намазыннан бары тик арганлык һәм авырлык тоюны гына ала», – дип әйткән. Бүгенге көндә бу бигрәк тә әһәмиятле, чөнки Кыямәт көненең галәмәтләре үзен күбрәк сиздерә бара. Әбү Дәрдадан тапшырылган хәдистә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Беренче булып бу өммәттән намаздагы итагатьлек югалачак, хәтта намазны басынкылык белән укучы бер генә кешене дә табып булмас».

Кызганычка, кайбер мөселманнар намазда Раббыбыз белән яшерен әңгәмә алып барганлыгыбызны оныта, намазга җиңел карый һәм мондый намазны Аллаһы Тәгалә кабул итмәскә мөмкинлеген уйламый.

Бу юлларны укыгыз әле:

«Аллаһым! Син һәртөрле кимчелектән өстенсең, бөтен мактаулар Сиңа, Синең исемең бик мөбарәк, даның олугтыр, вә Синнән башка илаһ юк, Синнән башкаларга гыйбадәт кылмыйбыз. Аллаһының рәхмәтеннән ерак булган шәйтаннан сакланып Аллаһыга сыенамын. Бу дөньяда һәркемгә дә шәфкатьле, ә Ахирәттә исә мөэминнәргә генә рәхимле булган Аллаһының исеме белән. Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы исеме белән! Барча мактаулар – галәмнәрнең Раббысы [тәрбиячесе] булган Аллаһыга. [Дөньяда һәрбер колына мәрхәмәтле булган] Рахманга, [иман китерүчеләргә генә Ахирәттә мәрхәмәтле булган] Рахимгә. Хисап [Кыямәт] Көненең Хуҗасына! [Аллаһы Тәгаләгә итагать иткән коллар:] «[Ий Раббыбыз!] Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз! Безне туры юлга күндер. [Синең тарафтан] Нигъмәтләндерелгәннәрнең

юлына. Ачуың төшкән һәм [туры юлдан] адашканнарның [юлына] түгел! Минем гыйбадәтемне кабул ит. Җирдә һәм Күкләрдә булганнарга ия булган Раббыбызга хәмед-сәналәребез. Кыямәт көнендә мактау Аңа тиешле. Ул Хикмәт иясе, Үзе теләгәннәрне тугры юлга Кертүче. Аллаһым! Хакыйкатьтә, Син олуг. Минем олуг Раббыма мактау булсын. Йә, Аллаһым, Сине олуглаучыны ишет. Раббым минем! Сиңа хәмед-сәналәрем булсын. Минем Раббым Аллаһыга мактау булсын!»

Таныдыгызмы? Бу – һәркөнне намазларыбызда укыла торган дога, аять һәм зикерләрнең тәрҗемәсе. Әмма без аларны йөрәкләребездә һәм җаннарыбызда тоябызмы? Без Аллаһының безгә җавап биргәнен ишетәбезме?

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә юнәлгән һәм тулысынча үзләрен намазга тапшырган мөэминнәр барлык фанилыктан һәм үзенең «мин»еннән ваз кичә. Алар бөтен дөнья өчен ирешә алмаслыкка әйләнә, ягъни намаз вакытында үзләрен дөньядан ваз кичтерә.

Җәләлетдин Руми алар хакында болай дип әйткән: «Тәкбир әйтү белән, алар, әйтерсең лә, үзләрен корбан итеп, бу дөньядан китә».

Аннары ул намаз укучыларга болай дип әйткән: «Алар артыннан китү өчен михрабта шәм торган сыман намазда тор. Бел, намазны башлый торган «Аллаһү әкбәр» сүзләренең мәгънәсе мондый: «Йә Аллаһы! Без үзебезне Сиңа корбан итеп китерәбез. Без бар нәрсәне дә читкә ыргыттык, кулларыбызны күтәреп (ирләр колак турысына кадәр) Сиңа юнәлдек». Син корбан чалганда «Аллаһү әкбәр» сүзләрен әйтәсең. Шушы ук сүзләр үлемгә лаек булган нәфесеңне корбан иткәндә дә әйтелә. Бу мизгелдә тән – Исмәгыйль галәйһиссәламгә, ә җан – Ибраһим галәйһиссәламгә тиң. Җан тәннең түбән булган теләкләрен юк итә, шул рәвешле аны нәфестән азат кыла. Намазда «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» сүзләрен әйтү белән тән җанның корбанына әйләнә. Гыйбадәт кылучыларның рәте Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршына тезелгән кешеләр рәте кебек.

Алар Раббылары каршында хисап тота, Аңа дога белән мөрәҗәгать итә. Намазда елап басып тору, Кыямәт көнендә торгызылганнан соң, Раббыбыз алдында басып торуга тиң. Раббыбыз: «Сиңа бирелгән вакытны ничек уздырдың? Миңа нәрсәләр белән килдең», – дип сорау алачак.

Шуннан соң Җәләлетдин Руми болай дип дәвам иткән: «Син бу билгеләрне намазда күреп алырга тиеш. Бел, шулай булачак та, бу авырлыкны үзеңдә той. Игътибар белән кара, намаз сиңа нәрсә бирә, чынлыкта, аның сиңа нинди файдасы бар? Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә каршына баскач, башын күтәреп һәм төшереп ашлык бөртеген җыючы кошка тиң булма... Пәйгамбәребезнең сүзләрен истә тот: «Кешеләрнең иң начары – ул үз намазыннан урлаучы»[1].

Хошугъ – йөрәкнең Аллаһыга карата мәхәббәт һәм тәвәкәллек белән тулуы. Бу халәт күңел тынычлыгына китерә. Йөрәктә барлыкка килеп, тәндә чагылыш тапкан хошугъ ике төрле була:

1. Йөрәккә хас булганы. Бу Аллаһының Бөеклеген һәм кешенең Раббысы алдында түбән булуын тану хисе. Ул җанны Раббысының Ихтыярына баш иярgә һәм Аңа итагать итәргә мәҗбүр итә.

2. Хошугълыкның тышкы чагылышы. Бу – барлык тән әгъзаларының һәм тәннең, әлеге хисләр аркасында барлыкка килгән, итагатьлелек һәм басынкылык халәте. Мәсәлән, намаз укучы кешенең як-ягына түгел, ә бары тик алдына һәм сәҗдә кыла торган урынына каравы.

Кешенең гыйбадәт кылганда һәм, гомумән, һәрвакытта хошугълыгының нинди булырга тиешлеген без Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәм аның сәхабәләренең тормыш юлыннан таба алабыз. Бу дөньяның фанилыгын һәм киләсе дөньяның хаклыгын танып яшәгән Пәйгамбәребез бик еш әлеге хакыйкатьне истә тотып гыйбадәт кылуның мөһимлеген әйткән.

---

1 Имам Хәким, Мөстәдрәк, I, 353.

Берьюлы аңа бер сәхабә килеп: «Йә, Аллаһының Расүле, миңа кыска һәм ачык булган киңәш бир», – дип әйткән. Бу сүзгә Пәйгамбәребез: «Намазыңны гомереңдәге соңгы намаз кебек башкар. Соңыннан үкенергә туры килгән сүзләр әйтмә. Башкаларда булганны үзеңә теләмә», – дип әйткән.[1]

Бер гыйлемле шәехтән болай дип сораганнар:

– Кол намазны хошугълык һәм дулкынлану белән ничек укый ала?

Ул болай дип җавап биргән:

– Дүрт әйбер моңа ярдәм итә:

1. Пакь кәсеп.

2. Тәһарәт алганда гафил булмау.

3. Беренче тәкбир сүзләрен әйткәндә күңел халәте.

4. Намаздан соң да Аллаһыны онытмау, ягъни көндәлек тормышта да, намаздагы кебек, итагатьле һәм тәкъва хәлдә яши алу.

Намазда хошугълык халәтенә ирешә һәм аны саклап кала алыр өчен, иң баштан ниятнең булуы кирәк. Бу вакытта кемгә мөрәҗәгать итүеңне генә түгел, ә нәрсә белән, ягъни тәгаен кайсы намаз белән икәнлегеңне дә аңлау мөһим. Болар белән беррәттән йөрәктә бер генә максатны калдыру зарур – ул Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы. Пәйгамбәребез: «Гамәлләр ният белән», – дип әйтә торган булган.

Шуннан соң дөрес итеп тәкбирне әйтергә, йөрәктә Аллаһының бөеклеген тоярга кирәк. Кулларны колак яфракларына китереп, барлык дөньяви уйларны читкә кую һәм Раббыбыз алдында басып торуның ләззәтен тою мөһим.

Кыямда басып торганда, итагатьле халәттә үзеңнең күз карашыңны сәҗдә урынына юнәлдерергә, бер мизгелгә генә булса да, үзеңнең көчсезлегеңне тоярга, Аллаһы Үзенең фәрештәләре алдында мактаган элеккеге тәкъва ияләренең чылбырына тоташырга тырышырга кирәк.

[1] Имамнар Ибне Мәҗе һәм Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

Кыйраәттә һәрбер хәрефне тиешенчә әйтеп, аятьләрне дөрес уку мөһим. Болар белән бергә аларның мәгънәләре турында фикер йөртергә, аларның тормышыбыздагы чагылышын күрергә кирәк. Хәдистә: «Коръәни Кәримне укучы Аллаһы белән сөйләшүчегә тиң»[1], – дип әйтелгән. Тел аятьләрне укыганда җан да уяу булырга тиеш.

Рөкүгътагы тәсбихләрне ашыкмыйча, мәгънәләре хакында уйланып әйтергә кирәк. Сәҗдәдә тәсбихне Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә хакында уйлап укырга кирәк. Бу мизгелләрдә җан Аллаһыга тагы да якын булуын тоярга тиеш, әйтерсең лә, ул Раббысының: «Сәҗдә кыл һәм [Раббыңа] якынай»[2], – дигән, чакыруына җавап бирә.

Кәгъдәдә утырганда, ягъни «Тәшәһһүд» һәм дога сүзләрен укыганда Аллаһы каршында башны иеп, фәкыйрь кеше кебек, түбәнчелекле халәттә утырырга кирәк.

Намазны тәмамлап, ике якка сәлам биргәндә фәрештәләр белән шатлыклы очрашуыбыз белән бүлешәбез. Әгәр Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә бу намазны кабул кылса, аның әҗере җәннәт булырга мөмкин. Һәм фәрештәләрдән җавап булып әлеге сүзләр торачак:

سَلَامٌ عَلَيْكُمْ بِمَا صَبَرْتُمْ ۚ فَنِعْمَ عُقْبَى الدَّارِ

**«[Исламча яшәп] Сабыр иткәнегез өчен сәлам сезгә! Йортның ахыры [булган җәннәт] нинди күркәм!»**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:24

Намаз гыйбадәтен башкарганда хошугълык һәм итагатьлелек халәте шулхәтле мөһим, чөнки нәкъ менә алар Раббыбызның колларына котылуга таба юл ача. Коръәндә болай дип әйтелгән:

---

1 Әбү Ногайм, Хилйә 7, 99.

2 «Әл-Галәк / Оешкан кан», 96:19.

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ ﴿١﴾ الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ ﴿٢﴾

**«Иман китерүчеләр хәзердән уңышка иреште [һәм өметләре гамәлгә ашты]. Кемнәр [Аллаһының хозурында булган кебек] намазларында [карарга тиешле урынга карап, бөтен әгъзаларын да тыныч тотып һәм күңелләре белән Раббыларына юнәлеп] түбәнчелеклеләр».**

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:1-2

Хошугълык халәтенә ирешеп булмый, намаздан ләззәт алу уйдырма, дип санарга кирәкми. Югарыда искә алган сыйфатлар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намазларының сыйфаты, бу сыйфатлар Пәйгамбәребезгә ияргән сәхабәләр һәм тәкъва ияләренең намазларына да юл күрсәткеч булып торган.

Мондый сыйфатларның чыганагы – ул Аллаһыга карата булган ярату. Аллаһыны ярату – мөэминнәрнең гамәл-гыйбадәтләрендә чагылыш тапкан күңел халәте ул. Аллаһыны олуглау хисләре һәр гамәлебездә: намазда да, башка төр гыйбадәтләребездә дә безнең йөрәгебезгә кереп урнашырга һәм бездән бары тык тынычлык, иминлек, яхшылык таратырга тиеш.

Йә Раббым! Безгә иман байлыгы бир, намазларыбызны камил рәвештә башкарырга ярдәм ит, күңелләребезгә итагатьлелек, күндәмлек хисләре сал.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

*1 нче апрель вәгазе,*
*шәгъбан аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Рамазан ае якынлаша

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһии әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар итүче, безнең тәнебезгә җан иңдерүче, безне һәрдаим ризыкландырып, Үзенең Рәхмәтендә йөртүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан хәмед-сәналәребез булса иде. Расүлләрнең ахыргысына һәм Аллаһы Тәгаләнең иң яратканына – пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифәләребез булса иде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә адәм балаларына бик күп нигъмәтләрен насыйп итә һәм һәрвакыт Үзенә якынаер өчен мөмкинлекләр бирә. Һәр кешенең күңеленә сеңеп калган, хәтерендә сакланган мизгелләр бар: беренче тапкыр намазга баскан вакыты, беренче тоткан уразасы вә тәүге мәртәбә мәчет бусагасын атлап керүе. Шуларның, мөгаен, иң истә калырлыгы һәм күңелләрне җебетеп, йөрәкләргә үтеп кергәне – Рамазан аеның җитүедер. Чыннан да, үзеңне Рамазан аена әзерләү, Рамазан аенда үзеңә билгеле бер максатлар куеп, Аллаһы Тәгалә Рәхмәтенә ирешү – шуның кадәр зур бүләктер. Һәр кеше дә, мөгаен, Рамазан ае җитәрәк, шундый күңеллелек һәм шатлык белән әлеге күркәм айны көтеп аладыр. Рамазан аена әзерләнеп: «Рамазан ае җитә, күңел тынычлыгы килә», – дип куанып, шушы айны каршы аладыр. Һәрберебез үзенең беренче тапкыр тоткан уразасын исенә төшерәдер.

Рамазан ае – ул күңелләргә үтеп, безнең: «Шушы айда мин төзәләм. Шушы айда куйган бөтен максатларыма ирешәм», – дип, үз-үзебезгә әйтә торган аебыздыр. Әгәр дә карасак, һәрберебезнең билгеле бер вакыйгасы бардыр. Рамазан ае якынлашуын белүгә бөтен эшләребезне ташлап, үзебезне күркәм итеп Рамазан аена әзерли башлыйбыз. Рамазан аенда тоткан уразалар, күмәкләшеп ифтар кылулар, тәравих намазына барып, анда ничәшәр сәгать намазда басып торулар, арганлыкны сизмичә, өйләргә кайткач сәхәр кылып, иртәнге намазны укып уразага керүләр – болар барысы да бер күңелле мизгелләрдер. Бу вакытта ризыкның да үзенә күрә башка тәме бар сыман. Шушы айда йокы да туя, ураза тотарга көч тә була һәм намаз уку мөмкинлеге дә бар. Күңелдә ниндидер бер рәхәтлек хакимлек итә. Әйе, Рамазан ае хакында ураза тотучыларның күңелле мизгелләре хәтердә сакланадыр. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә карасак, ул да безгә шушы айның никадәр мөбарәк вә никадәр бөек ай икәнен ассызыклап үтә. Ә инде үзебезнең тормышыбызга карасак, бик күңелле һәм кызыклы вакыйгалар бар.

Җәмәгать, Рамазан ае якынлаша! Күңелләрдә никадәр яктылык һәм рәхмәт белән шушы айны көтеп алсак, шуның кадәр ул безнең өчен файдалы һәм матур итеп үтеп китәчәк. Гаять, бу ай бик саваплы һәм бик могҗизалы ай. Юкка гына Аллаһы Тәгалә Коръәнне шушы айда иңдермәгән. Бу ай бик күркәм. Шушы айда кылынган догалар күңелдән

аеруча да ихлас булып, җылылык белән чыга. Шушы айда укылган намазлар үзенә күрә бер ихласлык белән укыла һәм күңелгә бер җылылык бөркеп тора.

Сезгә бер вакыйга сөйләп үтәм. Моннан берничә ел элек бер кардәшебез: «Йә Раббым Аллаһы! Үзеңнең киң рәхмәтләрең белән миңа шушы елларда хәерле сәфәрләр бир», – дип дога кыла. Һәм шушы доганы кич вә иртәләрен кабатлый торган була. Көннәрдән бер көнне, Рамазан аеның уртасы җиткәч, аңа шылтыратып, хаҗга юллама барлыгы хакында хәбәр итәләр. Ә иң могҗизалысы: шушы Рамазан аенда дога кылып йокларга ятканнан соң, ул Мәккә вә Мәдинә шәһәрләрен төшендә күргән була. Ягъни Рамазан ае безгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән бер могҗизадыр.

Янә тагын бер вакыйга: күпме кеше шушы Рамазан аенда уразалар тотып, намазга баса. Күпме танышларым, кардәшләрем шушы айда ураза тотып, Аллаһы Тәгаләгә ихлас күңелдән догалар кылып, Аннан сорап тугры юл вә Аллаһы Тәгалә юлына кереп киттеләр. Бу ай бик могҗизалы һәм бик күркәм ай. Шушы айда безнең арабызда хәзерге дөньяның салкынлыгы, көнчелеге юкка чыгып, бер-беребез арасында кардәшлек арта. Шушы айда эшләнгән бөтен эшләребез үзенә күрә бер ихласлык, рәхәтлек белән, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен дип үтәләләр. Шушы айда миллиардлаган мөселман бергә ураза тота, намаз укый һәм Аллаһы Тәгаләгә догалар кыла. Әгәр без Аллаһы Тәгаләнең никадәр гөнаһлар ярлыкаганын, шушы кылынган догаларыбыз, укыган намазларыбыз тотылган уразаларыбыз барәбәренә безгә күпме бәрәкәт вә күпме рәхмәт фәрештәләрен җибәргәнен, рәхмәтен иңдергәнен белсәк, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә, еллар буе Рамазан ае булуын теләр идек. Бу ай гүя бер чишмә сыман. Шушы дөньяның салкынлыгыннан, авырлыгыннан, сынауларыннан каткан йөрәкләргә бер җылы, назлы һәм шифалы чишмә суы сыман, йөрәкләребезгә үтеп кергән бер айдыр. Бу ай безнең

өчен бик күркәм, олы һәм хөрмәтле ай. Ул айларның солтаныдыр. Бөтен мөэмин-мөселманнар шушы айларда ихлас күңелдән уразаларын тотып, бер-берсеннән гафу сорап, бер-берсеннән Аллаһы Тәгалә разый булса ярый иде, дип дога кылуларын сорый торган бер мөбарәк айдыр.

Без һәрвакыт башка җирләрдәге халыкларның үзләренең бәйрәмнәрен каршы алуларын вә аңа әзерләнеп, шуның хакта никадәр могҗизалы вакыйгалар сөйләгәннәрен күрәбез. Без – мөселманнар да шулай ук әлеге айны зурлап, Рамазанның беренче көненнән алып, ахыргы көненә кадәр Аллаһы Тәгалә белән булган элемтәне ныгытып, бер-беребезнең күңелләрен күреп, бер-беребезне гафу итеп, бер-беребездән гафу сорап, бер-беребезгә карата булган ачуларыбызны онытып, Аллаһы ризалыгы өчен гафу итәргә тырышсак иде, чөнки чын күңелдән соралган гафу үтенүләр, чын күңелдән кылынган догалар сәбәпле, Аллаһы Тәгалә, һичшиксез, безгә Үзенең рәхмәтен җибәрмичә калмас.

Газиз дин кардәшләрем! Шушы айда кулларыбызны догага күтәреп, бер-беребез өчен хәерле, бәрәкәтле тормышлар сорап, Аллаһы Тәгалә безнең тормышыбызга бәрәкәт, тынычлык, муллык сәламәтлек, хәерле гамәл-гыйбадәтләр бирүен сорасак иде, чөнки Аллаһы Тәгалә безгә һәрвакыт хәерлесен тели. Һәм без дә Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләр бәрабәренә, алар сәбәбе белән, калганнарга да хәерле тормышлар вә гамәлләр теләсәк иде. Һәм дә якыннарыбызга шушы Рамазан аеның күркәмлеген аңлатсак иде. Әле диннең тәмен татымаган, намазга басу, йә булмаса ураза тоту бәхетенә ирешмәгән якыннарыбызга, туганнарыбызга шушы Рамазан аеның никадәр олы, бәрәкәтле вә зиннәтле икәнен аңлатып, аларга матур, тәмле сүзләр белән Рамазан ае турында сөйләргә тырышсак иде. Һичшиксез, Аллаһы Тәгалә безнең дә тормышыбызга хәерле бәрәкәтләрен бирер. Никадәр кеше күбрәк ураза тотса, шуның кадәр күбрәк әҗер-саваплар һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре артыр иде.

Әй, газиз дин кадәшләрем, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә беребезне дә Үз рәхмәтеннән ташламаса иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә: «Бер кеше дә, үзенә теләгәнне кардәшенә теләмичә, иманның камил дәрәҗәсенә ирешмәс», – дип әйткән. Шушы нисбәттән, бер-беребезгә догалар кылсак иде. Аллаһы Тәгаләдән кардәшләребезнең дә сәламәтлеге, иман ныклыгы өчен, Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән хәерле гамәлләр, догалар кылып, тәүбә-истигъфарлар сорасак иде. Кылган һәрбер эшләребездән Аллаһы Тәгалә разый булсын иде, якынлашып килгән Рамазан аен Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән бик файдалы итеп үткәрсәк иде. Газиз дин кардәшләрем, һәрбер аебыз, көнебез бик кадерле. Шушы Рамазан аенда булган форсатларны файдаланыйк, чөнки киләсе елларда Рамазан аена керә алу-алмавыбызны белмибез.

Бер кардәшем әйткәнчә: «Элеккеге сыман ураза тота алсам, еллар буе ураза тотар идем. Бер генә көнен дә калдырмас идем». Бу кардәшем, кызганычка, хәзер ураза тота алмый. Шуңа да без мондый хәлләрне искә алып: «Минем бит әле Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә ирешергә тагын бер могҗизалы аем – Рамазан ае бар», – дип, нинди генә эшләр эшләсәк тә, нинди генә халәттә булсак та, кулыбызны Аллаһы Тәгаләгә догага күтәреп, Аннан сораудан иренмәсәк иде. Һәм хәерле, бәрәкәтле тормышлар кичереп, Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, шушы айда булса да, намазга басарга тырышсак иде, уразаларыбызны тотсак иде, чөнки ураза безнең рухыбызга бер ялдыр. Рамазан ае – тынычлап гыйбадәт кылып, рухыбызга ял бирә торган бер айдыр. Аллаһы Тәгалә ризалыгы белән, гамәл-гыйбадәтләребезне үтәп, шушы айны иң хәерле, иң күркәм рәвештә үткәрсәк иде.

Газиз дин кардәшләрем! Бусагабызда торган Рамазан аен, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, гыйбадәттә үткәрсәк иде. Шушы айда моңарчы калдырылган намазларыбызны һәм өстәмә нәфел намазларыбызны да укып, Коръәннәр укысак иде. Без нәрсә бирәбез – шуны алабыз. Шушы

айда иң хәерле орлыкларны чәчеп, Аллаһы Тәгалә ризалыгы, рәхмәте белән, Кыямәт көнендә шушы чәчелгән орлыкларыбызның уңышларын мулдан җыеп алуны Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә насыйп вә мәяссәр кылса иде. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Рамазан айлары мөбарәк булсын!

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

# Үрнәк затлар

# Өмме Руман радыяллаһу ганһә

**Исеме:** Зәйнәб бинте Гамер бине Өвәймир бине Габдешәмс бине Әттаб Әл-Кинания радыяллаһу ганһә.

**Куньясе:** Өмме Руман.

## Мәккәгә мәхәббәте

Өмме Руман яшьли Габдулла бине Хариска кияүгә чыккан. Аларның Төфәйл исемле уллары туган. Озакламый бу гаилә Йәмәннең Серат шәһәреннән Мәккәгә күченеп килгән. Мәккәдә аларга Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе бик нык ярдәм иткән.

## Яңа гаилә

Мәккәгә күченеп килгәннән соң, озак та үтми Өмме Руманның ире вафат булып, ул тол калган һәм аның таяныч булырдай бер кешесе дә булмаган. Котәйлә бинте Габделгоззәгә өйләнгән Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе бу тол калган хатынны кызганып, үзенә кияүгә чыгарга тәкъдим ясаган. Бу никахтан аларның Габдерахман исемле уллары һәм Гайшә исемле кызлары туган.

## Ислам динен кабул итүе

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлеге килгәннән соң, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең беренче хатыны Котәйлә бинте Габделгоззә ислам динен кабул итүдән баш тарткан. Шул сәбәпле, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе бу хатыны белән аерылган, ләкин балалары (Әсма һәм Габдулла) әтиләре белән калганнар.

Өмме Руман радыяллаһу ганһә ислам динен кабул иткән. Ул үз балаларын һәм иренең беренче никахтан булган балаларын да бертигез

күргән, бертөрле яраткан һәм күркәм тәрбия биргән.

Өмме Руман радыяллаһу ганһә ислам дине хөкемнәрен тиешенчә үтәп бырырга тырышкан, күп нәрсәләрне үзенең иреннән өйрәнгән.

Бервакыт Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе хатынының намаз гыйбадәтен үтәгән вакытта гәүдәсен әле уң якка, әле сул якка авыштырганын күргән һәм бу гамәле өчен хатынын шелтәләгән. Өмме Руман радыяллаһу ганһә үз хаталарын тиз арада төзәтергә тырышкан.

Гайшә радыяллаһу ганһәдән хәбәр ителә: «Атасы йортына килгәндә, аскы катта – Өмме Руман радыяллаһу ганһә, ә югары катта – Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе булган. Аларның икесе дә Коръән укыганнар»[1].

## Тугры хатын

Өмме Руман радыяллаһу ганһә һәрвакытта да ире өчен ныклы таяныч булган. Бигрәк тә корәешлеләр тарафыннан эзәрлекләүләр көчәйгәч, шактый авыр вакытларда, ул иренә терәк булырга, аңа ярдәм итәргә тырышкан. Түбәндәге вакыйга моңа дәлил булып тора.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән мәгарәдә, мөшрикләрдә яшеренеп яткан вакытта, алар янына Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең Габдулла исемле улы килеп, хәл белешеп йөргән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе улына өйдә булган акчаларны алып килергә кушкан. Улы әтисенең үтенечен үтәгән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең әтисе Әбү Кухафә үзенең килененә: «Әбү Бәкер өй акчаларын нәрсә өчен тотты? Үз-үзен корбан итүе генә җитмәгән, инде гаилә акчаларын да тарата», – дип әйткән. Өмме Руман радыяллаһу ганһә кайнатасы алдында иренең намуслы исемен аклап, хикмәт белән аны тынычландыра алган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән Мәдинәдә булганда, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе Габдулла исемле улына хат язган.

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Хатында гаиләсенә Мәдинәгә күченеп килүләрен үтенгән. Өмме Руман радыяллаһу ганһә балалары белән бергә авыр һәм ерак юлга кузгалган.

Өмме Руман радыяллаһу ганһә гел ирен хуплаган һәм барлык эшләрендә дә аңа ярдәм иткән. Фәкыйрь сәхабәләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәчете тирәсендә яшәгәннәр. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәллерәк сәхабәләренә болай дип әйткән: «Кемнең өендә ике кешелек ризык булса, ул ризыкны өченче кеше белән бүлешсен. Кемдә дүрт кешелек ризык булса, бишенче кеше белән бүлешсен». Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе гаиләсендә өч кеше яшәвенә карамастан, ул ун кешелек ризык китергән.

## Ана йөрәге

Мәдинәгә һиҗрәт кылган вакытта Өмме Руман радыяллаһу ганһә кызы Гайшә радыяллаһу ганһә белән бер дөягә утырганнар. Дөя чабып киткән. Шулвакытта Өмме Руман радыяллаһу ганһә үзе турында онытып: «Ий, минем кызым!» дип борчылган. Дөянең йөгәннәре кулдан ычкынып, дөя әле уң, әле сул якка чапкан. Арттарак булган кешеләр аларга ярдәм иткәннәр, дөяне туктатканнар. Шул рәвешле Өмме Руман радыяллаһу ганһә кызы Гайшә радыяллаһу ганһә белән Мәдинәгә исән-имин килеп җиткәннәр.

Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең кызы Гайшә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кияүгә чыккан. Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне мәрхүмә хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһәгә бик көнләгән. Мәрхүмә хатыныннан көнләшеп, Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип әйтә торган булган: «Расүлуллаһның хатыннарыннан Хәдичәдән көнләшкәнем кадәр беркемнән дә шулкадәр көнләшмәдем. Аның кебекне күрмәдем. Ул Расүлуллаһ өчен бик мөһим иде. Һәрвакыт корбан чалгач та, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әүвәл Хәдичәнең якыннары һәм дусларына

өлеш чыгарыр иде»[1].

Әйткәнебезчә, Гайшә радыяллаһу ганһә ирен бик көнләгән һәм бервакыт бу гамәле белән аны үпкәләткән. Кызы өчен борчылып, Өмме Руман радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Ий, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, кызым Гайшә булган хәлләр өчен бик борчыла. Гафу ит аны, җәза кылма», – дип әйткән.

Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең улы – Габдерахман бине Әбү Бәкер ислам динен кабул итәргә ашыкмаган. Әлбәттә, ана йөрәге бу хәлгә бик кайгырган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән корәешлеләр арасында Ходәйбия килешүе төзелгән елны гына Габдрахман ислам динен кабул итеп, мөселман булган. Шушы 628 нче елда Габдерахманның әнисе Өмме Руман радыяллаһу ганһә вафат булган.

Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең үлеменә кызы Гайшәгә бәйле вакыйга да сәбәп булган. Гайшә радыяллаһу ганһә хакында ялган сүзләр таралгач, әнисе Өмме Руман бик кайгырган. Бер ай дәвамында ул үзендә көч табып, кызына ныклы терәк булган. Бик авыр булса да, ул берәүгә дә начар сүз белән җавап кайтармаган. Кешеләр арасында таралган сүзләрне дә кызына сөйләмәгән, аны саклаган. Кызын тынычландырып: «Кызым, борчылма! Ант итәм, кешеләр һәрвакытта да ире өзелеп ярата торган һәм көндәшләре булган чибәр хатын турында гайбәт сөйләячәкләр»[2], – дип әйткән.

## Вафаты һәм җәннәт белән шатландырылуы

Аллаһы Тәгалә кызы Гайшә радыяллаһу ганһәне аклаган аять индергәннән соң озак та үтми, һиҗри буенча алтынчы елда Өмме Руман радыяллаһу ганһә вафат булган.

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең гәүдәсен кабергә салганда Аллаһының Расүле болай дип әйткән: «Зур кара күзле хур кызларын күрәсе килгән кеше Өмме Руман радыяллаһу ганһәгә карасын». Шул рәвешле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең җәннәттә булачагы хакында хәбәр биргән.

*Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде*

# «Нәрсә?
# Кайда?
# Кайчан?»

# Октябрь

## Түбән Кама мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Сафәр аеның 26 нчы көнендә (3 нче октябрьдә) Түбән Кама районы Трудовой бистәсендә яңа мәчет ачылды. Мәхәллә халкы мәчет салу өчен зур тырышлык күрсәтте. 2018 елда төзелешкә рөхсәт алынып, 14 июль көнне нигезе салынды. 2021 елның 10 июлендә манара һәм ай куелды, мәчетнең тирә-ягы төзекләндерелде. Мәчет берьюлы 50 кешене сыйдыра ала, аның барлык уңайлыклары булган кухнясы һәм тәһарәтханәсе, инвалидлар өчен керү-чыгу урыны (пандус) бар. Бүгенге көндә Түбән Кама мөхтәсибәтендә 23 мәчет эшли.

## Казанда Татарстан мөселман уку йортлары мөгаллимнәре форумы узды

Рабигыль әүвәл аеның 6-7 нче көннәрендә (12-13 октябрьдә) Казанда Идел мөселман белем бирү оешмалары мөгаллимнәренең еллык форумы узды. Җыенда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Быел форум Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы һәм «Традицион диннәр теологиясе һәм мәгариф даирәсендә фәнни-педагогик һәм дини берләшмәләр хезмәттәшлеге» II Бөтенрәсәй симпозиумы кысаларында узды. Форумда Татарстанда дини белем бирү үзенчәлекләре белән бәйле мәсьәләләр каралды. Моннан тыш, җыен барышында Татарстанның иң яхшы мөгаллимнәренә һәм шәкертләренә ТР мөселманнары Диния нәзарәте бүләкләре, шул исәптән, Татарстан мөфтиенең рәхмәт хатлары һәм исемле стипендияләре тапшырылды.

## «Яшь килен» проектының бишенче сезоны башланды

ТР мөселманнары Диния нәзарәте, гүзәл затларның күпсанлы үтенечләре буенча, мөселман яшьләре арасында популярлык казанган «Яшь килен» проектының яңа бишенче сезонын башлады. Санитар-эпидемиологик вәзгыятьне исәпкә алып, бу юлы “Яшь килен” проекты күбесенчә онлайн форматта уза. Анда Казан кызлары гына түгел, Рәсәйнең башка төбәкләреннән дә илледән артык кеше катнашырга теләк белдерде. Алар арасында Свердловск өлкәсе, Первоуральск, Ульяновск, Сарапул, Уфа, Пятигорск, Оренбург, Борай районы, Төмән, Екатеринбург, Чабаксар, Чиләбе, Мәскәү, Петрозаводск, хәтта Казахстан кызлары бар.

«Яшь килен» мөселман яшьләре арасында гаилә кыйммәтләрен ныгыту максатыннан гамәлгә ашырыла. Шәригать һәм татар милли гореф-гадәтләр күзлегеннән чыгып, никах темасына караган төрле мәсьәләләргә багышлана. Очрашуларда, видеодәресләрдә булачак һәм хәзерге яшь киленнәргә милли традицияләр, никахның дини һәм хокукый яклары, хатын һәм ирнең бурычлары һәм хокуклары, мәһәр һәм никах килешүе, хатын-кыз һәм ир-ат психологиясе кебек мәсьәләләр турында сөйләнә. Моннан тыш, мөслимәләр милли ашлар әзерләргә, бала карарга, кунакларны каршыларга өйрәнә ала. Спикерлар булып психологлар, юристлар, табиблар, галимнәр чакырыла.

## Казанда Рәсәйнең фәнни-белем бирү киңлегендә традицион диннәр теологиясе буенча халыкара конференция узды

Рабигыль-әүвәл аеның 8-9 нчы көннәрендә (14-15 нче октябрьдә) Казанда «Хәзерге Рәсәйнең фән-мәгариф киңлегендә традицион диннәр

теологиясе» исемле ике көнлек Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Пленар утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Конференциянең төп оештыручысы булып «Фәнни-белем бирү теология ассоциациясе» (НОТА) тора. Конференцияне оештыручылар – Рәсәй ислам институты, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе, Казан православ рухи семинариясе, Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгарифкә ярдәм фонды.

– Рәсәйнең күпсанлы халыклар һәм дини төркемнәр өчен уртак йорт булуы беркемдә дә шик тудырырга тиеш түгел. Илебезнең чикләрен яклауда, Рәсәй дәүләтчелеген төзүдә, аның икътисадын үстерүдә барча төпле халыклар катнашты. Рәсәй иминлеге халыклар арасындагы үзара аңлашуга нигезләнә. Моны дини генә түгел, дөньяви уку йортларында да аңлатырга кирәк, – диде мөфти.

## Нәзарәттә “1100 еллыкка” “Казан басма” татар милли компьютер шрифты эшләнде

Рабигыль әүвәл аеның 12 көнендә (18 октябрьдә) ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә “Казан басма” исемле махсус эшләнгән дизайнлы компьютер шрифты нигезендә җыелган Коръән басмасының электрон нөсхәсе тапшырылды. ТР мөселманнары Диния нәзарәте Идел буе Болгар дәүләтендә ислам кабул ителүнең 1100 еллыгына “Казан басма” компьютер шрифты нигезендә яңа Коръән басмасын әзерли.

«Казан басма» компьютер шрифты дөньякүләм танылган иске типографик оттискысы нигезендә ясалган. Шрифт Коръән мөсхәфләрен бастыруга яңа зур мөмкинлекләр ачачак, Коръән һәм китаплар бастыруның татар традицияләрен яңартуга һәм үстерүгә ярдәм итәчәк. Бүгенге көндә яңа басылып чыгачак Коръән басмасының текстларын Татарстан мөфтияте белгечләре тикшереп чыкты. Ул дөньякүләм кабул

ителгән “Әр-рәсем Әл-Госмани” стандартларына туры киләчәк. Басмада М.Бигиевнең “Тасхих расм хат әл-Коръән” һәм Ш.Мәрҗанинең «Фаваид аль-Мухимма» китапларында бирелгән тәкъдимнәре исәпкә алынды.

## Татарстан мөфтияте «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйт» дип исемләнгән челлендж үткәрде

Татарстан Республикасы мөфтияте сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көне уңаеннан яңа челлендж үткәрде. Челленджны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлап җибәрде, ул үзенең инстаграмдагы аккаунтында барлык теләүчеләрне акциядә катнашырга һәм челленджны башкаларга тапшырырга чакырды. Моның өчен социаль челтәрләрдә сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә атап салават әйтелгән язманы куярга һәм аны #скажисалаватпророку хештегы белән билгеләргә кирәк иде.

## Нәзарәт татарлар арасында “Оста вәгазьче” бәйгесен үткәрде

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте «Оста вәгазьче» төбәкара дини бәйгесен үткәрде. Иҗади ярыш татар-мөселман яшьләрен һәм җәмгыятен рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләргә, катнашучыларның татар телендә чыгыш ясау һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә ярдәм итте, ораторлык осталыгына ия талантлы татар шәхесләрен ачыкларга мөмкинлек бирде. Бәйге Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында һәм Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан оештырылды. Бәйгедә үз көчләрен 18 яшьтән алып 45 яшькә кадәрге ир-атлар һәм хатын-кызлар сынап карый алды. Бәйгенең төп шарты буенча алар имам,

хәзрәт һәм мәчет-мәдрәсәдә мөгаллим булырга тиеш түгел иде.

Бәяләүнең төп критерийлары – тәкъдим ителгән темага, сайланган стильгә һәм жанрга туры килү, теманы чикләнгән вакыт эчендә ача белү, сөйләмнең һәм телнең байлыгы, матурлыгы һәм дөреслеге, сөйләм темпы һәм интонациясе (сөйләм тизлеге, логик акцентлар, тонның күтәрелүе һәм түбәнәюе, пауза), аудитория белән эшләү иде.

## Татарстан мөфтиятенең "Хозур ТВ" телеканалы социаль оешмалар эшчәнлеген яктырту бәйгесендә җиңде

«Хозур ТВ» телеканалы Татарстан Республикасының социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктырту бәйгесендә җиңү яулады. Конкурс комиссиясе физик мөмкинлекләре чикле кешеләр тормышына багышланган «Счастье без границ» тапшырулары циклын югары бәяләде.

## Казан шәкертләре Мәүлид ән-Нәби уңаеннан "Хозур" интеллектуаль уеннарында көч сынашты

Казанның "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе, Коръән хафизлар әзерләү үзәге һәм Рәсәй ислам институты шәкертләре Мәүлид ае уңаеннан "Хозур" интеллектуаль уеннарында көч сынашты. Викторина "Нәрсә? Кайда? Кайчан?" форматында «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан оештырылды. Кызлар һәм егетләр Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сирасы, фикһе, гакыйдә һәм Коръән фәннәре буенча сорауларга җавап бирде. Викторинада катнашучылар ислам гакыйдәсен белү буенча яхшы нәтиҗәләр күрсәтте.

## РИИда иҗтимагый аккредитациядә катнашучы экспертларга кандидатлар аттестация узды

Рабигыль-әүвәл аеның 15 нче көнендә (22 октябрьдә) Казанда Рәсәй ислам институты базасында Ислам уку йортларын иҗтимагый аккредитацияләү буенча экспертларга кандидатлар аттестация узды. Әлеге курсларны Рәсәйнең 6 төбәгеннән (Татарстан, Башкортстан, Чечня, Дагыстан, Кабарда-Балкар, Ингушетия республикалары) экспертлыкка кандидат булган 28 кеше үтте. Кандидатлар ике атна дәвамында Ислам мәгарифе советы тарафыннан оештырылган "Дини белем бирү өлкәсендә эксперт эшчәнлеге" дигән квалификация күтәрү курсларында катнашты. Йомгаклау аттестациясендә кандидатларга мөселман дини белем бирү системасында эксперт эшенә әзер булуын, мөселман уку йорты эшчәнлеге күрсәткечләрен анализлый белүен күрсәтергә кирәк иде. Ислам мәгарифе советының иҗтимагый аккредитациясе системасы белән тулырак www.islamobr.ru сайтында, «Совет эшчәнлеге» бүлегендә танышырга мөмкин.

## Балык Бистәсендә, төзекләндерелеп, борынгы агач мәчет үз ишекләрен ачты

Рабигыль-әүвәл аеның 23 нче көнендә (29 нчы октябрьдә) төзекләндерүдән соң мәчет ачу тантанасы узды. Олы Елга мәчете – агач мәчет, ул 1879 елда, Казан губернасы идарәсе тарафыннан расланган проект буенча төзелгән. Ул чорда Лаеш өязе Олы Елга авылының беренче Җәмигъ мәчет булып саналган. Җәмигъ мәчет 1937 елга кадәр эшли. Соңрак бина хуҗалык максатларында кулланыла. Соңгы дистә еллар эчендә архитектура һәйкәле авария хәлендә булу сәбәпле, ремонт эшләрен үткәрү мөһимлеге килеп басты. 2019 елда төзекләндерү эшләре башланды, аның барышында бинаның бүрәнәдән эшләнгән үз диварла-

ры сакланып калынды, түбә кыегы, манара һәм югалган декоратив элементлар яңадан торгызылды. Тәһарәтханә салынды, яңа җылыту бинасы төзелде. Бүгенге көндә Җәмигъ мәчет архитектура һәйкәле генә түгел, мөселманнарга гыйбадәт кылу өчен төзелгән Аллаһы йорты да. Бүген Балык бистәсе мөхтәсибәтендә 44 мәчет эшли.

## Казанның 400дән артык мохтаҗ гаиләсе гошер садакасы белән тәэмин ителде

Татарстанда Диния Нәзарәте башлангычы белән тормышка ашырылган гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе үтте. Әлеге башлангыч нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасында барлыгы 577,33 тонна гошер садакасы җыелды. Мөхтәсибәтләр арасында беренче өчлекне Балык Бистәсе (75 т), Балтач (43,5 т) һәм Чирмешән (40 т) районнары алып тора. Шулай ук Питрәч районы (30 т), Чүпрәле районы (27 т), Саба районы (26 т), Биектау, Әтнә, Кукмара районнары (25-әр тонна), Мамадыш районы (20 т) зур активлык күрсәтте.

Кампания кысаларында җыелган азык-төлек хәйрия оешмаларына (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды һәм «Ярдәм» милли ислам хәйрия фондының тернәкләндерү үзәге), социаль учреждениеләргә (районнардагы картлар йортлары, балалар йортлары), мөселман уку йортларына (мәдрәсәләр, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, Коръән хафизлар әзерләү үзәге һ.б.), шулай ук турыдан-туры мохтаҗ гаиләләргә җибәрелде. Шулай итеп, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Казанның 400дән артык азкеремле гаиләсен азык-төлек белән тәэмин итте. Татарстанда 2017 елда – 160 тонна, 2018 елда – 600 тонна, 2019 елда – 1109,5 тонна, 2020 елда – 1000 тонна гошер садакасы җыеп таратылган иде.

# Ноябрь

## Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча мәдрәсәләр арасында Рәсәйкүләм олимпиаданың төбәк туры үтте

Рабигыль-ахыр аеның 13 нче көнендә (18 нче ноябрьдә) Казанда ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча олимпиаданың төбәк туры узды. Әлеге чарада Татарстанның һәм Идел буе-Урал төбәгенең урта һөнәри ислам уку йортлары шәкертләре көч сынашты. Олимпиаданы Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам мәдәниятенә һәм мәгарифенә ярдәм фонды булышлыгы белән Рәсәй ислам институты оештырды. Олимпиадада урта һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы II-III курс студентлары катнашты. Бәйге урта һөнәри дини белем бирү өчен төп һөнәри белем бирү программалары нигезендә төзелгән биремнәр буенча үткәрелде.

## Рөстәм Миңнеханов Казанны «Мөселман дөньясында беренче басма Коръән басылган шәһәр» дип игълан итәргә тәкъдим итте

Рабигыль-ахыр аеның 19 көнендә (24 ноябрьдә) Җиддә шәһәрендә «Рәсәй – ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең пленар утырышы узды. Утырышның көн тәртибе «Рәсәй – ислам дөньясы: диалог һәм хезмәттәшлек перспективалары» темасына багышланган иде. Төркем эшендә Татарстан Президенты, «Рәсәй – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Мәртәбәле кунаклар арасында Согуд Гарәбстаны короле киңәшчесе, принц Халид Әл-Фәйсал кебек башка хөрмәтле шәхесләр бар иде.

“Рәсәй – ислам дөньясы” стратегик караш төркеме утырышы барышында Рөстәм Миңнеханов 1803 елны мөселманнар әзерләгән беренче басма Коръән нәшер ителү истәлекле елы итеп билгеләү, шулай ук Казанны «Мөселман дөньясында беренче басма Коръән басылган шәһәр» дип игълан итү башлангычы белән чыкты. Ул нәкъ менә Казанда 1803 елда мөселман типографиясендә Коръәннең беренче тапкыр күпләп бастырылуын искәртте. Билгеле булганча, Нәзарәттә махсус эшләнгән “Казан басма” дизайнлы компьютер шрифты нигезендәге Коръән басмага әзерләнә.

## Казанда мөселман яшьләре «MuslimQuiz» акыл көрәшендә көч сынашты

Рабигыль-ахыр аеның 20 нче көнендә (25 нче ноябрьдә) Диния Нәзарәте бинасында мөселман яшьләре катнашындагы яңа проект – «MuslimQuiz»ның 3 нче уены үткәрелде. Чираттагы “акыл көрәше”ндә алтышар кешедән торган 19 команда һәм жюри әгъзалары катнашты. Шунысы игътибарга лаек: уенда Казан гына түгел, Яшел Үзән шәһәре яшьләре һәм студентлары да катнашты. Уен «акыл һөҗүме» форматындагы 6 раундтан торды. Биремнәр колачлы фикер йөртүне, тарихи фактлар һәм вакыйгалар белән кызыксынуны, логик мәсьәләләр чишүне, тапкырлыкны таләп итте. Уенда катнашучылар табышмакларга җавап эзләде, рәсемнәрдән танылган шәхесләрне танып белде, мантыйк мәсьәләләренә, катлаулы интеллектуаль сорауларга җавап бирде. 2021-2022 еллар сезонында «MuslimQuiz» интеллектуаль уенының 6 очрашуы узачак. Уен нәтиҗәләре буенча, иң күп балл җыйган команда кыйммәтле бүләк алачак.

## Мөселман яшьләре «Мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яратам» промоакциясе үткәрде

Рабигыль-ахыр аеның 21 нче көнендә (26 ноябрендә) Татарстан мөфтиятенең Muslimmol хәрәкәте яшьләре Казанның Мәрҗани мәчете янында "Мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яратам" акциясен уздырды. Нәзарәт волонтерлары, мәчеткә килгән халыкка җомга намазыннан соң Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үгет-нәсыйхәтләрен җиткереп, «Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы" китабын, истәлекле сумка һәм түш тамгаларын өләште. «Мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яратам" акциясе, Татарстан мөселманнарын берләштереп, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһиссәләмгә карата хөрмәт һәм ярату хисләрен күрсәтү максатыннан оештырылды.

## Яңа Чишмә районы Бакташ авылында яңа мәчет ачылды

Рабигыль-ахыр аеның 22 нче көнендә (27 нче ноябрьдә) Яңа Чишмә мөхтәсибәте Бакташ авылында тантаналы рәвештә "Мәсәния" мәчете ачылды. Анда Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары, көньяк төбәк казые, Аксубай районы имам-мөхтәсибе Равил хәзрәт Зөфәров Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламен җиткерде һәм үз вәгазендә мәчетләрнең рухи тәрбия бирүдәге роле турында сөйләде. Әлеге мәчет утызлап кешегә исәпләнгән. Хәзерге вакытта Яңа Чишмә мөхтәсибәтендә 12 мәчет эшли.

### Сигезенче сезонда “Ислам. Беренче адымнар” мәктәбе үз эшен төгәлләде

Рабигыль-ахыр аеның 25 нче көнендә (30 нчы ноябрьдә) Нәзарәтнең халык арасында зур популярлык казанган проекты – “Ислам. Беренче адымнар” мәктәбе үз эшен төгәлләде. Сигезенче тапкыр оештырылган бу төркемдә 60 кеше шәһадәтнамә алды. Алар атнага бер тапкыр 8 дәрестә тәһарәт, намаз серләренә төшенде. Шуларга өстәп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы, гакыйдә, хәләл-харам мәсьәләләрен үзләштерде. Проект – кыска вакыт эчендә Ислам нигезләрен үзләштереп, намаз укырга өйрәнүне максат иткән чара. Ул мөфтият тарафыннан беренче тапкыр 2018 елда дәгъват эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырыла башлады. Сигез сезон дәвамында әлеге курсларда 720 кеше белем алды һәм намазга басты. Белем бирү татар һәм рус телләрендә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен аерым алып барылды. Дәресләрне мөфтият белгечләре һәм хәзрәтләр бирә.

## Декабрь

### Татарстанда “Изге әманәт” бәйгесендә җиңүче иң яхшы мәчетләр һәм иң яхшы имам-хатыйблар билгеләнде

ТР Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән республикакүләм “Изге әманәт” бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. Аны үткәрү турында 2020 елның ахырында Татарстан мәчетләрен һәм имамнарны татар телле проектларны тормышка ашыруга җәлеп итү әһәмиятеннән чыгып, ТР Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов мөфти Камил хәзрәт

Сәмигуллинга тәкъдим иткән иде. Эшләргә бәя биргәндә, мәхәллә халкы, аеруча балалар һәм яшьләр арасында, милли-дини үзаң тәрбияләү буенча системалы һәм актив рәвештә тәрбияви-педагогик эшчәнлек алып баруга, татар телен, татар-мөселман гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен саклауга юнәлтелгән төрле массакүләм чаралар уздыруга игътибар бирелде. Бәйгегә килгән материаллар 6 номинация буенча бәяләнде: "Балалар өчен иң яхшы татар телле проектларны тормышка ашыручы мәчет", "Яшьләр өчен иң яхшы татар телле проектларны тормышка ашыручы мәчет", "Өлкәннәр өчен иң яхшы татар телле проектларны тормышка ашыручы мәчет", "Гаилә кыйммәтләрен ныгыту буенча иң яхшы татар телле проектларны тормышка ашыручы мәчет", "Электрон ММЧда һәм социаль челтәрләрдә иң яхшы татар телле проектларны тормышка ашыручы мәчет", "Иң яхшы имам-хатыйб".

## Татарстан мәдрәсәләре һәм хафизлар әзерләү үзәкләре арасында республикакүләм Коръән уку бәйгесе узды

Рабигыль-ахыр аеның 27 нче көнендә (2 нче декабрьдә) Татарстан мәдрәсәләре һәм Коръән хафизлар әзерләү үзәкләре арасында Коръән бәйгесе үткәрелде. Әлеге чара Казан ислам университетының «Рәшидә» рухи-белем бирү үзәге бинасында узды. Бәйгене Рәсәй ислам институты Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам мәдәниятенә һәм мәгарифенә ярдәм фонды ярдәме белән Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү чаралары кысаларында оештырды. Бәйгедә 8 мәдрәсәдән 5 кешелек берәр команда катнашты. Мәдрәсә командалары үзара Коръәннең 30нчы җөзен яттан белү буенча көч сынашты. Ә менә КИУның Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар һәм "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең Коръән ятлау үзәге шәкертләренә зуррак таләпләр куелды. Булачак Коръән-хафизлардан торган бишәр кеше-

лек ике команда Коръәннең 29, 30 нчы җөзен яттан укып ярышты.

Татарстан мәдрәсәләре арасында беренче урынны “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенең шәригать бүлеге шәкертләре командасы яулады. КИУның Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар үзәге аз гына баллар аермасы белән икенче урын яулады.

## “Горки Парк” сәүдә үзәгендә тантаналы төстә намаз уку бүлмәсе ачылды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 4 нче көнендә (8 декабрьдә) Казанның “Горки Парк” сәүдә үзәгендә рәсми рәвештә намаз уку бүлмәсе ачылды. Әлеге чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Президенты ярдәмчесе Фәрит Габделганиев, РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов катнашты. Намаз уку бүлмәсе РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе тырышлыгы белән оештырылды. Бүгенге көндә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов йөкләмәсе буенча эшмәкәрләр көче белән шундый җиде бүлмә булдырылды һәм төзекләндерелде. Алар “Казан молл”, “Мега”, “Сувар плаза”, “Караван”, “Порт”, “Тандем”, “Горки парк” сәүдә үзәкләрендә урнашты. РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең алдагы планнарында – “Южный”, “Кольцо” һәм “Парк Хаус” сәүдә үзәкләрендә намаз уку бүлмәләре ачу.

## Нәзарәтнең “Хозур” нәшрияты яңа татарча медиапроект әзерләде

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын йомгаклап һәм Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100 еллыгын каршылап, “Хозур ТВ” телеканалы эфирга чыгару өчен “Билал” исемле дөньядагы иң популяр мөселман мультфильмын татарчага тәрҗемә итте. Татар телендәге «Билал» мультфильмы эфирга 1 гыйнварда кышкы каникуллар вакытында чыгачак.

# Тарих

# Швециядә беренче татарлар: мөселман татар җәмәгатьчелегенең барлыкка килүе

Рәсми документларда татарлар үзләрен нигездә «төрекләр» дип атаган. Шуңа күрә Швеция тикшерүчеләре, архив документларын анализлаганда, кайвакыт ялгышып, сүз Төркия төрекләре хакында бара дип уйлый. Нигә татарлар үзләрен шулай атаган икән? Моның берничә сәбәбе бар:

Беренчедән, Швеция телендә tattare дигән сүз бар. Ул түбән мәгънәгә ия сүз. Бу сүз җәмгыятьнең түбән катлавындагы кешеләрне белдерер өчен кулланылган. Бик еш бу сүз белән чегәннәрне атаганнар.

Икенчедән, татарлар төрки халкына керә. Әле революциягә кадәр Рәсәй империясе татарлары үзләрен төньяк төрекләре белән тиңләштергән. Әлеге идеологиянең иң актив кешеләренең берсе танылган татар дин әһеле Ризаэтдин Фәхретдин булган. Фин һәм Швеция татарлары очрагында, 1920 еллардан башлап, Төрек республикасы элемтәләре белән төрек идентификациясе (төрек идентификациясе – беренче Бөтендөнья сугышыннан соң формалаша башлаган сәясәт ул) ныгый. 1960, кайбер очракларда 1980 елларга кадәр, фин татарлары үзләрен төньяк төрекләренә тиңләгән.

Өченчедән, 1940 елларда Швециягә күченеп килүче татарларның үзләрен төрек милләтенә кертүенең сәбәбе: Советлар Союзына тапшырылудан курку, чөнки сугыштан соң Советлар Союзы СССРдан чыгучыларны яңадан кайтартырга омтыла. Ә күпчелегенең ата-бабалары Сергач өязе Түбән Новгород губерниясе татар авылларыннан булганга күрә, татарлар, ирексезләп, Советлар Союзына кайтарылудан курыкканнар. Ә инде үзләрен төрек милләтеннән дип белдерүләре аларны бу хәлләрдән саклап калган.

Мәсәлән, Швециягә Рафат Саләх килгәннән соң, җирле хакимият аны Төркиягә җибәрергә тырыша, әмма Төрек хакимияте аны кабул итүдән баш тарта. Шул рәвешле, аңа Швециядә калу мөмкинлеге тудырыла һәм ул Швеция гражданлыгы ала.

Шулай ук Швециядә формалашкан татар җәмәгатьчелеге белән Төркия гражданины Госман Соуккан да бәйле була. Ул 1903 елда Госманлы империясенең Штип шәһәрендә (хәзерге Төньяк Македония) туа. Яшь вакытында Аурупа буенча сәяхәт итәргә ният кыла, ике ел велосипедта Аурупа буйлап сәяхәт итә һәм Финляндиягә килеп җитә. Биредә ул татар җәмәгатьчелеге турында белә һәм аларга тарих, төрек һәм Ислам нигезләрен укытучы булып урнаша. Шулай итеп, ул татар җәмәгатьчелеге булган берничә шәһәрдә эшли.

1930 еллар азагында ул, татар җәмәгатьчелеге булган, Ярвенпяя исемле фин шәһәрендә нигезләнә. Монда ул татар мәктәбенә укытучы буларак эшкә керә. 1939 елда Госман Соуккан биредә яшәүче татар кызы Әминә Нисаметдингә (1920–2010) никахлана. Аларның өч балалары туа: Туркер Соуккан исемле бер уллары һәм ике кызлары.

1948 елда Соуккан гаиләсе Швециягә күченеп китәргә карар кыла. Алар Виггбихольм шәһәрендә нигезләнеп, анда кер юу йорты ача. 1952 елда Госман Соуккан Төркиягә күченеп китәргә омтыла, әмма берничә айдан соң гаилә кабат Швециягә кайта. Госман Соуккан бик күп еллар Аурупада яшәгәнгә күрә, Төркиядәге тормышка гадәтләнмәгән була.

1956 елда Соуккан гаиләсе Швеция гражданлыгы ала. Госман һәм Әминә Соуккан кер юу һәм үтүкләү эшләре бизнесын дәвам итә. Әминә чәчтараш һөнәренә дә өйрәнеп, үзенең салонын ача. Госман Соуккан имам була һәм төрек-ислам дини һәм мәдәни ассоциациясенең актив катнашучысы була.



*Мөселман зираты өчен җир мәйданын карау вакыты. Сул яктан Хәйдәр Сәмлихан, Рафат Саләх, Госман Соуккан һәм кечкенә Туркер Соуккан. Туркер Соукканның шәхси архивыннан*

# Габделхәмид солтан сараенда: татар укытучысының хатирәләре

*Гомәр Хакан Озалп тырышлыгы белән кызыклы китап дөнья күргән. Ул болай дип атала: «Габделхәмид солтан сараенда: татар укытучысының Истанбул, Бурса шәһәре, Сюррейск полкы һәм хаҗ хакындагы хатирәләре (1906-1907)».*



*“Нурия” мәдрәсәсе җитәкчесе – ишан Нургали улы Хәсән Әл-Буави*

Бу мемуарлар тумышы белән Казан губерниясе Тәтеш өязе Морзалар авылыннан булган татар имамы, шәех, укытучы Нургали Хәсән улы Әл-Буавига (Нургали Хәсәнов) багышлана. Ул 1852 елның ноябрь аенда Морзалар авылында дөньяга килә. Биредә аның әтисе имам булып хезмәт итә. Әтисе чыгышы белән Касыйм морзалары нәселеннән. Морзалар авылы җирләре бу нәселгә рус патшасы тарафыннан бүләк ителгән була. Ә әнисе тумышы белән, шул ук өязнең Югары Балтай авылыннан. Ике авыл да бүгенге көндә Татарстан Республикасының Апас районына керә. Хәсән улы Нургали яхшы дини тәрбия алган була. Башлангыч белемне аңа әтисе – Исмәгыйль улы Хәсән бирә. Алты яшендә аны Казан шәһәренең дүртенче Җәмигъ мәчете каршындагы Исхаковлар мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр (хәзерге Зәңгәр мәчет). Аннан соң ике ел Ырынбур шәһәрендә укып, яңадан Казан шәһәренә кайта һәм абруйлы «Күл буе» мәдрәсәсенә укырга керә. Соңрак ул гыйлем алырга дип, Урта Азиягә юл тота һәм Бохара шәһәрендә танылган «Мир-Араб» мәдрәсәсен тәмамлый.

Туган якларына әйләнеп кайтканнан соң, 1886 елда Өфедә Ырынбур Мөселман Диния җыелышында имам-хатыйб һәм укытучы вазифалары-

на алынырга теләп, имтихан тапшыра.

1886 елның 12 нче декабрендә ул Буа шәһәрендәге «Нурия» мәдрәсәсенә рәсми рәвештә имам-хатыйб булып билгеләнә. Мәдрәсә шәһәрнең беренче мәхәлләсенә карый һәм яңа җитәкче ярдәме белән, Идел-Урал төбәгенең алдынгы мәдрәсәләреннән санала башлый. Хәсән улы Нургали бакыйлыкка күчкәнче, 1919 елга кадәр мәдрәсәне җитәкли.



*«Нурия» мәдрәсәсе укытучылары һәм шәкертләре. Буа шәһәре. XX гасыр башы.*

«Нурия» мәдрәсәсе өч бүлектән торган: башлангыч, урта һәм югары. 1913 елда мәдрәсәдә 12 укытучы эшләгәне, 300дән артык шәкертнең укыганы билгеле. Бирегә ул вакытта территориясе белән Буа шәһәренә кергән Сембер губернасыннан гына түгел, ә Казан, Әстерхан губерналарыннан дә килеп укыганнар.

Үзенең нәтиҗәле һәм тырыш эшчәнлеге өчен, Ырынбур Мөселман Диния җыелышы Нургали хәзрәткә ахун исемен бирә.

Болардан тыш, Нургали хәзрәтнең күпсанлы шәкертләре булган, ул суфичылык тарикатенең танылган ишан-шәехе иде. Хәзрәт үзенең тирән гыйлемнәре ярдәмендә танылган дин белгеченә әйләнә.

Нургали хәзрәт мантыйк, ислам хокукы буенча 8 фәнни хезмәт яза. Бу хезмәтләр танылган уку-укыту әсбапларына әйләнә һәм күпчелек мәдрәсәләрдә кулланыла.

Нургали Хәсән улы Әл-Буави 1919 елның 19 нчы маенда бу фани дөньядан китә. Аны Буа мөселман зиратына җирлиләр. Имам-хатыйбның эшен ике улы: Гыясетдин һәм Ибраһим дәвам итә.


*«Нурия» мәдрәсәсе шәкертләре*

«Бу язмага Госманлы империясе белән солтан Габделхәмиднең кагылышы бармы?» – дип сорарсыз. Эш шунда: 1906 елда Нургали Хәсән улы Әл-Буави улы Гыясетдинны «Даруль-Муаллимин»га укырга бирү нияте белән, Истанбулга килә.

Госманлы империясендә укытучылар әзерли торган мәктәп шулай дип аталган була.

# Татар имамының Госманлы империясе ордены белән бүләкләнүе

1906 елда Хәсән улы Нургали, улы Гыясетдинны «Даруль-Мугаллимин»га укырга бирү нияте белән, Истанбул шәһәренә килә. Госманлы империясендә укытучылар әзерли торган мәктәп шулай дип аталган була. Болардан тыш Нургали хәзрәт Бурса шәһәрендәге җылы су чыганакларына барырга теләгән.

Истанбулда ул төрле мәчетләрдә, мавзолейларда, музейларда, мәдрәсәләрдә һәм суфилар торган урыннарда булган. Шулай ук җирле китапханәләрдә үзенең китапларын калдырган. Нургали хәзрәт Госманлы империясенең танылган дин эшлеклеләре белән очраша алган. Алар арасында Ислам шәехе Җәмәлетдин әфәнде, Әбү Әл-Худа әфәнде, шәех Ибраһим Зариф һәм башкалар да булган.

Истанбулның суфилар торган җирләрендә ул зикер һәм хәтем мәҗлесләрендә, шулай ук мәчетләрдә вәгазьләр һәм нәсыйхәтләр сөйләнгән урыннарда катнашкан. Шул вакыт эчендә ул Госманлы империясенең Ислам шәехләренә дин мәсьәләсенә кагылышлы фәтваларын биргән. Мәсәлән, ирнең хатыныннан аерым торуы, һавадагы айны күзәтеп ай башын билгеләү һ.б.

Укытучының хатирәләреннән шунысы билгеле: Госманлы империясендәге кайбер гореф-гадәтләр аның өчен сәер булган. Мәсәлән, хәтем, ягъни кешеләрнең бүлешеп тулаем Коръәни Кәримне укып чыгулары һәм аннары бергәләп дога кылулары; мәхия, бу – мөселман бәйрәмнәре, бигрәк тә Рамазан ае вакытында, ике мәчет манаралары арасын янып торган фонарьләр ярдәмендә язулар һәм рәсемнәр белән бизәү.

1906 елның 1 нче сентябрендә ул солтан Габделхәмид IIнең хакимияткә килүенең 30-еллыгын билгеләп үтү тантанасының шаһиты була.

Бурсада Нургали хәзрәт җылы су чыганакларында була, истәлекле урыннарны күрә, Дагыстан шәехе Мөхәммәд Элмәле һәм шәех Шәрәфетдин белән очраша.

Әмма аның сәфәрендәге иң әһәмиятле вакыйга – ул солтан Габделхәмид II белән очрашу булгандыр. Солтанның  хәлиф, ягъни барлык мөселманнарның дин башлыгы булуын да истән чыгармаска кирәк.

Ике ай чамасы Нургали хәзрәт төрек патшасының сараенда яши һәм солтан тарафыннан игътибарга һәм мактауга лаек була. Бу вакыйга Рамазан аена туры килә.  Нургали хәзрәт солтан Габделхәмид IIгә бик нык якыная, хәтта алар бергәләп ифтар кылалар, тәравих намазларын укыйлар. Сарайдагы тәртип, әдәп буенча, хәзрәт солтан белән очрашкач, аның кулын үбә торган була. Хәтта алар берьюлы дусларча кочаклашалар да.



*I нче дәрәҗәдәге Госмания ордены лентасы wikipedia.org сайтыннан*


Ихтирам йөзеннән 1906 елның 1 нче ноябрендә солтан (рәсми указ нигезендә) Нургали хәзрәтне I нче дәрәҗәдәге Госмания ордены белән бүләкли. Бу орден белән, Госманлы империясе алдында күрсәткән хезмәтләре өчен, гражданлык хезмәткәрләрен, хәрби бүлек башлыкларын бүләкли торган булганнар. I нче дәрәҗәдәге орден кайвакытларда бриллиант белән бизәлгән. Шунысы игътибарга лаек, Госманлы империясенең ордены белән барлыгы иллеләп кеше бүләкләнгән.

Нургали хәзрәт күп тапкырлар солтанны җомга көн сәламләү һәм рәсми аудиенция (югары дәрәҗәдәге кешенең рәсми рәвештә кабул ителүе) чараларында катнашкан. Нургали хәзрәтнең мемуарлары ярдәмендә Габделхәмид IIнең кичләре һәм төннәре ничек узганын да беләбез. Солтанның әүлия булуы һәм шул вакытның суфиы булуы ха-

кында билгеле. Нургали хәзрәт бу фикерләрне раслап, солтанга илһам (Аллаһыдан бирелгән гыйлем) һәм кәшеф (калебнең күп әйберләрне аңлавы) кебек үзенчәлекләр бирелүе хакында билгеләп үтә. Хәзрәт солтанның сарай китапханәсенә кереп, сирәк очрый торган хезмәтләр белән таныша алган.

Хәсән улы Нургали өчен иң зур бүләк – ул солтанның аны улы белән хаҗга җибәрергә карар кылуы. Алар хаҗга Сюррейск полкы белән бергә кузгалганнар. Бу сәяхәт солтаннар тарафыннан әзерләнеп, Истанбулдан Мәккәгә һәм Мәдинәгә кадәр әзерләнгән махсус сакчылар белән озата барылган. Сюррейск полкы Хиҗазга кадәр атларда, качырларда һәм дөяләрдә изге җирләр өчен мөселманнар тарафыннан җыелган кыйммәтле әйберләрне һәм акчалата ярдәмне илтеп җиткерергә тиеш булган. Димәшкъка килеп җиткәннән соң, Нургали хәзрәт улы белән Бәйрутка юнәлә, ә аннан диңгез аша Хиҗазга ирешә.

Үзенең юлында алар төрле мәчетләргә, мәдрәсәләргә, мәктәпләргә, мавзолейларга, китапханәләргә керә. Шулай ук алар җирле түрәләрнең һәм галимнәрнең мәҗлесләрендә катнаша. Галимнәр белән очрашканда Нургали хәзрәт төрле сораулар буенча фәтваларын да әйтә.




*Хәсән улы Нургали хәзрәтнең истәлекләре.*
*Фотоның чыганагы: ikrakitap.com*

Күпмедер вакыттан соң Нургали хәзрәт туган ягына Буага кайта һәм «Нурия» мәдрәсәсен җитәкли башлый. Нәтиҗәдә ул ике китап нәшер итә. Анда Госманлы империясенә сәяхәте тасвирланган була: «Әл-гәвәтыйф әл-хәмидия фиссәяхәти нурия» («Нурлы сәяхәттән туган рәхмәт хисләре») китабы 1907 елда (гарәп телендә)

Казанда басыла. Бу китапны Нургали хәзрәт төрек солтанына рәхмәт булар әзерли һәм анда үзенең сәяхәтен бәян итә.

*Дамир Гайнетдинов язмасы,*

*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Мирас

# «Мине кемнәр нәрсәгә өйрәттеләр?»

Казан шәһәре Островский урамы, 15нче йорт адресы буенча урнашкан ике катлы йорт бик күп серләр саклый. Биредә сату-алу эшләре дә, никах мәсьәләләре дә хәл ителгән. Ә сугыш елларында төрле гаиләләр биредә үзләренә тынычлык тапкан. Шундый тынычлык ноктасының берсе – язучы Шәриф Камал яшәгән өч бүлмәле фатир.

Кызыл язучы Шәриф Камал гаиләсенә бу фатирны 1928 елда тапшырганнар. Шул көннән башлап, бүгенгәчә әлеге бүлмәләр язучы Ш.Камалның истәлекләрен саклый.

Пенза өлкәсендәге Татар Пешләсе авылы мулласы Камал хәзрәтнең өч улы үсә. Олысы Гыймади, мәшһүр Мисыр һәм Төркия мәдрәсәләрен тәмамлап кайткач, Санкт-Петербург мәчетләренең берсендә мулла була. Берникадәр вакыттан соң, аны Төньяк Кавказ мөселманнарының ахуны итеп сайлыйлар. Гыймади хәзрәт гаиләсе белән Дон елгасы буенда урнашкан Ростов шәһәренә, аннан соң Армавирга күчеп китә.

Камал хәзрәтнең икенче улы – «Акчарлаклар», «Козгыннар оясында», «Уяну», «Буранда», «Сәмруг кош», «Бәхет эзләгәндә», «Хаҗи әфәнде өйләнә» кебек йөзләрчә үлемсез хикәяләр, повестьлар, драма әсәрләре язган Шәриф Камал.

Давыллы-буранлы октябрь инкыйлабы килгәч тә, дөньяның асты өскә әйләнә. Хәзергә кадәр халык ихтирам иткән муллаларны, сәүдәгәрләрне, «ак якалыларны» «контр» дип игълан итәләр. 1926 елда бу шаукым Гыймади хәзрәтнең гаиләсенә дә кагыла: Гыймади хәзрәтне кулга алалар, ун елга сөргенгә сөрәләр, ә гаиләсен өеннән куып чыгаралар.

Без, Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры хезмәткәләре, әле дә булса язучы турында кызыклы яңа фактлар табып торабыз. Кайбер мәгълүматларны сезгә дә тәкъдим итәргә булдык: бу язмада сез язучы Шәриф Камалның үз куллары белән язып калдырган бер

истәлекне укый алачаксыз. Бу истәлекне язучы үзе «Мине кемнәр нәрсәгә өйрәтте?» дигән исем астында калдырган.

Бүген галимнәр Шәриф Камалның бик аз сүзле һәм һәр сүзен үлчәп кенә сөйли торган кызыл язучы буларак белә. Ләкин истәлектән күренгәнчә, Шәриф Камалның да хәзрәт әтиле һәм мәдрәсәле балачагы булган. Иң кызыгы: бу истәлекләрдән язучының дин әһелләренә карата бернинди тискәре мөнәсәбәте күренми.

Бәлки Шәриф Камалның кызыллыгы артык кызыл да булмагандыр дигән сорау туа...

Истәлек:

*«1896 елның ноябрь аенда мин Саранский өязендәге Ләбәҗә дигән авылга укырга бардым. Мондагы «гыйлем» байлыгы минем өчен байтак вакытларга җитәрлек иде әле. Монда 12 яшьлек малайлар гына түгел, 19-20 яшьлек егетлар дә (солдатка киткәнчегә хәтле) әле бик канәгатьлелек белән «гыйлем чишмәсеннән зәм-зәм суын эчеп» ятадыр иде. Хәтта солдат хезмәтен бетереп кайткан сары мыеклы шадра Салих агай һәм 35-40 яшьлек Шакир суфый да монда гыйлем кытлыгы сизмиләр. Бәлки зур комсызлык белән «Мохтәсәр шәрхы» (дини законнар жыентыгы) өйрәнү һәм күңел сабаклары ятлауларында дәвам итә иделәр.*

*Ләбәҗәдәге уку йорты безнең авылдагы төсле «мәхтеп» түгел, мәдрәсә дип атала. Аның җитәкчесе дә мулла яисә хәлфә түгел, ә «дәмулла» һәм «Бохари хәзрәт» дигән титуллар белән файдалана иде. Ул, чынлап та, 10 елдан артык вакыт Бохарада торып, иске схоластика белемнәрен нык кына үзләштергән, үзе әйтмешли, «гыйлем дәрьясына чумып кайткан» кеше. Жыйнаграк көрәк сыман коңгырт сакаллы, хатын-кызларныкына охшашлы матур, ягымлы йөзле Йосыф дәмулла үзенең шәкертләренә бик күп әйберләрне кичерә, дәрес өчен берәүне дә кысмый. Кыш буенча такмак әйтеп, экият сөйләп вакыт үткәрә торган Шакай кушаматлы, иләмсез озын буйлы*

*Мөхәммәтшага тел тидергәнен белмим. Әмма бер әйбер турында ул чиксез кырыс иде. Монда инде тел генә түгел, бик иркенләп һәм ләззәт белән кул да, камчы да тидерә. Намаз! Менә инде бу турыда сак бул. Моның авырлыгы бигрәк тә март-апрель айларында нык сизелә иде. Чөнки кояш калыкмас борын торып, иртә намазга мәчеткә барырга кирәк. Ә бу вакытларда, каһәр суккан кояш, үч иткәндәй, бездән иртәрәк калкырга тырыша. Менә шул чагында, безнең хәзрәт иртә намаздан кайтышлый, елан шикелле боргаланып торган камчы тотып (аны Салих солдат кайдандыр кулга төшереп, хәзрәткә бүләк иткән, бик әйбәт камчы иде), безнең хәлне белергә керә... Ә без, кояшның мәкереннән хәбәрсез көе, идәнгә түшәлгән хәлдә рәхәтләнеп тирләп-пешеп йоклап ятабыз. Менә инде шуннан сугыш куба. Чат Мамай сугышы! Матур йөзле ягымлы хәзрәтебезнең чырае бу вакытта ... «Яһүвә»нең иң ачуда вакытындагы чыраеннан да ачулырак төскә кергән була иде».*

*Гөлназ Рәшит кызы Җиһангирова,*
*Татар әдәбияты тарихы музее һәм*
*Ш.Камал мемориаль фатирының*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

# Фэн

# Мәзһәбләргә иярмәүчеләрне кире кагу

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Барлык мактаулар Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга тиештер. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә яраткан һәм алардан риза булган күпсанлы күркәм мактауларыбыз Аңа гына. Барлык салават-шәрифәләребез пәйгамбәрләрнең иң соңгысына, тәкъва ияләренең имамына, хакыйкый дин һәм саклана торган шәригать белән килүчегә, Кыямәт көненә кадәр өммәте хак юлда булучыга һәм начарлык теләүчеләре бернинди зыян да сала алмаган кешегә – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булсын.

Безнең көннәрдә миңа шундый фикерләрне ишетергә туры килде: мин имам Әхмәдкә һәм калган мәшһүр мәзһәбләргә иярүче һәм төрле сорауларда мәзһәб чикләреннән узучы төркемнәрне тәнкыйтьләүдән баш тартам икән. Шулай ук, имеш мин, бу гамәлләрне кылучыны тәнкыйтьләмәүнең, аның мөҗтәһид булуын яки башка мөҗтәһидкә иярүче булуын исәптә тотып, аңа хокук бирелүнең кирәклеген әйтәм.

«Ярдәм бары тик Аллаһыдан гына, Аннан гына ярдәм сорыйлар, тәвәккәл итү Аңа гына, Көч һәм Кодрәт Аңа гына хас» дигән сүзләрне әйтеп, мин болай дип җавап бирәм:

«Һичшиксез, Аллаһы Тәгалә, башка өммәтләрнең диненнән аермалы буларак, бу өммәтнең динен саклады, чөнки бу өммәттән соң, башка пәйгамбәрләрнең диннәрендә булган кебек, диндә булган үзгәрешләрне төзәтүче пәйгамбәр килмәячәк. Элек берәр пәйгамбәрнең диненнән читкә китү очраклары арта башласа, икенче пәйгамбәр килеп, Аллаһы динен яңарта иде. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бу динне сакларга вәгъдә итте: һәр гасыр саен үзгәрешләргә, читтән чыгучыларга, ялганчыларның фикерләренә һәм наданнарның аңлатма бирүләренә каршы торучылар – диннең тынычлык байрагын йөртүчеләр барлыкка килгән».

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ ﴿٩﴾

**«Һичшиксез, [алар инкяр иткән] Коръәнне Без иңдердек һәм Без [бүтән китапларыбыз арасыннан] аны [гына үзгәртелү, югалудан] саклыйбыз».**

«Әл-Хиҗр», 15:9

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Үзенең Китабын саклау бурычын Үз өстенә алган. Берәү дә Аның Сүзләренә нәрсәдер өсти яки, киресенчә, алып ата алмаган.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, үз өммәтенең тормышын җиңеләйтү максатыннан, алар аңа өйрәнә алсын өчен, Коръәннән төрле уку рәвешләре белән өземтә китерә торган булган. Ул, аңа иярүчеләр арасында яшьләр дә, олылар да, хатын-кызлар да, ирләр дә яки укый-яза белмәүчеләр дә булганга күрә, шулай эшләгән. Үбәй бине Кәгъбтән яки башка кешеләр әйткән хәдистә тапшырылганча, алар ятлаган вакытта Коръән укуының җиде төрен өйрәтүләрен сораганнар.

Аннары Ислам ерак җирләргә таралган. Мөселманнар бер-берләреннән ерак булган илләргә китеп урнашкан. Бу төркемнәрнең һәрберсе Коръәни Кәримнән үзләренә килеп ирешкән уку төре белән өземтә китергән. Бу вакытта Коръән уку формалары бер-берсенә каршы килә башлаган. Хаҗ кылганда яки башка урыннарда очрашканда алар Коръәнгә кагылышлы төрле фикер каршылыкларына төшкән.

Госман радыяллаһу ганһе хакимлек иткән вакытта, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иярүчеләр, башка өммәтләрнең үз китаплары хакында килеп туган фикер каршылыкларыннан куркып, Коръәнне укуның бер төрен генә калдыру фикеренә килгәннәр. Алар моны өммәт өчен гомумфайда дип санаганнар. Алар башка формада китерелгән өземтәләр салынган сәхифәләрне якканнар. Госман радыяллаһу ганһе

тарафыннан эшләнгән бу изге эшне сәхабәләр Гали, Хозәйфә радыяллаһу ганһүмәләр дә хуплаган. Әгәр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән вакытта да булган Коръән уку төрләре буенча фикер каршылыгы сакланса, нәрсә булыр иде? Бу вакыйгалар, Пәйгамбәребез исән вакытта, Гомәр радыяллаһу ганһенең бер аять хакында Хишам бине Хәким бине Низамны катгый рәвештә тәнкыйтьләгән вакытында була. Коръәнне уку буенча фикер каршылыгы килеп тугач, Үбәй бине Кәгъб үзенең белешмәләрне тапшыруында шиккә кала. Ул вакытта Пәйгамбәребездән аятьләрне язып баручы кайбер кешеләр, Коръәнне уку мәсьәләсендә, диннән чыккан хәлдә (мөртәт булып) үлеп киткән була, чөнки аларның йөрәкләрендә иман ныгымый. Шул сәбәпле, галимнәрнең күпчелеге Госман радыяллаһу ганһенең җәмәгатьчелеген туплаган, Коръәнне бер генә формада укырга кирәк дигән, әлеге фикерне кабул итми. Алар арасында бары тик бер төркем генә мондый укуны гамәлгә ашырган. Имам Әхмәдтән һәм имам Мәликтән риваять ителгәнчә, Коръәнне намаз вакытында да, аннан тыш вакытта да уку яки аннан тыш вакытта гына уку турында фикер каршылыклары яшәп килә.

*(Дәвамы бар)*

*«Мәзһәбләргә иярмәүчеләрне кире кагу»*

*(«Опровержение тем, кто не следует мазхабам») китабыннан тәрҗемә*

# Ураза

# Рамазан – кадерле кунак

Туган көн, яңа ел, әниләр көне кебек бәйрәмнәрне алдан ук көтеп алабыз. Һәм шундый ук зарыгу белән, Рамазан аен да көтәргә тиешбез.

Әгәр дә безгә берәр кунак килергә җыенса, без өйләребезне җыештырабыз, кунакларны матур итеп каршы алабыз, алар безнең өйдә булганда үзебезне дә гадәттәгечә түгел, ә бүтәнчәрәк тотабыз, ә киткәндә, моңсуланып озатып калабыз. Рамазан ае бик кадерле кунак.

Рамазан – мөселман тәкъвименең тугызынчы ае. Рамазан сүзе гарәп телендәге «рамада» сүзеннән чыккан һәм «кайнар», «эссе булу» дигәнне аңлата. Бу ай гарәп ярымутравындагы бик эссе һава торышына туры килә торган була.

Безнең якларда бу айны «ураза ае» дип тә йөртәләр. Әлбәттә, моның да үз нигезе бар, чөнки Рамазан ае дигәч, нәкъ менә ураза күз алдына килә. Әмма ураза тоту бу айда гына булмаганлыктан, Рамазанны аның белән генә чикләргә ярамый. Дөреслектә, бу бик фазыйләтле, бүләкләргә бай ай. Аллаһы Тәгалә бу айны калган айлардан аерып куйды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу ай турында бик күп хәдисләр әйтеп калдырды.

Әбү Габдрахман Габдулла бине Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән: «Мин Аллаһы Расүленең: «Ислам биш терәккә нигезләнә: «Аллаһыдан башка илаһ юк, Мөхәммәд – Аның Расүле», – дип, шәһадәт бирү, намаз уку, зәкят түләү, хаҗ кылу, Рамазанда ураза тоту», – дип әйткәнен ишеттем».

Пәйгамбәребез әлеге хәдистә берничә фарыз гамәлне санап китә һәм шулар арасында Рамазан аенда ураза тоту да бар. Димәк, Рамазан ае буенча без Аллаһыга якын булган гамәлне кылабыз икән. Бераз гына аңа тукталып та үтик.

## Нәрсә соң ул ураза?

Рамазан аенда иң олуг гыйбадәтләрнең берсе – ураза тоту. Ураза – Ислам диненең биш баганасының берсе, ягъни фарыз кылынган гамәл. Бохари хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ураза – калкан булып тора, ураза тоткан кеше һәрбер әдәпсез эштән читләшсен һәм үзен дорфа кешеләр кебек тотмасын. Әгәр дә берәр кеше аның белән талашырга теләсә яки тирги башласа, ике тапкыр: «Мин уразамын», – дип әйтсен. Җаным Аның кулында булган (Аллаһы) белән ант итәм, ураза тотучының авызыннан килгән ис Аллаһы Тәгалә каршында хушбуй (гамбәр) дәрәҗәсендә. Һәм Аллаһы Тәгалә: «Ул ашау-эчүдән һәм теләкләреннән Минем өчен тыелып тора. Бу уразасын да ул минем өчен тота һәм аның өчен әҗерен дә Мин Үзем бирермен, ә (кылган) бер изге гамәл өчен (әҗер-савабы) ун тапкыр артык булачак», – дип әйтте».

Ураза гарәп телендә «саум» – тыелу дигәнне аңлата. Ураза тотуның нигезе – тыелып тору. Без бу айда ашау-эчүдән, начар гамәлләрдән, начар сүзләрдән (гайбәт, ялган, бохтан, яла-ягу һ.б.) читләшеп торабыз, чөнки бу уразаның кабул булу шарты да булып тора. Әмма калган айларда бу гамәлләрне кылырга ярый дигән сүз юк, киресенчә, бу айда үзеңне тәрбияләп, калган айларда да шундый ук яшәү рәвеше алып барырга кирәк.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөэмин ураза тотып та, ачлыктан башка бер нәрсәгә дә ирешмәскә мөмкин», – дип әйткән. Рамазан аенда безнең күзебез дә, колагыбыз да, телебез дә, йөрәгебез дә ураза тота. Ураза тотучының йөрәге тәкәбберлектән, көнчелектән, икейөзлелектән, ачудан пакь булыр. Тик иң мөһиме, ураза тоту – Аллаһыга гыйбадәт кылу икәнен онытмасак иде.

## Рамазан ае фазыйләтләре

Рамазан аеның бер фазыйләте булып, шәйтаннарның ай буе богауда булулары тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан ае килү белән җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, ә шәйтаннар богауланып куела», – дип әйткән. Бу, вәсвәсә кыла торган шәйтаннарның булмавы, шуңа да бик күп итеп изге гамәлләр кылып калу мөмкинлеге була, дигәнне аңлата. Ә кем дә кем үзен изге гамәлләр кылырга ияләштерә, ул Рамазаннан соң да шулай ук дәвам итәчәк. Гомумән, кешенең уразалы булган көне уразасыз көненнән аерылып торырга тиеш. Ә шәйтаннарның богауда булуы моңа ярдәм итә.

Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазанның беренче төне җитү белән шәйтаннар һәм тыңлаусыз җеннәр богауланып куелалар. Җәһәннәмнең ишекләре ябыла һәм аларның берсе дә ачылмый. Җәннәт ишекләре ачыла һәм аларның берсе дә ябылмый. Соңыннан бер кычкыручы: «Йә, яхшылык теләүче, монда кил. Йә, начарлык теләүче, тукта», – дип кычкырыр. Һәм һәрбер кичәдә Аллаһы Тәгаләнең уттан котылган бәндәләре булыр», – дип әйткән.

Бу хәдискә шәрех бирүче галимнәр, «җәннәт ишекләре ачыла», дигән гыйбарәне Аллаһы Тәгаләнең җиргә бик күп нигъмәтләре иңә дип аңлаттылар. Шулай ук бу айда шәйтаннар богауга куела. Рамазан ае – гамәлләр өчен бик күп саваплар языла торган һәм шулай ук начарлыклар өчен дә гөнаһ дәрәҗәсе арта торган ай. Шәйтаннарның булмавы кешегә изгелекләрне күбрәк кылырга, явызлыклардан читләшергә булыша. Бу хәдистән аңлашылганча, шәйтаннар белән җеннәр бер сүз түгел. Шәйтан – «шәтана», ягъни «ерагайган» дигән сүздән чыккан һәм «Аллаһының рәхмәтеннән ерагайган», дигәнне аңлата.

Алга таба Пәйгамбәребез: «Соңыннан хәбәр җиткерүче бер фәрештә: «Йә, яхшылык теләүче, монда кил. Йә, начарлык теләүче, тукта», – дип әйтә. Рамазанда яхшылык кылуга чакыру да, яхшылыкны эшләү дә бик

күп савапларга ия. Шулай ук гөнаһ дәрәҗәсе артканга күрә, тукталып торырга кушыла.

Иң соңыннан: «Һәм һәрбер кичәдә Аллаһы Тәгаләнең уттан котылган бәндәләре булыр», – дип тәмамлады. Кайбер галимнәребез моны һәр кичтә дип, ә кайберләре авыз ачкан вакытта була, дип әйттеләр. Әмма, ничек кенә булмасын, Аллаһы Тәгалә Рамазан аена тагын бер бүләк биргән, ул да булса Аллаһы Тәгалә – җәһәннәмгә керергә лаеклы кешеләрне дә бу ай хакы-хөрмәтенә уттан азат итә икән.

Уразаның тагын бер фазыйләте: авыздан килгән иснең Аллаһы каршында күркәм булуы. Ураза тотучыларның күбесе ул исне авызда барлыкка килә дип уйлыйлар. Әмма табиблар аны ашказаны чистарыну белән бәйләп аңлаталар. Кеше ураза тота-тота, ашказанындагы тупланган матдәләрдән арына башлый. Шуңа күрә ураза тотучы гыйбадәт кылып кына калмый, аңа өстәп, үзенең сәламәтлеген дә яхшырта икән.

Тагын бер фазыйләт: ураза тоткан өчен әҗер-савапны Аллаһы Тәгалә Үзе билгели. Намаз укыган өчен фәлән кадәрле, садака өчен фәлән кадәрле савап языла, дип сөйләнсәк тә, ураза өчен савапның билгеле булмавының берничә уңай ягы бар. Беренчедән, кеше ураза өчен бик күп савапларга өмет итә ала, чөнки 10, 20 генә дип әйтелмәгән. Икенчедән, кеше: «Мин 30 көн буе ураза тоттым, минем инде шуның кадәрле изгелекләрем бар», – дип, үз-үзен юата алмый һәм шулай итеп, тәкәбберлектән саклана.

Рамазан аеның тагын бер фазыйләте: ифтар ашлары. Ураза тотучыны авыз ачтырган өчен, ураза тоткан кеше кадәрле савапка ирешеп була. Ә ураза тотучыга савап билгеле түгел, аны Аллаһы Тәгалә Үзе билгели. Башка бер риваятьләрдә: «Ураза тотучыны авыз ачтырган кешегә бер кол азат иткән кадәр савап языла», – дип әйтелә. Һәм, әлбәттә, без бу форсатлардан файдалана белергә тиешбез.

Уразаның озынлыгы бер ай. Фазыйләт булмыйча, ни булсын. Бер ай дәвамында рәхәтләнеп гыйбадәт кылырга, ураза тотарга, начар

гадәтләрдән арынырга була. Әйе, кемдер өчен бу артык күп булып тоела аладыр. Әмма, беренчедән, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا

**«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286

Икенчедән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Рамазан – сабырлык ае. Сабырлыкның савабы исә җәннәттер», – дигән хәдисен дә исебезгә төшерик. Рамазан тулысы белән бәрәкәтле ай: аның иртәсе дә, киче дә, көндезе дә, төне дә бәрәкәтле.

Рамазан ае – ул ярышу ае. Юмарт вә Рәхимле Аллаһы Тәгалә Үз колларына да бер-берләренә карата рәхимле вә юмарт булырга өнди. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм иң юмарт кешеләрнең берсе иде, ә Рамазанда ул тагын да юмартрак булган. Хәдисләрдә әйтелгәнчә: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм яхшы гамәлләр кылуда искән җилгә караганда да юмартрак иде».

## Кадер кичәсе

Рамазан аен ел буе сагынып көтсәң дә, изге көннәр сизелми дә үтә. Раббысына тугры булган бәндә көн саен кадерле вакытларын изге гамәл кылуга, Коръән укуга багышлый. Тоткан ураза калебләрне йомшарта, үтәгән намазлар кешене сабыр, әхлаклы итә, укыган аятьләр гафиллектән уята. Тән итагать кыла, тел зикер итә, җан уйлана, гыйбрәт ала.

Кунакның китәр вакытлары җиткәч, кадере арта. Шулай ук Рамазанның ахыргы 10 көне дә безнең өчен аеруча гыйззәтле. Ул көннәрдә иман әһеленең изгелекләре өстәлә, «Рәхмәтенә ирешермен, гөнаһымнан пакьләнермен, уттан котылырмын», – дигән өметләр арта.

Гайшә радыяллаһу ганһә: «Аллаһы Расүле Рамазанның ахыргы ун көнендә башка көннәргә караганда ныграк ижтиһад, тырышлык күрсәтте», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ул көннәр турында болай дигән: «Рамазанның ахыргы 10 көне – ул җәһәннәм газабыннан котылу көннәре».

Рамазан аеның иң мәртәбәле көннәрендә Коръән иңдерелгән Кадер кичәсе яшеренеп тора. Бу кичәдә әҗер-саваплар бергә – мең бәрабәрендә языла. Бу кичәнең тулы кадерен һәм кыйммәтен бары тик ураза тотып, үз нәфесләрен тәрбияли алган кешеләр генә, нечкә күңелләр, ихлас коллар гына тоя аладыр. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةِ الْقَدْرِ ﴿١﴾ وَمَا أَدْرَاكَ مَا لَيْلَةُ الْقَدْرِ ﴿٢﴾ لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ ﴿٣﴾ تَنَزَّلُ الْمَلَائِكَةُ وَالرُّوحُ فِيهَا بِإِذْنِ رَبِّهِم مِّن كُلِّ أَمْرٍ ﴿٤﴾ سَلَامٌ هِيَ حَتَّىٰ مَطْلَعِ الْفَجْرِ ﴿٥﴾

**«Һичшиксез, Без аны [мәңгелек могҗиза булган Коръәни Кәримне] Кадер кичәсендә [Ләүхүл-Мәхфүздән тулы килеш беренче кат күккә] иңдердек. Кадер кичәсенең нинди икәнен син каян белә аласың? Кадер кичәсе [Кадер кичәсе булмаган] мең айдан да хәерлерәк. [Шул сәбәпле, аңарда кылынган изге гамәл сиксән өч ел да дүрт ай буена бертуктаусыз кылынган гамәлгә тиң генә түгел, аннан да фазыйләтлерәк]. Ул кичәдә, Раббыларының рөхсәте белән, фәрештәләр һәм Рух [дип тә аталган Җәбраил [галәйһиссәлам] һәртөрле эш өчен иңәләр. Таң атканчы [фәрештәләр очраткан һәр иманлы ир һәм хатынга сәлам биргәннәре өчен] ул [кичә] иминлек [булыр]».**

«Әл-Кадр / Кадер киче», 97:1-5

## Ни өчен соң ул төн «Кадер киче» дип аталды?

Кадер – ул «кодрәт», бу төн Аллаһы каршында иң кодрәтле һәм иң хөрмәтле төндер. Аның икенче мәгънәсе – «тәкъдир», бу төндә ел әйләнәсенең язмышы тәкъдир кылына. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

فِيهَا يُفْرَقُ كُلُّ أَمْرٍ حَكِيمٍ ﴿٤﴾

**«Анда һәр хикмәтле эш аерыла».**

«Әд-Духан / Төтен», 44:4

Бу кичәдә фәрештәләр адәм баласының берьеллык тәкъдирен алып киләләр. Соңрак Кадер төнен Коръән иңү белән үзенчәлекле иткән Аллаһы, ул төннең тагын бер өстенлеген бәян итеп: «Кадер төне мең айдан хәерлерәк», – дип әйтә. Ул төнне догада, гыйбадәттә, зикердә, намазда үткәргән бәндә мең ай гыйбадәт кылудан да зуррак әҗер алачактыр.

## Мең ай – ул 83 ел һәм 4 ай була

Ул төндә җир йөзенә Аллаһы кешеләргә тәкъдир кылган һәрбер яхшы вә яман эш белән Җәбраил галәйһиссәлам һәм башка фәрештәләр төшәләр. «Ул таң беленгәнче иминлектер», ягъни Кадер төнендә җир өстенә төшкән фәрештәләр бәрәкәт, тынычлык һәм хәерлелек белән төшәләр. Бигрәк тә ул фәрештәләр Коръән укучылар, Аллаһыны зикер итүчеләр һәм гыйлем эстәүчеләр белән бергә булалар. Шәйтан да ул төнне үзенең мәкерлекләрен кыла алмый.

Кадер төне кайчан була? Мөселманнар өчен айлар арасында Рамазан ае, көннәр арасында җомга көне, кичләр арасында Кадер кичәсе иң мөбарәк санала. Кадер кичәсе Рамазан-шәриф аенда булган бер кичәдер. Шул ук вакытта Рамазанның кайсы кичәсендә булганы төгәл һәм ачык рәвештә билгеләнмәгән. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кадер төне – Рамазанның ахыргы ун төнендә. Кем аларны уяу үткәрсә, Аллаһы аның кылган һәм кылачак гөнаһларын кичерер. Бу – так санлы төндә: 23, 25, 27, 29ында», – дип әйткән.

Кадер төненең үз галәмәтләре бар. Галимнәр билгеләп үткәнчә, Кадер кичәсен кайбер галәмәтләрдән, шул кичкә хас булган аерым билгеләрдән тәгаенләргә мөмкин: бу кичә нурлы, тыныч һәм матур булыр; бик салкын да, бик эссе дә булмас; ул кичтә болытлар йөрмәс һәм җил исмәс, һавадан йолдызлар атылмас, яңгыр яумас, барча җиһанда тылсымлы тынлык урнашыр. Шул төн арты кояш, нурсыз пакь тулы ай кебек чыгар.

Кадер кичәсе гыйбадәте: бу кичә Аллаһының рәхмәте бик мул булган бер кичәдер. Көндез ихтыяҗы булганнарга мөмкин кадәр ярдәм итәргә, авыз ачканда фәкыйрьләрне ашатып-эчертергә, кичен Коръән укып, гыйбадәт кылып, үткәрергә кирәк. Гыйбадәттә каза намазын кылу, Коръәни Кәримнән сүрәләр, догалар уку, тәүбә итү, садака бирү, мөселманнарны сөендерү һәм башка саваплар казану – болар барысы да бу кичәгә хөрмәт күрсәтүнең ишарәседер. Хөрмәт күрсәтү гөнаһлы эшләрне эшләмәү белән дә хасил булыр.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү, Аллаһы Тәгаләгә инанып һәм савабына өметләнеп, Кадер кичәсен гыйбадәт кылып уздырса, элек кылган гөнаһлары гафу ителәчәк», – дип әйткән.

Шулай ук кайбер риваятьләрдә Кадер кичәсендә иң азы – ике рәкәгать, уртача – йөз рәкәгать, ә иң күбе – бер мең рәкәгатьле намаз укылуы хәбәр ителә.

Бу намазны нәкъ шул рәвешле уку мәҗбүри түгел, әмма аны болай уку мәслихәт булуын хәбәр итә торган риваятьләр бар. Төп максат булып, мөселманнарның бу төнне гыйбадәт һәм зикердә үткәрүе тора.

Кадер кичәсендә укыла торган дога. «Хәзрәти Гайшә радыяллаһу ганһә: «Йә, Расүлуллаһ, Кадер кичәсенең кайсы кичә икәнен белсәк, ул

кичтә ни дип әйтергә кирәк?» – дип сораганына, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу доганы укырга кушкан:

اللَّهُمَّ إِنَّكَ عَفُوٌّ كَرِيمٌ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّى

«Аллаһуммә иннәкә гафүвүң кәриимүң, түхиббүл-гафүә, фәгъфү ганнии».

Мәгънәсе: «Йә, Аллаһым, һичшиксез, Син Гафу кылучы, Син икрам Иясе, Син гафу итәргә яратасың, мине гафу ит».

## Тәравих намазы турында бер-ике сүз

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә бу айда ураза тотуны – фарыз, ә төннәрен намазда үткәрүне сөннәт итеп кылды», – дип әйткән. Галимнәребез «төннәрен намазда үткәрү», дигәнне «тәравих намазы», дип әйтәләр. Чыннан да, Рамазан аенда уразадан кала икенче зур гамәл – ул тәравих намазы. Тәравих намазы Рамазан аенда укыла. Ул 20 рәкәгатьтән тора. Тәравих намазы ирләр һәм хатыннар өчен, ураза тотучылар өчен дә, берәр төрле авыру яки сәфәрдә булу сәбәпле, ураза тотмаучылар өчен дә, сөннәт мүәккәдә булып санала. Тәравих намазын мәчеттә уку – сөннәт, аны үтәгән өчен зур савап вәгъдә ителгән. Әмма әлеге намазны өйдә ялгызың гына укысаң да ярый.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аенда, бу айның изге ай икәнлегенә ышанган хәлдә һәм әҗер-савабын бары тик Аллаһыдан гына өмет итеп, тәравих намазын кылучыга аның барлык элеккеге гөнаһлары кичерелә», – дип әйтә. Шулай ук ул: «Аллаһы Рамазан аенда ураза тотуны сезнең өчен бурыч иткән. Ә мин аның төнендә кыямда торуны, ягъни тәравих намазын сөннәт иттем. Кем иманлы йөрәк белән, савап алу теләге белән Рамазан аенда ураза тотса һәм тәравих намазын укыса, гөнаһлардан котылыр, яңа туган сабый бала сыман булыр», – дип әйтә.

Тәравих намазын бары тик ястү намазыннан соң гына укырга була. Рамазан аенда витр намазы тәравих намазыннан соң укыла. 20 рәкәгатьле тәравих намазында сәламне һәр ике рәкәгатьтән соң яки һәр дүрт рәкәгатьтән соң бирергә була. Тәравих сүзе «ял итеп алу» дигән сүздән килеп чыккан. 20 рәкәгатьле тәравих намазын бишкә бүлеп ял итүебез дә шуны аңлата. Шушы ял итү вакытында түбәндәге зикерне әйтү динебездә күркәм гамәлләрдән санала. Гадәттә, аны мәкам белән, матур итеп көйләп укыйлар.

*Рамазанның 1-20 нче көннәрендә укыла торган зикер:*

سُبْحَانَ ذِي الْمُلْكِ وَالْمَلَكُوتِ سُبْحَانَ ذِي العِزَّةِ وَالعَظَمَةِ وَالْقُدْرَةِ وَالْكِبْرِيَاءِ وَالجَبَرُوتِ سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَيِّ الَّذِي لَا يَمُوتُ سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّنَا وَ رَبُّ الْمَلاَئِكَةِ وَ الرُّوحِ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ نَسْتَغْفِرُاللَّه نَسْأَلُكَ الْجَنَّةَ وَ نَعُوذُبِكَ مِنَ النَّارِ

«Сүбхәәнә ẓил-мүлки вәл-мәләкүүт. Сүбхәәнә ẓил-гыйззәти вәл-гаẓамәти вәл-кудрати вәл-кибрийәә-и вәл-җәбәруут. Сүбхәәнәл-мәликил-хәййил-ләẓии ләә йәмүүт. Сүббүүхүн куддүүсун раббүнәә вә раббүл-мәләәикәти вәрруух. Ләә иләәһә илләллааһу нәстәгъфируллааһ. Нәс-әлүкәл җәннәтә вә нәгууẓү бикә минән нәәр».

Мәгънәсе: «Яшерен вә ачык булган һәрнәрсәнең Иясе Чиста вә Пакь. Көч-Куәт, Бөеклек, Күркәмлелек Иясе Чиста вә Пакь. Ул Мәңге Исән һәм беркайчан да үлмәс. Камиллек Иясе, Кимчелексез, Ул – безнең Раббыбыз, фәрештәләрнең һәм җаннарның Раббысы. Аллаһыдан башка илаһ юк һәм без Аннан гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә, Раббым, без Синнән җәннәт сорыйбыз һәм ут газабыннан сыенабыз».

*Соңгы ун көнендә укыла торган зикер:*

سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَنَّانِ الْمَنَّانِ، سُبْحَانَ الْمَلِكِ الدَّيَّانِ، اَلْمَعْرُوفِ بِالْغُفْرَانِ وَالْمَوْصُوفِ بِالْإِحْسَانِ. اَلْوَدَاعُ اَلْوَدَاعُ اَلْفِرَاقُ اَلْفِرَاقُ يَا شَهْرَ رَمَضَانِ. اَللَّهُمَّ يَا قَدِيمُ يَا حَكِيمُ يَا عَلِيمُ اِغْفِرْلَنَا يَا كَرِيمُ يَا رَحِيمُ يَا حَلِيمُ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

«Сүбхәәнәл мәликиль хәннәәнил мәннәән. Сүбхәәнәл мәликид дәййәән. Әлмәгъруруфү билгуфраан. Әлмәүсууфү биль ихсәән. Әлвәдәәгъ. Әлвәдәәгъ. Әльфираак. Әльфираак, йәә шәһра рамәдаан. Аллааһуммә йәә кадиим, йәә хәкиим, йәә галиим игъфир ләнәә йәә кәриим йәә рахиим йәә хәлиим йәә әрхәмәр-раахимиин».

Мәгънәсе: «Юмарт һәм Рәхимле булган Хаким Пакьтер. Ярлыкаучы буларак билгеле, игелеге белән аерылып торган хөкем Итүче Хаким Пакьтер. Ий, Рамазан ае, синең белән саубуллашабыз, саубуллашабыз, аерылабыз, аерылабыз. Мәңге, Хәким, Галим булган Аллаһы, безнең гөнаһларны ярлыка, Син юмартлык Иясе, гөнаһларны Ярлыкаучы, ий, Рәхимнәрнең Рәхимлесе».

*Тәравих намазыннан соң, әлеге дога укыла:*

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ وَسَلِّمْ اَللَّهُمَّ زَيِّنَّا بِزِينَةِ الْإِيمَانِ وَشَرِّفْنَا بِشَرَافَةِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرِمْنَا بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ وَارْزُقْنَا الْجَنَّةَ وَالْغُفْرَانَ وَتَقَبَّلْ مِنَّا تَرَاوِيحَنَا يَا سُبْحَان وَاسْتَجِبْ دُعَائَنَا يَا حَنَّان. بِفَضْلِكَ وَجُودِكَ يَا مَنَّانُ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ

«Аллааһуммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин вә сәллим. Аллааһуммә зәййиннәә бизиинәтил-иимәән. Вә шәррифнәә

бишәраафәтил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән. Вә әкримнәә бисыйәәми шәһри рамадаан. Вәрзукънәл-җәннәтә вәл-гуфраан. Вә тәкаббәл миннәә тәраавиихәнәә йәә сүбехән. Вәстәҗиб дүгаа-әнәә йәә хәннәән. Бифәдъликә вә җүүдикә йәә мәннәән. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин».

Мәгънәсе: «Йә, Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның әһле-бәйтен мөбарәк кыл һәм аларны сәламлә. Йә, Аллаһым, безне иман зиннәте белән бүләклә, хак юлга үгет-нәсыйхәт, гыйлем биреп, Рамазан аенда ураза тоттыр, ярлыкавыңны бир һәм җәннәт насыйп әйлә! Ий, Пакь булган Аллаһы Тәгалә, бездән тәравих намазын кабул ит. Ий, Мәрхәмәтле булган Аллаһы Тәгалә, мәрхәмәтеңнән, юмартлыгыңнан үтенечләребезгә җавап бир. Син мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе! Барысы да Синең рәхмәтеңнән була».

*«Кунак килә, каршы ал! Рамазан аена әзерлек!» китабыннан*

# Тәрбия

# Күркәм холык – җәннәткә илтә

Ислам динебезнең нигезе булып тәүхид – бер Аллаһыга гына ышану торса, аның икенче мөһим өлеше – гүзәл әхлак, күркәм холык. Аллаһы Раббыбызның безгә йөкләгән фарызлары, тыйган харамнары әхлакны төзәтү өчен. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Мин изге холыкларны тәмам өйрәтү өчен җибәрелдем», – дигән. Пәйгамбәрләрнең һәрберсе гүзәл әхлакны өйрәтү нияте белән күндерелгән булсалар, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә шуны тәмам итеп өйрәтү һәм камиллеккә ирештерү өчен җибәрелгән. Димәк, иман китереп үзен мөселман дип санаучы һәркем әхлагын төзәтү өчен һәрдаим тырышырга тиеш. Бер җирдә бик күркәм холыклы, бик әдәпле бер кеше яшәгән. Аннан: «Син бу сыйфатларга ничек итеп ирештең?» – дип сорагач, «Мин яшәвемнең нигезе итеп дүрт кагыйдәне алдым», – дип җавап биргән. «Алар нидән гыйбарәт?» – дигәч, «Беренчесе, Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешегә билгеләнгән байлык артмый да, кимеми дә. Шуның өчен дә кемнәрнеңдер байлыгы, дәрәҗәсе минекеннән артык икән, алардан көнләшмим, нәрсәдер булдырам дип тырышып та барып чыкмаса, йә каза килсә, кайгырмыйм.

Икенчесе, Аллаһы каршында минем бурычларым бар, аны минем өчен берәү дә түли алмый, мин шул бурычларны түләү белән мәшгульмен.

Өченчесе, минем бер дустым бар, аның белән очрашырга әзерләнәм. Ул дус «үлем» дип атала. Дөньяда ике генә хакыйкать бар. Аның берсе – Аллаһы Тәгалә, без Аны танырга, тормышыбызны Ул кушканча көйләргә тиеш. Башка бар нәрсә дә вакытлыча һәм үтүчән. Акыллы кеше мәңгелек сәгадәтне вакытлы мавыгуларга сатмый. Ә икенче хакыйкать ул – үлем, аңа әзерләнергә кирәк.

Дүртенчесе, мин иман китергән кеше буларак, Аллаһының һәрвакыт мине күреп торуын беләм, үлгәч, Аның каршына барып җавап

бирәчәгемә ышанам. Шуңа күрә дә Раббым каршында йөзем кызарырлык эшләр эшләмәскә тырышам», – дип җавап кайтарган. Боларның һәрберсенә тулырак тукталып үтик:

## Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешегә билгеләнгән байлык артмый да, кимеми дә

Беркөнне Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләргә: «Бүген сезнең яныгызга җәннәткә керәчәк бер кеше килә», – дип игълан иткән. Әлеге кеше килгәч, сәхабәләр аның артыннан күзәтеп йөри башлаганнар. Берничә көн үткәч, аның башкалардан артык гыйбадәт кылганын күрмәгәч, аптырап: «Синең кешеләрдән артык нинди сыйфатларың бар?» – дип сораганнар. Әлеге кеше: «Мин үз гомеремдә берәү турында да начар сүз сөйләмәдем һәм берәүдән дә көнләшмәдем», – дип җавап биргән. Кызганыч ки, күп вакыт кеше турында начар сүзләрне ул яман булган өчен түгел, ә ниндидер уңышка ирешүеннән көнләшеп сөйлиләр. Күпмедер тырышсаң, фарызларны да үтәп була, нәфелләрне дә. Әмма әлеге кеше әйткәнне эшләргә кайсыбызның көче җитә? Әйдәгез, шуңа омтылыйк. Югыйсә, һәр әйткән сүз (яхшымы ул, начармы ул) үзебезгә әйләнеп кайта – моны барыбыз да белә. Һәркайсыбыз сүзләребезне уйлап, Аллаһы бүләк итеп биргән акыл белән фикерләп кенә сөйләсәк иде. «Кешенең кем икәнен беләсең килсә, аның турында башкалар сөйләгәнгә игътибар итмә, ул кешенең башкалар турында сөйләвенә кара» дигән сүз бар. Начарлыкны сөйләүче ул шуны таратучы да, үзенә начарлык теләүче дә булып тора. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنْ أَحْسَنتُمْ أَحْسَنتُمْ لِأَنفُسِكُمْ ۖ وَإِنْ أَسَأْتُمْ فَلَهَا ۚ ... ﴿٧﴾

**«Игелекле гамәл кылсагыз, үзегезгә игелек кылган булырсыз. Начар гамәл кылсагыз – янә үзегезгә генә [чөнки начарлыклар өчен үзегезгә җавап тотарга туры киләчәк]».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:7

Имам Әбү Хәнифә хәзрәтләре дәрес биргәндә, бер шәкерт кереп: «Хәзрәт, сезнең сәүдә малыгыз төялгән көймә баткан», – дип хәбәр итә (Имам Әбү Хәнифә хәзрәтләре иң зур галим генә түгел, ә сәүдәгәр дә булган. Диннән кәсеп ясамасыннар дип, һөнәре, кәсебе булмаганнарны шәкерт итеп алмаган). Хәзрәт бераз гына калебенә карап тора да: «Әлхәмдүлилләһ», – дип, дәресне дәвам итә. Бераз вакыттан соң икенче берәү килеп: «Баткан көймә сезнеке булмаган, сезнеке яр кырыена килеп җитте», – дип хәбәр бирә. Хәзрәт янә бераз калебенә карап тора да: «Әлхәмдүлилләһ», – дип дәресне дәвам итә. Шәкертләр дәрес беткәч: «Хәзрәт, сез ни өчен ике очракта да бер төрле җавап бирдегез?» – дип сорагач, «Мин беренче очракта калебемдә бер кайгы да күрмәдем, икенче очракта шатлык, дулкынлану кичермәдем, шуңа күрә: «Әлхәмдүлилләһ», – дидем», – дип җавап бирә.

Байлык кешенең күңелендә түгел, кесәсендә булырга тиеш. Калеб иман өчен, аның урынын байлык алса, ул кеше дөньяда һәм Ахирәттә бәхетсез була. Бу, әлбәттә, эшләмәскә, дөньядан ваз кичәргә дигәнне аңлатмый. Көчең, сәләтең бар икән, тырыш, кәсеп ит: өең дә, машинаң да, киемең дә яхшы булсын, әмма фарызларны үтәмичә, харамга кереп батарга ярамый.

Дөрес, Раббыбыз тәкъдирләгән байлык артмый да, кимеми дә, әмма Аллаһы шул байлыкны булдыруда кешене сәбәпче итеп куйган. Дөнья тормышында бу байлыкка хәләл юл белән дә, харам юл белән дә ирешеп була. Кайсы юл белән барсаң да, сиңа язган байлык синеке, берәүнеке дә сиңа керми, синеке дә башкага китми. Тик харам мал сине дөньяда хурлыкка калдыра, җинаятьче ясый, Ахирәттә тәмуг утынына кисәтү итә.

Кыямәт көнендә һәркайсыбыз байлык турында ике төрле сорауга җавап тотачакбыз. Беренчесе, малларыбызны нинди юл белән таптык? Икенчесе, малыбызны нинди җирләргә исраф иттек? Сәламәтлегең, сәләтең булып, Аллаһының рәхмәте белән байлыкка ия булгансың икән, аның кырыктан бере (2,5 %) синеке түгел, ә ятимнәр, мескеннәр, дин юлында тырышучылар өлеше. Раббыбыз теләсә, безне бер мизгелдә байлыксыз калдыра ала, яисә шул байлыктан файдалана алмый торган итәргә мөмкин.

Бер бай кеше Зәйнулла ишанга: «Хәзрәт, акча булса, бар да була бит, шуңа күрә байлык артыннан куып, намазларымны да вакытында укый алмыйм», – ди. Аңа каршы Зәйнулла ишан: «Әйе, байлык булса бар да була. Әйтик, базарга чыгып, җаның ни тели, шул ризыкны сатып ала аласың, әмма Аллаһы бирмәсә, ашыйсы килү теләгең сатып ала алмыйсың. Бүген күпме кешеләргә ашаган саен начар була. Акчаң булса, яхшы урын-җир сатып ала аласың, әмма йокыны сатып ала алмыйсың. Бүген күпме кеше йокысызлыктан интегә. Акчаң бар икән, кыйммәтле дарулар ала, яхшы табиблар янына бара аласың. Тик Аллаһы теләмәсә, шифа таба алмыйсың. Акчаң булса, яхшы йорт ала аласың, әмма йорт эченә тынычлыкны сатып алып куярга һич мөмкин түгел. Акчаң бар икән, дусларың да күп була, әмма акчага аларның мәхәббәтен яулый алмыйсың. Акчаң булса, балаң ни сорый, шуны алып бирә аласың, әмма аңа тәүфыйк-һидаять сатып ала алмыйсың», – дип җавап кайтара.

Акчаң да, алда санап киткәннәр дә булсын дисәң, керемең хәләл юл белән табылырга һәм зәкятләре биреп барылырга тиеш.

## Аллаһы каршындагы бурычларны безнең өчен бирәү дә түли алмый

Һарун Әр-Рәшид патша берәр галим белән очрашасы килүен әйтә һәм аны галим янына алып баралар. Күпмедер сөйләшеп утыргач, пат-

ша аннан: «Бурычларың бармы?» – дип сорый. Уңай җавап алгач, ул галимнең бурычларын түләргә боера. Шуннан патшаны икенче галим янына алып баралар. Анда да шул ук хәл кабатлана. «Тагын берәр галим юкмы?» – дигәч, аны Фузаил бине Гыяз янына алып баралар. Патша аннан да: «Бурычларың бармы?» – дип сорый. Фузаил бине Гыяз: «Бурычларым бик күп, әмма, падишаһым, син аны түли алмыйсың», – ди. Һарун Әр-Рәшид патша бик аптырап: «Байлыгым күп, мин теләсә нинди бурычны түли алам», – ди. Фузаил бине Гыяз: «Аллаһы каршында бурычларым бар, аны минем өчен берәү дә, шул исәптән син дә түли алмыйсың», – ди. «Мин кешеләр белән ике арадагы бурычны сорыйм», – дигәч, Фузаил бине Гыяз: «Аллаһы биргән нигъмәтләргә шөкер итмичә, кыска гына гомерем өчен бурычка кереп мәшәкатьләнмәдем», – дип җавап кайтара. Падишаһ елап җибәрә һәм үзенә нәсыйхәт кылуны үтенә. Фузаил бине Гыяз: «Әй, падишаһым, Аллаһыны таныган бер мизгел меңәр ел меңләгән кеше белән идарә итүдән хәерлерәк», – ди.

Аллаһы Тәгалә безне акыл белән зиннәтләгән һәм аны намаз белән тәрбия кылырга кушкан. Берәү Раббысы каршындагы шул бурычны үтәмәсә, акылы тәрбиясез була. Берничә уку йорты бетерү, гыйльми дәрәҗәләр алу әле ул тәрбияле булу дигән сүз түгел. Акылың тәрбияле икән, ул синең әгъзаларыңны гөнаһлы эшләрдән тыеп торырга тиеш. Адәм баласында нәфес тә бар. Без нәфесне ураза белән тәрбия кылырга тиешбез. Тәрбия кылынмаган нәфес кешегә хуҗа була һәм аңа ияреп, кеше үз-үзенә золым сала. Аллаһы каршындагы бурычларыбызны безнең өчен башка беркем дә үти алмый. Һәрберебез, дөньяда һәм Ахирәттә бәхетле булыйк дисәк, тизрәк тәүбәгә килик, намус белән бурычларыбызны түли башлыйк.

## Дөньяда ике генә хакыйкать бар

Аның берсе – Аллаһы Тәгалә, без Аны танырга, тормышыбызны Ул кушканча көйләргә тиеш. Ә икенче хакыйкать – ул үлем, аңа әзерләнергә кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем үлми, теләсә нәрсә эшләсен», – дигән. Бүген күбебез затлы дару, яхшы табиб эзләп гомерне үткәрәбез, күпме акча түгәбез. «Бу мәсьәләдә үзем ярдәм итә алам», – дип күпме кеше башкаларны алдап баеп ята. Үлемнән алып кала торган дару һәм табиб юк, булмаячак та. Яшәү кебек, үлем дә табигый. Бернинди байлык, дәрәҗә дә аннан алып кала алмый.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй адәм баласы, өең белән мактанма, актыккы өең кабер булыр; әй адәм баласы, кигән киемең белән горурланма, актыккы киемең кәфен булыр; әй адәм баласы, утырып йөргән әйберләрең белән мактанма, актыккы барган нәрсәң кабык булыр; әй адәм баласы, ашаган ризыгың белән мактанма, беркөн үзең башкаларга ризык булырсың», – дигән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем үлә – ул йокысыннан уяна», – дигән. Димәк, бу дөнья төш кенә. Мондагы кыйммәтләр анда ярамый. Әлбәттә, соңгы юлга да матур итеп озатсыннар, әмма анда алып барырлык изге гамәлләрең дә булсын. Бер галим: «Бу дөнья язгы кояш астындагы кар кебек, эреп юкка чыгачак. Ә изге гамәлләр кыйммәтле асылташлар кебек, торган саен бәһаләре арта», – дигән. Газиз дин кардәшләрем, шул асылташларны күбрәк әзерлик. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Әгәр берничә минуттан ахырзаман җитә, дисәләр, ни эшлик?» – дип сорагач, «Кулыңда бер үсенте бар икән, өлгерә алсаң, утыртып калырга тырыш, Кыямәт көнендә сиңа файдасы тияр», – дип җавап кайтарган. Димәк, һәркем гомеренең соңгы сулышына кадәр игелек эшләп калырга тырышырга тиеш. Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

فَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ ﴿٧﴾ وَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ ﴿٨﴾

**«Кем дә кем [дөньяда] зәррә авырлыгы кадәр генә игелек кыла, аны [Ахирәттә] күрәчәк. Кем дә кем [дөньяда] зәррә авырлыгы кадәр генә начарлык кыла, аны [Ахирәттә] күрәчәк».**

«Әз-Зәлзәлә / Җир тетрәү», 99:7-8

## Аллаһы Тәгалә безне һәрвакыт күреп тора

Аның каршына барып җавап бирәчәкбез. Шуңа күрә дә Раббыбыз каршында йөзебез кызарырлык эшләр эшләмәскә кирәк. Һәркем иман китергән икән, 7 нәрсәгә шикләнмичә ышанырга тиеш:

1. Аллаһының барлыгына, берлегенә;
2. Фәрештәләренә;
3. Китапларына;
4. Пәйгамбәрләренә;
5. Кыямәт көненә;
6. Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән булуга;
7. Үлгәннән соң терелүгә.

Кызганыч ки, күп кешеләр үлгәннән соң терелүгә бераз шикләнеп карыйлар. Әгәр кеше үлгәннән соң терелүгә, аннан соң җавап бирәчәгенә чын күңелдән ышанса, күп гөнаһлардан тыелырга үзендә көч табар иде.

Зөләйха Йосыф галәйһиссәламне зинага чакырганда Йосыф галәйһиссәламгә иманы шушы эштән тыелып калырга көч бирә. Йосыф галәйһиссәлам: «Мин Аллаһыдан куркам», – дип төрмәдә утыруны зинадан өстен күрә. Аллаһы Раббыбыз шушы сынауны уңышлы үткәне өчен аңа патшалыкта дәрәҗә һәм пәйгамбәрлек бирә. Әгәр Йосыф галәйһиссәлам, берәү дә күрми әле дип, зинага ризалашса, күпмедер кәеф-сафа корып яшәсә – ул дөньяда хурлыкка калыр һәм Ахирәттә урыны җәһәннәм булыр иде.

Ислам дине буенча яшәүнең ике төп кагыйдәсе бар: кеше үз нәфесенә булышып, үзенә-үзе зыян китермәскә һәм үз-үзенең тотышы белән башкаларга зыян салмаска тиеш. Барчабызга да Аллаһы риза булырлык итеп яшәргә насыйп булса иде.

*Җәлил хәзрәт Фазлыевның «Күңел бакчасы» китабыннан*

# Тәфсир

# Идрис галәйһиссәлам кыйссасы

وَاذْكُرْ فِي الْكِتَابِ إِدْرِيسَ ۚ إِنَّهُ كَانَ صِدِّيقًا نَّبِيًّا ﴿٥٦﴾ وَرَفَعْنَاهُ مَكَانًا عَلِيًّا ﴿٥٧﴾

**«[Расүлем!] Китапта Идрис галәйһиссәламне дә искә ал. Һичшиксез, ул һәм изге, һәм бер пәйгамбәр иде. Без аны [пәйгамбәрлек кебек] өстен бер урынга күтәрдек».**

«Мәрьям», 19:56-57

Аллаһы Тәгалә Кәлам Шәрифтә үзенең тагын бер пәйгамбәре – Идрис галәйһиссәлам турында шулай дип әйтә. Идрис галәйһиссәлам 360 яшендә могҗизалы рәвештә күккә ашуы белән билгеле.

Бу хакта берничә риваять бар. Шул риваятьләрнең берсендә Идрис галәйһиссәламнең күккә ашуы раҗәб аеның 15 нче төнендә булган, дип әйтелә. Аллаһының расүле Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мигъраҗ төнендә күккә ашуы һәм күкнең җиде катына да күтәрелүе исегездәме? Коръәндә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең күкнең җиденче катында Идрис галәйһиссәлам белән күрешүе хакында телгә алынган. Күкнең дүртенче каты урталыкны аңлата – аның өстендә һәм астында тагын өчәр күк бар. Пәйгамбәрләрнең икесе әле дә булса исән дип санала, һәм алар күкләрдә яшиләр: болар – Гайсә (икенче кат күктә) һәм Идрис (дүртенче кат күктә).

Идрис галәйһиссәлам Шис галәйһиссәлам нәселеннән, ә Шис галәйһиссәлам исә – Адәм галәйһиссәламнең улы. Аллаһы Тәгалә Идрис галәйһиссәламне утка табынган Кабил улларына пәйгамбәр сыйфатында җибәргән. Ул аларга башта Шис галәйһиссәламгә иңдерелгән изге язмаларны укыган, ә аннары, Раббыбыз аңа Үзе җибәргән, ягъни 30 төргәккә язылган Аллаһы сүзләрен җиткергән. Раббыбыз иңдергән язмаларны

Идрис галәйһиссәлам үз куллары белән язып барган, шул рәвешчә ул Адәм галәйһиссәламнән соң язар өчен кулына каләм алган беренче кеше булган. Шуңа да карамастан, Кабил улларыннан Идрис галәйһиссәламгә бары берничәсе генә иман китергән.

## Беренче тегүче, каләм иясе, корал уйлап табучы…

Хәер, Идрис галәйһиссәлам ул чордагы кешеләр тормышының башка өлкәләрендә дә беренчеләрдән булган һәм бик күп һөнәрләр уйлап тапкан. Идрис галәйһиссәлам турында сүз барганда, хәтергә беренче булып тегүчелек һөнәре килеп басуы юкка гына түгел. Әйе, ул кешелек тарихында беренчеләрдән булып энә һәм җеп ярдәмендә киемнәр тегә башлаган. Аңа кадәр кешеләр хайваннарны аулап, аның тиресен киеп йөргәннәр, ә Идрис галәйһиссәлам нигезләгән тегүчелек һөнәре хәзер күлмәк, чалбар һәм камзул киеп йөрергә мөмкинлек биргән.

Игътибар итегез: борынгы кешеләр, тәннәрен каплар өчен, кыргый җәнлекләрне аулап йөреп, үзләрен куркыныч астына куйганнар. Чакрымнарча озынлыктагы тукымалар җитештерә торган хәзерге эрләүтуку эшләнмәләре сәнәгате кулланучыларга уңайлы, җылы һәм җиңел киемнәрнең киң төрләрен тәкъдим итә. Әмма, кызганыч ки, хатынкызлар кыска һәм тәнгә сыланып торган киемнәрне өстен күрә, ә ир-атларның исә хатыннары, кызлары һәм сеңелләре ялангач йөргәнгә исләре китми, хәтта ки алар бу күренешне танырга теләмиләр дә.

Идрис галәйһиссәлам шулай ук беренче булып язу уйлап тапкан, математик исәпне башлап җибәргән, астрономик күренешләр белән кызыксынган һәм үлчәү исәбен куллана башлаган. Аллаһының рәхмәте белән, шулай ук үткен акылы, күзәтүчәнлеге һәм зирәклеге сәбәпле, ул медицина һәм башка күп кенә фәннәр буенча да белемнәргә ия булган. Кавемдәшләренә дә бу фәннәрне өйрәткән, хәтта кылычлар, уклар һәм

сөңгеләр кебек кораллар да уйлап тапкан. Әмма Идрис галәйһиссәламнең иң күркәм сыйфаты – Аллаһыга гыйбадәт кылуда бик зур тырышлык куюы.

## Гыйбадәттә кешеләр арасында иң тырыш кеше

Бер риваятьтә әйтелгәнчә, Идрис галәйһиссәлам төннән алып таңга кадәр Яратучысына гыйбадәт кылган һәм төргәккә язылган язмаларны укыган. Ул шулкадәр гыйбадәт кылырга яраткан ки, бу гамәлне ул барлык башка кешеләр эшләгәнгә караганда да күбрәк башкарган. Фәрештәләр аның озак вакыт гыйбадәттә булуына таң калганнар һәм бу сыйфаты өчен аны бик нык яратканнар.

Шуны әйтергә кирәк, пәйгамбәрләрнең генә изге сыйфатлары күккә ашып калмый, калган башка кешеләрнең дә ихлас иманулары аларны шулай ук Аллаһы Тәгаләгә якынайта:

مَن كَانَ يُرِيدُ الْعِزَّةَ فَلِلَّهِ الْعِزَّةُ جَمِيعًا ۚ إِلَيْهِ يَصْعَدُ الْكَلِمُ الطَّيِّبُ وَالْعَمَلُ الصَّالِحُ يَرْفَعُهُ ۚ وَالَّذِينَ يَمْكُرُونَ السَّيِّئَاتِ لَهُمْ عَذَابٌ شَدِيدٌ ۖ وَمَكْرُ أُولَٰئِكَ هُوَ يَبُورُ ﴿١٠﴾

**«Кем дә кем бөеклек [көч һәм шәрәф] теләсә, [һәрнәрсәгә көче җиткән Аллаһыга итагать итсен] бөеклек тулысынча Аллаһыныкы гына. Күркәм сүзләр Аңа ирешә. [Намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек] Изге гамәл исә, аны ул [тәүхид кәлимәсе] күтәрә. Әмма [Исламга каршы] начарлыклар корган кешеләр – аларга каты газап. Аларның тозагы бозылачак [һәм иртәмесоңмы бушка чыгачак]».**

«Фатыйр / Бар кылучы», 35:10

Аллаһыга ирешә торган изге гамәлләрнең канатлары булып тәсбихәт тора. Әйтелгән изге сүзләребез күкләргә без кылган изге гамәлләрне юнәлтәләр, һәм фәрештәләр бу хакта беләләр. Шулай итеп, без никадәр күбрәк Аллаһы Тәгаләне зикер кылсак, күк әһелләре безне шулкадәр яхшырак белер, һәм шул рәвешчә алар безне ныграк яратырлар.

## «Миңа үлемне һәм җәһәннәмне күрсәт»

Аллаһы Тәгалә Идрис галәйһиссәлам турында болай дип әйтә:

وَرَفَعۡنَٰهُ مَكَانًا عَلِيًّا ﴿٥٧﴾

**«Без аны [пәйгамбәрлек кебек] өстен бер урынга күтәрдек».**

«Мәрьям», 19:57

Идрис галәйһиссәламнең күккә ашуы турында күпләгән риваятьләр бар. Шуларның берсе буенча, «югары» дигәндә җәннәт күздә тотыла. Ә «Рухуль-Бәйан» тәфсирендә түбәндәгеләр хәбәр ителә. Фәрештәләр Идрис галәйһиссәламнең исәпсез-хисапсыз гыйбадәтләреннән гаҗәпкә калганнар. Газраил галәйһиссәлам үзе Яратучыдан Идрис галәйһиссәламнең дусты булырга рөхсәт сораган һәм ул моңа ирешкән. Аларның дуслыгы ныгыгач, Газраил галәйһиссәлам Идрис галәйһиссәламгә болай дип әйткән:

– Мин – үлем фәрештәсе Газраил. Мин сине күрергә килдем. Син Аллаһыга күп гыйбадәт кылдың, мин сине Аллаһы ризалыгы өчен сөйдем һәм синең дустың һәм кардәшең булырга теләдем. Әгәр синең миңа үтенечең бар икән, әйт, мин аны үтим.

Идрис галәйһиссәлам көтмәгәндә генә үлем ачысын татып карыйсы килү хакында әйткән. Газраил галәйһиссәлам Идрис галәйһиссәламнең көтелмәгән мондый теләге булганга бик тә гаҗәпкә калган һәм болай дип әйткән:

– Ий Идрис! Мин моны үз теләгем белән генә башкара алмыйм, синең үлем мизгелең әле җитмәгән.

– Ий Газраил! Әгәр син әзер булсаң, ул шулай булсын да. Миңа тагын мең ел яшәргә язылган булса да минем җанымны ал. Әгәр миңа озын гомер тәкъдир кылынган икән, Аллаһы мине кабаттан терелтәчәк.

– Ий Идрис! Мин бу эшне Раббыбызның рөхсәтеннән башка эшли алмыйм.

Аннары Идрис галәйһиссәлам Аллаһыга дога белән мөрәҗәгать иткән һәм Аннан үлем турында сораган. Аллаһы – барысын да Белүче Зат, һәм Ул Идрис галәйһиссәламнең хакыйкый теләге турында белгән һәм үлем фәрештәсенә рөхсәт биргән. Газраил галәйһиссәлам Идрис галәйһиссәламнең җанын алганда аңа 60 яшь булган. Үлгәннән соң терелгән Идристән Газраил галәйһиссәлам болай дип сораган:

– Ничек сиңа үлем?

– Аның турында сөйләгәннәр белән чагыштырганда, ул бик катлаулы һәм авыр әйбер.

Фәрештәнең һәм Пәйгамбәрнең дуслыгы дәвам иткән. Идрис галәйһиссәлам янә үзенең дустыннан җәһәннәмне күрсәтүен сораган. Аллаһыдан рөхсәт алып, Газраил галәйһиссәлам Идрис галәйһиссәламне җәһәннәмнең төрле дәрәҗәләре буенча йөртә, һәм аңа гөнаһ әһелләренә карата кулланыла торган җәзалар күрсәтелә. Тәмугның барлык җиде дәрәҗәсен күреп, Идрис галәйһиссәлам Аллаһының яклавы астында була һәм тәмугтан кайтарыла.

## Җәннәттән китәсе килми

Әмма Идрис галәйһиссәламнең Фәрештәгә тагын бер үтенече кала: «Ий минем дустым! Минем җәннәтне күрәсем килә». Раббыбыз аларга бу эшкә дә рөхсәт бирә. Җәннәтнең сигезенче дәрәҗәсен күреп, Газраил галәйһиссәлам болай дигән:

– Киттек, кире әйләнеп кайтырга вакыт җитте.

Әмма Пәйгамбәр галәйһиссәлам җәннәтне ташлап китәргә теләмәгән. Шуннан соң җәннәтне саклаучы Ризван аңа мөрәҗәгать иткән:

– Ий Аллаһының пәйгамбәре! Син җәннәттән чыгарга теләмисең, ләкин синең монда калу өчен вакытың җитмәгән әле. Җәннәткә керү өчен, вафат булырга, ә аннары кабаттан терелергә кирәк.

Идрис галәйһиссәлам җавап биргән:

– Әйе, барысы да дөрес. Безнең Раббыбыз: «Һәрбер җан үлем ачысын татыр», – дип әйтә һәм мин үлем ачысын татыдым инде. Шулай ук безнең Раббыбыз әйтә: «Сезнең һәрберегез аңа (җәһәннәмгә) керер», һәм мин анда булдым инде. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Һәм алар аннан (җәннәттән) чыкмаслар». Ул чагында сез мине моннан ничек чыгарырга телисез?

Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аларга хәбәр бирә:

– Ул җәннәткә минем рөхсәт белән керде, һәм ул монда Минем боерык белән калсын да. Теләгән җиренә барсын, җаны теләгәнне эшләсен.

Фикер йөртүче кешеләр өчен ачык ки, Идрис галәйһиссәлам белән булган хәлләр, һичшиксез, безнең барыбызга да киләчәк. Әмма бу вакыйгаларны – үлемебезне, каберне һәм Кыямәт көнен без нинди әзерлек белән каршы алырбыз? Дөнья мәшәкатьләре кеше өчен төп әйбер түгел, нәкъ менә кабаттан кубарылу һәм аннары үз гамәлләрең өчен хисап бирү – иң мөһим, чөнки фани дөнья үтә дә китә, һәм мәңгелек тормыш башлана. Барыр юлыбыз озын, ә йөгебез авыр. Үзенең бер хәдисендә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Әгәр сез мин белгәннәрне белсәгез, аз көләр, күп елар идегез». Кыямәт көне, җыелу, кубарылу, гамәлләр үлчәүгә куелу һәм Сират күпере хакында бөтен кешеләрдән дә күбрәк белүче Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә шулай дип әйтә.

Аллаһы Тәгалә безнең калебләребезне йомшартса иде һәм алда торган сәфәр авырлыкларында җиңеллекләр сорап, Аңа догалар белән

теләкләребезне җиткерүне насыйп әйләсә иде. Кем белә, бәлки, Аллаһыны ихлас сөюдән һәм Аның рәхмәтенә өмет итүдән тамган бер күз яше безнең күңелебезне пакьләр һәм Аллаһы Үзенең бөек Ярлыкавын бүләк итүенә бер сәбәп булыр?

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

## 62. Әл-Җүмүгә (Җомга) сүрәсе

Мәдинә чоры, 11 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Күкләрдә булганнар һәм җирдә булганнар** [һәрнәрсәнең] **Хуҗасы, Кимчелексез, Бөек** [Җиңелмәс]**, Хикмәт иясе булган Аллаһыны** [барлык кимчелекләрдән ерак тотып] **тәсбих итә.**
2. **Ул –** [фәрештә һәм җен төрләреннән түгел, аралашулары җиңел булсын өчен] **үзләреннән Расүлне** [укый-яза белмәгән] **өммиләргә җибәрүче ки, ул аларга Аның аятьләрен укый, аларны** [матди һәм рухи нәҗесләрдән] **арындыра, аларга** [бөек] **Китапны һәм хикмәтне** [сөннәт белән шәригать хөкемнәрен] **өйрәтә. Хәлбуки, алар элек ап-ачык адашу эчендәләр иде.**
3. **Янә** [Аллаһы Тәгалә Расүлуллаһны (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) гарәпләргә генә һәм үзе яшәгән гасырдагыларга гына түгел, китап әһеле булмаган] **бүтән – әле боларга** [вакыт ягыннан] **ирешмәгән** [өмми] **кешеләргә дә** [җибәрелде]**. Ул – Бөек** [Җиңелмәс]**, Хикмәт иясе**[1]**.**
4. **Бу – Аллаһының фазылы. Ул аны теләгәненә бирә. Аллаһы – фазыл Иясе, Бөекләрнең бөеге.**
5. **Үзләренә Тәүрат** [гыйлеме бирелеп, эчендәге хөкемнәр белән гамәл кылу җаваплылыгы өсләренә] **йөкләнгән, шуннан соң** [ул китапның әмерләре белән гамәл кылмыйча] **аны илтмәгәннәрнең хәле китаплар ташыган ишәк кебек. Аллаһының аятьләрен ялган дип санаган бу кавемнең хәле бик яман! Аллаһы** [белә торып, инкяр итү белән үз-үзләренә начарлык эшләгән] **залим кешеләрне** [котылуга ирештерә торган юлларга] **һидаять итми.**

---

[1] Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгәнгәнчә, «Җомга» сүрәсе иңгәч, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны сәхабәләренә укыганда, шушы аяте кәримәгә җиткәч, бер затның: «Йә Расүлуллаһ! Әле безгә ирешмәгән кешеләр кемнәр алар?» – дигән соравына, ул кулын Сәлман Фариси радыяллаһу ганһегә салып: «Җаным (кодрәт) кулында булган Зат белән ант итәмен ки, иман Сүрайя йолдызында булса да, болардан бер төркем кешеләр үрелеп аны алырлар», – дип әйткән. Моннан аңлашылганча, аяте кәримәдә күз уңында тотылган затлар, гарәпләрдән булмыйча, тагын да соңрак Исламны кабул итәчәк башка милләт вәкилләре булачак. Чыннан да, Бохари, Мөслим кебек хәдис хафизларының бик күбесе, Әбү Хәнифә радыяллаһу ганһе кебек хәдисләрдән хөкем чыгарган мөҗтәһидләрнең бер өлеше гарәпләрдән түгел, фарсы милләте кебек чит халыклардан булганнар. Хәтта ки, Исламның бүгенгә кадәр сау-сәламәт килеп ирешүе бу шәхесләрнең җитди тырышлыклары аркасында булган.

6. [Расүлем!] **Әйт: «И, яһүди булганнар! Әгәр дә сез** [яһүди булмаган] **башка кешеләрнең түгел, үзегезнең генә Аллаһының дуслары булганыгызга дәгъва кылсагыз, үлемне теләгез, әгәр дә** [дәгъвагызда] **дөрес сөйләүче булсагыз** [бераздан дустыгыз белән очрашырга теләрсез]**».**
7. **Әмма алар** [Тәүратны үзгәртү, Мөхәммәдне (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) һәм Коръәнне инкяр итү кебек элек эшләп] **кулларын озгган** [начар] **нәрсәләре аркасында** [яшәгән дәверләречә] **беркайчан да аны теләмәсләр** [хәтта үлемне акылларына да китермәсләр]**. Аллаһы ул залимнәрне** [бик яхшы] **белә.**
8. [Расүлем!] **Әйт: «Һичшиксез, сез кача торган үлем сезне каршы алачак. Шуннан соң сез** [Кыямәт көнендә тойгылар белән кабул ителгән һәм ителмәгән] **бөтен яшереннәрне һәм күренгәннәрне Белгәнгә кайтарылачаксыз, Ул сезгә** [дөньяда чакта] **кылган нәрсәләрегезне хәбәр итәчәк».**
9. **И, иман китерүчеләр! Җомга көнне намаз өчен** [азан әйтелеп] **чакырылгач, Аллаһыны искә алырга ашыгыгыз һәм сәүдәне ташлагыз. Бу –** [сәүдәнең вакытлы файдасыннан] **сезнең өчен яхшырак. Әгәр дә белсәгез иде** [мәңгелек алыш-бирешне сайлар идегез]**.**
10. **Намаз беткәч, җирдә таралыгыз, Аллаһының фазылыннан** [файдагызны] **эзләгез һәм Аллаһыны** [бөтен хәлләрегездә дә] **зикер кылыгыз. Бәлки, сез** [ике җиһанда да] **уңышка** [һәм котылуга] **ирешә алырсыз.**
11. [Расүлем!] **Алар бер сәүдә яки күңел ача торган нәрсә күргәч,** [синең яныңнан] **таралып, аңа юнәлделәр һәм сине** [минбәреңдә] **басып торган килеш калдырдылар. Әйт: «Аллаһы хозурында булганнар күңел ачудан да, сәүдәдән дә яхшырак** [чөнки Ахирәт әҗере даими һәм бетми торган булса, дөнья мәнфәгатьләре вакытлы гына]**. Аллаһы – ризык бирүчеләрнең иң яхшысы**[1]**.**

---

[1] Җабир ибне Габдуллаһтан радыяллаһу ганһе риваять ителгәнчә, Мәдинәдә ачлык һәм кыйммәтчелек хөкем сөргән бер җомга көнне Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) аягөсте торып, хотбә укыган вакытта Шамнан бер сәүдә кәрваны килеп чыккан. Әбү Бәкер, Гомәр һәм Җәбир радыйаллаһу ганһүм дә араларында булган унике кешедән тыш, сәхабәләрнең бөтенесе мәчетне ташлап, кәрванга таба ашыкканнар. Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): «Әгәр дә барысы да чыгып киткән булса, вади ут булып аларны яндырачак иде», – дигән. Әмма Әбү Давыдның (рәхимәһуллаһ) «әл-Мәрасил» дип аталган әсәрендә Мукатил ибне Хәййанга (рәхимәһуллаһ) таянып хәбәр иткәнгә караганда, ул чорда Расүлуллаһ

## 63. Әл-Мүнәәфикуун (Монафикълар) сүрәсе

Мәдинә чоры, 11 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. [Расүлем!] **Монафикълар сиңа килгәч: «Синең Аллаһының расүле икәнлегеңә шаһитлык итәбез», – диләр.** [Сине җибәргән] **Аллаһы синең расүл булуыңны, әлбәттә, беләә. Аллаһы монафикъларның** [сөйләгән сүзләре дөрес булса да,мәгънәсенә үзләре дә ышанмаганнары өчен, аларның] **ялганчы булуларына да шаһитлык итә.**
2. **Алар** [каннарын һәм малларын саклар өчен] **антларын үзләренә калкан иттеләр, шул сәбәпле** [мөселман булып күренгән самими мөселманнарны] **Аллаһы юлыннан тайпылдырдылар. Һичшиксез, алар кылган нәрсә нинди начар!**
3. [Аларның] **Бу – иман китергән** [булып күренгән]**, соңыннан инкяр иткәннәре өчен** [булды]**. Шуңа күрә аларның йөрәкләренә мөһер сугылды. Алар инде** [үлгәнче хакыйкый иман хакында] **аңлый алмаслар.**
4. **Син аларны күргәч, тышкы кыяфәтләре сине сокландыра. Әгәр дә алар сөйләсәләр, син сүзләрен тыңлыйсың. Алар** [синең мәҗлесеңдә таянып утырган чакларында, үзләре генә тора алмаганга, коймага] **терәп куйган бүрәнәләр** [иманнан арынган җисемнәр] **шикелле. Алар** [куркаклыкларыннан һәм дөнья малына хирыслыкларыннан] **һәр шау-шуны үзләренә каршы дип исәплиләр. Алар – дошман,** [тышкы кыяфәтләренә алдануны калдыр да] **алардан саклан. Аллаһы аларны һәлак итсен! Алар ничек алданалар!**
5. **Аларга: «Килегез, Аллаһының расүле сезнең өчен кичерү сорасын!» – дип әйтелгәч,** [тәкәбберлекләре сәбәпле] **башларын чөерәләр. Һәм син аларның масаеп,** [бу сүзне аларга әйтүчедән] **йөз чөергәннәрен күрәсең.**
6. **Син алар өчен ярлыкау сорыйсыңмы яки сорамыйсыңмы,** [берни дә үзгәрмәячәк, чөнки ике очракта да] **аларга барыбер. Аллаһы аларны ярлыкамаячак. Һичшиксез, Аллаһы фасикълар кавемен** [хакыйкый иманга] **һидаять итми.**
7. **Алар** [мөһаҗирләргә ярдәм иткән әнсарларга]**: «Аллаһының расүле**

---

(салләллаһу галәйһи вә сәлләм), бәйрәм намазларындагы кебек, җомга намазын да хотбәдән алда укыта торган булган, шул сәбәпле, сәхабәи кирам намазны калдырмаганнар, бары тик хотбә тыңлауның намаз кебек үк мәҗбүри булганын белмәгәннәре өчен аны калдырып киткәннәр (Ибне Кәсир).

**янындагылар** [фәкыйрь һәм мөһаҗирләр] **өчен, аны калдырып киткәнчегә кадәр, бернинди чыгымнар да ясамагыз», – дип әйтүчеләр. Күкләрнең вә җирнең хәзинәләре Аллаһыда бит.** [Шуңа күрә Мәдинә халкы фәкыйрь мөһаҗирләргә ярдәмен туктатса да, бөтен ризыкларның иясе булган Аллаһы аларны тәэмин итәргә кодрәтле]. **Ләкин монафикъләр** [Аллаһы Тәгаләнең бу өстен көчен] **аңламыйлар.**

8. **Алар: «Әгәр** [бәни Мүсталәк газвәсеннән] **Мәдинәгә кайтсак, иң көчле булган иң түбәнне аннан куып чыгарачак!» – диләр. Көчкуәт** [һәм шәрәф] **исә Аллаһыда, Аның расүлендә** (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) **һәм мөэминнәрдә, ләкин монафикъләр** [наданлыклары сәбәпле һәм алданган булулары өчен, бу хакыйкатьне] **белмиләр.**[1]

[1] Риваять ителгәнчә, бәни Мүсталик газавәте беткәннән соң, кешеләр бер кое тирәсендә туплангач, Гомәр радыяллаһу ганһенең хезмәтчесе Җәһҗаһ бине Сәгыйдь белән монафикъларның башлыгы Ибне Үбәйнең юлдашы Синан әл-Җүһәни суга чиратта торганда ачуланышып киткәннәр. Җәһҗаһ – мөһаҗирләрне, Синан әнсарны ярдәмгә чакыргач, фәкыйрь мөһаҗирләрдән берсе Җәһҗәһкә ярдәмгә килгән һәм Синанга бер суккан. Шул вакыт Ибне Үбәй аңа: «Син эшләдеңме моны? Шул инде, без бит Мөхәммәд янына кыйналыр өчен килдек. Валлаһи, алар белән безнең хәлебез, ашат этне, тешләр үзеңне, дигән шикелле. Ләкин Мәдинәгә кайтсак, иң көчле булган кеше иң түбән кешене аннан куып чыгарачак!» – дигән һәм «иң көчле» дигәндә – үзен, «иң түбән» дигәндә Расүлуллаһны (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) күз уңында тоткан. Шуннан соң үз кешеләре янына кайтып: «Валлаһи, сез бу фәкыйрьләргә артыкларыгызны ашатмаган булсагыз, хәзер муеннарыгызга менеп атланмаган булырлар иде. Артык аларга ярдәм итмәгез, Мөхәммәднең яныннан таралсыннар», – дигән. Бу вакытта әле яшь булган Зәед бине Әркам радыяллаһу ганһе моны ишеткәч: «Валлаһи, кавеме арасында сөелмәгән түбән һәм фәкыйрь кеше – синсең. Мөхәммәд исә мигъраҗ таҗы башында булган, Рахманның гыйззәте белән газиз һәм мөселманнардан көч алган кеше!» – дигән. Ибне Үбәй: «Тик тор! Мин шаярдым гына!» – дисә дә, Зәед радыяллаһу ганһе шундук Расүлуллаһка (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) барып, ишеткәннәрен сөйләп биргән. Бу чакта Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) янында булган Гомәр радыяллаһу ганһе: «Йә Расүлуллаһ! Рөхсәт ит тә, мин шул монафикъның башын чабыйм!» – дигәч, Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): «Алай итсәң, Мәдинәдә бик күп борыннар тетрәр (бик күп кеше куркуга төшәр һәм ышаныч бозылыр)», – дип әйткән. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әгәр аны бер мөһаҗирнең үтерүен теләмәсәң, моны берәр әнсарга боер!» – дигән. Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): «Мөхәммәд үзенең кешеләрен үтерә, дип сөйли башласалар ни булачак?» – дигән. Соңрак Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): Ибне Үбәйне чакырып: «Бу сүзләрне син әйттеңме?» – дип сорагач, ул: «Сиңа китап иңдергән Аллаһы белән ант итәмен, мин болардан берсен дә әйтмәдем. Зәйд – ялганчы!» – дигән. Анда булганнар: «Йә Расүлуллаһ! Бер баланың сүзен безнең олугыбызның сүзеннән өстен куясыңмыни? Ул, бәлки, ялгыш аңлагандыр?!» – дигәннәр. Бу вакыйгадан соң Зәед радыяллаһу ганһе оятыннан берникадәр вакыт өеннән чыкмаган. Ләкин бу сүрә иңгәннән соң Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) аңа: «Ий, егет! Һичшиксез, Аллаһы сине хаклы итеп, өстен чыгарды, мо-

9. **Ий, иман китерүчеләр! Малларыгыз** [белән булашуыгыз] **да, балаларыгыз да** [намаз, җиһад һәм Коръән уку кебек] **Аллаһыны зикер итүдән** [һәм гыйбадәт кылудан] **сезне тайпылдырмасын. Кем дә кем моны эшләсә,** [кыйммәтле һәм мәңгелек булган бернәрсәне гади һәм фани дөнья бәрабәренә сатканы өчен] **зарар күрүчеләр булырлар.**
10. **Сезнең берәрегезгә үлем** [галәмәтләре] **килгәнче Безнең сезгә ризык итеп биргән нәрсәләрнең бер өлешен** [Ахирәткә бер әзерлек буларак, мохтаҗларга] **сарыф итегез, соңыннан** [авырлык күргәч]**: «Ий, Раббым! Мине** [үлемемне] **якын бервакытка кадәр кичектерсәң, күп итеп садака бирер идем һәм** [Сиңа карата булган вазифаларымны тиешенчә үтәп] **изге кешеләрдән булыр идем», – дияр.**
11. **Аллаһы әҗәле җиткән җанга кичектерү бирми. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгыздан хәбәрдар.**

## 64. Әт-Тәгабүн (Алдашу) сүрәсе

Мәдинә чоры, 18 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Күкләрдә булганнар һәм җирдә булганнар Аллаһыны** [барлык кимчелекләрдән ерак тотып] **тәсбих итә. Хакимлек – Аныкы гына, мактау – Аңа гына. Ул һәрнәрсәгә** [көче җиткән] **кодрәтле.**
2. **Ул – сезне Яратучы. Сезнең арагызда кяфер булган да бар, сездән мөэмин булган да бар. Аллаһы сез кылган нәрсәләрне** [бик яхшы] **күреп тора.**
3. **Ул күкләрне һәм җирне** [мөкәлләфләргә сынау йорты кебек] **хак белән яратты, сезгә сурәт бирде һәм** [башка җан ияләре арасында] **сезнең сурәтләрегезне күркәм итте. Кайту – Аңа гына [булачак].**

---

нафикъларны исә ялганчы чыгарды», – дигән. Ибне Үбәйнең ялганы уртага чыккач, кайбер кешеләр аңа: «Синең хакта бик куркыныч аятьләр инде. Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) янына барып, гөнаһыңны таны да, ул синең өчен истигъфар сорасын!» – дигәннәр. Моны эшләмәячәген белдерер өчен, башын чөеп: «Иман ит, дидегез – иман иттем, зәкят бир, дидегез – зәкят бирдем. Инде миңа Мөхәммәдкә сәҗдә кылуымны әмер итүегездән башка берни дә калмады», – дигән. Бу хәлләрдән соң берничә көн яшәгәннән соң вафат булган (Нәсәфи, Хазин).

4. **Ул күкләрдә булган һәм җирдә булган һәрнәрсәне [бик яхшы] белә, сез яшергән нәрсәне дә, ачып салган нәрсәне дә белә. Аллаһы күкрәкләрдә булган нәрсәне [күңелләрдә яшерелгән барлык серләрне, ният һәм иманны бик яхшы] белүче.**
5. **Элек инкяр иткәннәрнең хәбәре сезгә ирешмәдемени? Алар [начар] эшләренең зарарын [дөньяда чакта ук] татыдылар. [Ахирәттә] Алар өчен тилмерткеч газап бар.**
6. **Бу шул сәбәпле ки, расүлләре аларга ап-ачык могҗизалар китергән иде, ләкин алар** [пәйгамбәрнең кеше булуын аңлый алмыйча]**: «Безне һидаятькә кешеләр ирештерәчәкмени?» – дигәннәр иде. Алар** [китапларны да, пәйгамбәрләрне дә, Ахирәтне дә] **инкяр иттеләр һәм** [дәлилләрдән] **йөз чөерделәр. Аллаһының аларга ихтыяҗы булмады. Аллаһы бит – Байлык иясе, Мактаулы.**
7. **Кяферләр беркайчан да терелтелмәячәкләр дип санаййлар. Әйт: «Юк! Раббым белән ант итәмен, сез тулысынча терелтеләчәксез, шуннан соң кылган нәрсәләрегездән хәбәрдар ителәчәксез. Аллаһы өчен бу бик җиңел».**
8. **Шулай булгач, Аллаһыга, Аның расүленә** (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) **һәм Без иңдергән Нурга** [Коръәнгә] **иман итегез. Аллаһы сезнең кылганнарыгыздан хәбәрдар.**
9. **Ул** [әүвәлгеләрнең һәм соңгыларның] **җыелу көне** [булган Кыямәт хисабы] **өчен сезне бер урынга китерәчәк көнне** [исеңдә тот]**. Ул – алдану көне** [һәм ул көнне алданганнар җәһәннәмдә булачаклар, чөнки иман белән үлгән очракларында җәннәттә алачак урыннарын мөселманнарга бирәчәкләр һәм җәһәннәмдә янган вакытта аларга ул урыннар күрсәтелгән чакта үкенечләреннән буылачаклар]**. Кем дә кем Аллаһыга иман итсә һәм изге гамәл кылса, Ул аңардан начар эшләрен каплаячак һәм аны** [сарайлары һәм агачлары] **асларыннан елгалар агып торган җәннәтләргә кертәчәк, алар анда мәңге калачак. Менә бу – бөек котылу.**
10. **Кяфер булган һәм Безнең аятьләребезне ялган дип санаганнар – Ут әһелләре. Алар анда мәңге калачак. Ул – нинди яман бару урыны!**
11. **Аллаһының рөхсәте** [теләве һәм мөмкинлек бирүе] **белән булмаса,** [кешенең малына, баласына һәм җанына] **һичбер бәла-каза килми. Кем дә кем Аллаһыга иман китерсә, Ул аның күңелен**

[сабырлыкка һәм, башына килгән нәрсәне Аллаһыдан дип белеп, ризалык күрсәтүгә] **һидаять итә. Аллаһы һәрнәрсәне** [бик яхшы] **белә.**

12. [Әмер һәм тыюларын үтәү мәсьәләсендә] **Аллаһыга итагать итегез һәм Расүлгә** (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) **итагать итегез. Әгәр дә** [аларның хөкемнәреннән] **йөз чөерсәгез,** [Аллаһыга да, пәйгамбәргә дә зарар китерә алмассыз, чөнки] **Расүлебезгә** (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) **ап-ачык ишеттерү генә йөкләнгән бит.**
13. **Аллаһы, Аннан башка** [гыйбадәткә лаек] **һичбер илаһ юк. Шулай булгач, иман китерүчеләр Аңа гына тәвәккәл кылсын.**
14. **Ий, иман китерүчеләр! Һичшиксез, хатыннарыгыз һәм балаларыгыз арасыннан сезгә дошман булганнары бар. Алардан сакланыгыз. Әмма әгәр дә** [аларның гафу итәрлек гаепләрен] **гафу итсәгез,** [шелтәләү һәм гаепләү юлына басмыйча] **йөз чөермәсәгез һәм** [кимчелекләрен] **яшерсәгез, һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле.**
15. **Малларыгыз һәм балаларыгыз –** [гөнаһка һәм газапка төшүегезгә сәбәп бирә торган] **бер сынау.** [Ризалыгын алган һәркемгә исә] **Аллаһы хозурында зур әҗер бар.**
16. **Көчегездән килгән кадәр Аллаһыдан куркыгыз,** [Аның үгетләрен кабул колагы белән] **тыңлагыз,** [әмер һәм тыюларына] **итагать итегез һәм** [сезгә биргән ризыклардан бер өлешен] **үзегез өчен** [малдан да, балалардан да] **яхшырак булган шәкелдә** [Ул әмер иткән урыннарга] **сарыф итегез. Кем дә кем үзенең комсызлык хирысыннан курка** [һәм Аллаһы юлында сарыф итә], **шулар – уңышка ирешүчеләр**[1]**.**
17. **Әгәр дә сез Аллаһыга бурычка** [чын күңелдән дини хезмәтләргә сарыф итү һәм бурыч сораучыга рибасыз акча бирү кебек] **яхшы нәрсә биреп тора, Ул сезгә аны** [кемгәдер – ун, кемгәдер җиде

---

[1] Сәгыйд бине Җүбәйр радыяллаһу ганһедән риваять ителгәнгә күрә, «Аллаһыдан куркыгыз» (Әлү Гыймран, 102) аяте кәримәсе иңгәч, сәхабәләр аяклары шешенгәнче һәм маңгайлары сөялләнгәнче гыйбадәт кыла башлаганнар. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә мөселманнарга бер җиңеллек өчен шушы аяте кәримәне иңдереп, беренче аяте кәримәнең хөкемен нәсех иткән һәм мөэминнәрнең, көчләреннән килмәгән нәрсәләр өчен, җаваплы булмаганнарын бәян иткән. Гәрчә монда нәсех булмаганын, бу аяте кәримәнең алдагы аяте кәримәнең кыскача эчтәлеген ачыклау (кыска һәм аңлашылып тормаган мәгънәнең аңлатмасы) булганын әйтүчеләр дә бар (Алуси).

йөздән дә күбрәк итеп] **кат-кат арттырыр һәм сезне ярлыкар. Аллаһы –** [тиеш булганнан артык] **Савап бирүче, Мәрхәмәтле.**

18. [Ул тою органнары белән сизеп булмаган бөтен] **Яшерен һәм күренгәннәрне** [асылы белән] **Белүче, Бөек** [Җиңелмәс]**, Хикмәт иясе.**

## 65. Әт-Таләк (Талак) сүрәсе

Мәдинә чоры, 12 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Ий, Нәби! Хатыннарны аерган чакта, аларны** [өч күрем вакыты булган] **гыйддәләреннән соң** [пакь хәлләрендә һәм алар белән якынлык кылмыйча] **аерыгыз һәм гыйддәне** [һич киметмичә] **санагыз. Раббыгыз булган Аллаһыдан куркыгыз** [гыйддә вакытын озайтып, аларга зарар китермәгез]**.** [Зина һәм караклык кебек] **Ап-ачык кабахәт бернәрсә кылмасалар,** [үзләренең милекләре кебек булган] **өйләреннән** [гыйддәләре тулганчы] **аларны кумагыз, алар да чыкмасыннар.** [Бары тик хәд җәзасы кирәк булган хәлләрдә, бу җәзага тартылыр өчен, чыгарылып, соңыннан өйләренә кабат кайтарылырлар]. **Болар – Аллаһының чикләре. Кем дә кем Аллаһының чикләреннән чыкса, алар –** [үз-үзләренә] **золым кылучылар.** [Ий, хатынын аерырга ниятләгән кеше!] **Син белмисең, бәлки, Аллаһы моның артыннан бер хәл чыгарып куяр** [да, нәфрәтне – сөюгә, күрәсе килмәүне тартылуга үзгәртер, ул чакта сез бик үкенерсез һәм бер-берегезгә кайтырсыз]**.**
2. **Шуннан соң алар** [гыйддә көтү] **чорларының ахырына якынлашкан чакта,** [хатыннарыгызны кайтарып] **яхшылык белән** [аларны никахыгызда] **тотыгыз яки** [гыйддәләре беткәнче, аларга кайтмыйча һәм зарар китермичә] **яхшылык белән аларны җибәрегез. Янә** [кире кайтырга яки тәмам аерылырга ниятләгән очракта] **арагыздан гадел булган ике кешене шаһит тотыгыз.** [Ий, шаһитлар!] **Сез** [кемгә дә файдасына яки зарарына дип тормыйча] **шаһитлыкны Аллаһы өчен кылыгыз. Бу – Аллаһыга һәм соңгы көнгә инанганнар өчен үгет. Кем дә кем Аллаһыдан курыкса, Ул аңа** [үлем куркынычлыгыннан, Кыямәт көненең кыенлыкларыннан] **бер чыгыш** [юлы] **насыйп итә.**
3. **Һич көтмәгән ягыннан аны ризыкландыра. Кем дә кем Аллаһыга**

**тәвәккәл кыла, аңа Ул җитә. Һичшиксез, Аллаһы һәрнәрсә өчен** [ул әле бар булганчы] **бер үлчәм куйган.**

4. **Хатыннарыгыздан** [картлыклары сәбәпле кабат] **күремнән өметләре өзелгәннәренең, әгәр дә** [аларның гыйддәтенең хөкеме хакында белмәгәнегез өчен] **шикләнсәгез, гыйддәләре, күрем күрмәгәннәрнең гыйддәләре кебек үк, өч ай. Йөкле хатыннарның исә** [гыйддә көтү] **вакытларының ахыры –** [балаларын тудырып] **йөкләреннән котылулары. Кем дә кем Аллаһыдан курка** [һәм Аның хөкемнәрен тиеш булганча тота]**, Ул аның эшләрендә җиңеллек бирә.**
5. **Бу – Аллаһының әмере. Ул аны сезгә иңдерде. Кем дә кем Аллаһыдан курыкса, Ул аларның начар эшләрен каплар һәм әҗерен арттырыр.**
6. [Ий, гыйддәт көткән хатыннар мәсьәләсендә тәкъвалыкны ничек үтәячәкләрен сораучылар!] **Аларны үзегез яшәгән урында көчегезгә карап урнаштырыгыз.** [Алар белән бергә калырга тиеш булмаган кешеләрне яннарына урнаштырып яки әйберләр куеп, урынны тарайту белән] **Аларны кысрыклар** [һәм өйдән чыгып китәргә мәҗбүр итәр] **өчен, аларга зарар китермәгез. Әгәр дә алар йөкле булсалар, алар** [балаларын тудырып] **йөкләреннән котылганчы,** [кирәк булганнар белән тәэмин итеп] **аларга сарыф итегез. Әгәр дә алар** [бала тудырганнан соң] **сезнең өчен** [балаларыгызны] **имезсәләр, аларга хакын түләгез.** [Ий, әниләр һәм әтиләр!] **Арагызда бер-берегезгә яхшы дип беленгән нәрсәне әмер итегез. Әгәр дә** [тиешле түләү бирелмичә яки сөйләшенгәннән артыграк соралып] **бер-берегезгә кыенлык тудырсагыз, ул чакта башка бер хатын аның өчен** [баласын] **имезәчәк.**
7. **Хәлле кеше киң мөмкинлегенә карап сарыф итсен. Кемнеңдер исә ризыгы чамалы булса, ул Аллаһы аңа биргән нәрсәләрдән сарыф итсен. Аллаһы беркемгә дә аңа биргән нәрсәсеннән башканы йөкләми. Аллаһы** [башка төшкән] **кыенлык артыннан җиңеллек яралтачак.**
8. **Раббыңның һәм расүлеңнең әмереннән чыккан ничәмә-ничә мәмләкәт** [халкы] **бар ки, Без аларны** [олы-кече һәр гөнаһлары өчен] **каты хисапка тарттык һәм аларны куркыныч газап белән җәзаладык.**
9. **Алар** [начар] **эшләренең зыянын татыдылар һәм эшләренең ахыры зарар булды.**

10. [Ахирәттә исә] **Аллаһы аларга каты газап әзерләп куйды. Ий, акыл ияләре булган иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз. Аллаһы сезгә зикер** [һәм бик тәэсирле бер үгет булган Коръәнне] **иңдерде.**
11. **Расүлне** [дә (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) җибәрдек] **ки, иман иткәннәр һәм изге гамәлләр кылучылар** [көферлек, адашу] **караңгылыклардан нурга чыксыннар өчен, ул** [пәйгамбәр] **сезгә Аллаһының ап-ачык аятьләрен укый. Кем дә кем Аллаһыга иман итә һәм** [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек] **изге гамәлләр кыла, шуларны Ул** [сарайлары һәм агачлары] **асларыннан елгалар агып торган җәннәтләргә кертәчәк, алар анда мәңге калачак. Аллаһы аларга күркәм ризык бирде.**
12. **Аллаһы – җиде** [кат] **күкне яратучы һәм шуның кадәр үк җирне дә** [бар итүче]**. Аллаһының – һәрнәрсәгә** [көче җиткән] **кодрәтле икәнен һәм Аллаһының гыйлеме белән һәрнәрсәне уратып алганын белүегез өчен, әмер** [каза һәм кадәрдән гыйбарәт булган бар итү һәм идарә итү эше] **алар** [җиде кат күк белән җиде кат җир катлары] **арасында иңеп тора.**[1]

[1] Бу аяте кәримәдә җир күкнең мисалы итеп аңлатылган. Әмма нәрсәнең дә булса башка бер әйбергә охшатылуы һәрьяклап аның белән бериш дигән сүз түгел. Бу охшашлык кайбер сыйфатлар белән генә була ала. Дин галимнәренең күпчелеге фикеренчә, җирнең күккә охшашлыгы – җиде кат булуы, бер-берсе өстендәге катларга ия булуы, һәр ике кат арасында, җир белән күк арасында булганы кебек, биш йөз еллык ара булуы һәм һәрберендә Аллаһының бер төркем мәхлүкълары булган кебек кайбер үзенчәлекләрдә. Ибне Габбас радыяллаһу ганһүмәдә риваять ителгәнчә, җир катлауларында булганнар – йә фәрештәләр, йә җеннәр. Кайбер галимнәрнең җир катлауларын җиде икълим яки мәгъдән катлаулары, яки туфрак катлары кебек мәгънәләрдә аңлатулары имам Әхмәд һәм Тирмизи кебек мәртәбәле галимнәр теркәгән хәдис-шәрифләр белән кисешә, чөнки Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) ике җир каты арасында биш йөз еллык ара барлыгын ачык итеп бәян иткән һәм җиде кат җирне берәм-берәм санаган. Шул сәбәпле, Алуси (рәхимәһуллаһ) фикеренчә, җир катларының бер-берсеннән аерым җиде каты һәм һәрберенең үз мәхлуклары бар дигән карашны кабул итүдә акыл ягыннан да, дин ягыннан да бернинди киртә юк. Бүгенгә кадәр җир катларындагы мәхлүкъларны очратмау моны инкяр итүебезне кирәк кылмый, чөнки иман китергән нәрсәләребезнең күбесе безгә күренми. Аллаһының хакимиятенең киңлегенә һәм кодрәтенең бөеклегенә ышанган кешеләр, күпчелек галимнәр карашынча, җиде кат җирнең барлыгын һич икеләнмичә кабул итәргә тиешләр (Алуси).

## 66. Әт-Тәхрим (Тыю) сүрәсе

Мәдинә чоры, 12 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Ий, Нәби! Ни өчен, хатыннарыңа ярарга тырышып, Аллаһы сиңа хәләл иткән нәрсәне** [үз-үзеңә] **харам кыласың?** [Гәрчә бу синең затыңа гөнаһ булмаса да, югары дәрәҗәңә карата кулайракны кире кагу да гөнаһ кебек саналганлыктан] **Аллаһы –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле.**[1]
2. **Аллаһы сезгә антларыгыздан** [аларны бозган очракта, кәффарәт биреп] **азат булуны билгеләде. Аллаһы –** [бөтен эшләрегез белән идарә иткән] **Яклаучыгыз. Ул –** [һәрнәрсәне] **Белүче, Хикмәт иясе.**
3. **Менә Нәби хатыннарыннан берсенә** [Хәфсага] **сер итеп бер сүз сөйләде, ләкин ул аны** [Гайшәгә] **хәбәр иткәч, Аллаһы аңа моны ачкач, ул** [Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) **аның бер өлешен** [Хәфсага] **белдерде,** [артык оялтмас өчен һәм хәлифәлек турындагы хәбәрнең таралуын теләмәгәне өчен] **бер өлешен яшерде** [шулай итеп, балны үзенә харам иткәне серен сөйләгәнен йөзенә әйтте, ләкин әтисенең хәлифә булачагы серен фаш итүенә кагылмады]**.**

---

[1] Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип белдергән: «Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) татлы ризыкны, бигрәк тә балны, бик ярата иде. Зәйнәб бинте Җәһеш радыяллаһу ганһә янында ара-тирә озаграк калып, бал ширбәте эчә иде. Мин моннан көнләшеп, сердәшем Хәфса белән: «Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) кайсыбызның янына керә, аңа: «Синнән әллә нинди ис килә, әллә берәр исләнгән нәрсә ашадыңмы?» – дип әйтергә сүз куештык». Бер мәртәбә ул Хәфсаның янына кергәч, аңа бу сүзләр әйтелгән чакта, ул хатыннарына ярарга тырышып: «Юк, мин Зәйнәб бинте Җәһеш янында бал ширбәте эчкән идем, ләкин артык эчмәячәкмен дип ант итәм, син моны беркемгә дә сөйләмә. Һәм сиңа шул сөенечле хәбәрне дә ирештерим: миннән соң өммәтемне җитәкләүне – Әбү Бәкер, аңардан соң әтиең Гомәр өстенә алачак», – дигән һәм моны сер итеп саклавын сораган. Ләкин Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) янынnan китәр-китмәс Хәфса радыяллаһу ганһә арабыздагы диварга шакып, миңа моны хәбәр итте һәм беркемгә дә сөйләмәвемне үтенде. Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) үзенә килгән вәхи белән бу хәлне белеп алгач, серенең ачылганына ачуланып, бер ай буена бер генә хатыны янына да кермәде. Менә бу кыйсса хакында сүрәнең башыннан алып биш аяте иңде». Кайбер җаһилләр уйлаганча, монда бер гөнаһ турында сүз алып барылмый, чөнки Аллаһының хәләлен харам кылу ике төрле бәяләнә. Бер хәләлнең харам булганына ышану шәкелендә булса, бу гөнаһтан да үтеп, кешене кяфер итә торган ышану, Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) хакында мондый бер нәрсә уйлау – көферлек. Әмма Аллаһының бер хәләлен ант итү юлы белән үзенә тыю мәгънәсендә кабул ителсә, бу хәтта гөнаһ түгел. Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) дә нәкъ менә шуны эшләгән. Монда бөек дәрәҗәсенә нисбәтле бер кулайрак вариантны кирү кагу һәм тайпылу барлыкка килү турында әйтеп була (Хазин, Алуси, Тәфсире Матуриди).

**Аңа моны хәбәр иткәч, ул** [Хәфса]**: «Кем сиңа моны хәбәр итте?» – диде. Ул: «**[Һәрнәрсәне] **Белүче һәм Хәбәрдар** [булган Аллаһы] **миңа хәбәр итте», – диде.**

4. [Ий, Гайшә һәм Хәфса!] **Әгәр дә икегез** [Пәйгамбәремә карата эшләгән бу эшегездән] **Аллаһыга тәүбә итсәгез** [дөрес юлда булырсыз, чөнки] **күңелләрегез** [хактан] **тайпылды бит. Ләкин аңа каршы икегез бер-берегезгә ярдәм итәсез икән, һичшиксез, аның Яклаучысы – Аллаһы. Моңардан соң Җәбраил,** [Әбү Бәкер һәм Гомәр кебек] **изге мөэминнәр һәм фәрештәләр дә – ярдәмчеләр.**
5. **Әгәр дә ул сезне аерса, Раббысы сезнең урынга аңа сездән дә яхшырак булганнарны,** [Аллаһыга] **бирелгәннәрне, иман китергәннәрне, намаз укыганнарны, тәүбә иткәннәрне, гыйбадәт кылганнарны, ураза тотканнарны тол һәм саф хатыннар итеп бирер.**
6. **Ий, иман китерүчеләр!** [Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып] **Үз-үзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз,** [башка утларның ягулыгы утын булса] **аның ягулыгы** [кяфер] **кешеләр һәм** [бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт] **ташлар. Аның өстендә каты табигатьле һәм көчле фәрештәләр бар. Алар үзләренә әмер ителгән нәрсәләрдә Аллаһыга каршы төшмиләр һәм әмер ителгәнне үтиләр**[1]**.**
7. [Кяферләр җәһәннәмгә ыргытылган вакытта гафу үтенергә маташканда, аларга әйтелер] **«Ий, инкяр итүчеләр! Бүген гафу үтенмәгез. Сез үзегез** [дөньяда] **кылган нәрсәләр белән генә җәзаландырыласыз».**
8. **И, иман китерүчеләр! Аллаһыга ихлас бер тәүбә белән тәүбә итегез. Бәлки, Раббыгыз начар эшләрегезне сезнең кичерер һәм Аллаһы пәйгамбәре** (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) **һәм аның белән бергә иман китергәннәрне рисвай итмәячәк беркөнне сезне асларыннан елгалар агып торган җәннәтләргә кертер.** [Сират күперен үткән чакта] **Аларның нуры алларында һәм уңнарында** [үзләреннән алда] **барачак. Алар** [монафикъларның нурлары сүнгәнен күргәч]**: «И, Раббыбыз! Безгә нурыбызны тулысынча бир**

[1] Әбү Гыймран хәзрәтләреннән риваять ителгәнчә, зобани дип билгеле булган бу фәрештәләрнең саны – унтугыз. Һәрберенең ике кулбашы арасы – йөз еллык ераклык. Күңелләрендә һич кызгану һәм аяу хисе булмаган бу фәрештәләр газап бирү өчен яралтылганнар. Алардан берәрсе җәһәннәм әһеленнән кемгә дә булса берне суккач, аны баш түбәсеннән аяк тырнагына кадәр тартылган он хәленә китерә (Алуси).

**һәм безне ярлыка. Һичшиксез, Син – һәрнәрсәгә** [көче җиткән] **кодрәтлесең», – диячәкләр**[1].

9. **Ий, Нәби! Кяферләргә каршы** [кылыч белән] **һәм монафикъларга каршы** [дәлилгә нигезләнгән бер юл белән] **җиһад кыл. Аларга карата каты бул.** [Ахирәттә исә] **Аларның сыеныр урыннары – җәһәннәм. Ул нинди яман бару урыны!**
10. **Аллаһы Нухның** [галәйһиссәлам] **хатыны белән Лутның** [галәйһиссәлам] **хатынын кяфер булганнар өчен үрнәк итеп китерде. Алар икесе дә колларыбыздан** [Нух һәм Лут [галәйһимәссәләм] кебек] **ике колның никахларында иделәр, ләкин** [иман итмичә] **аларга хыянәт кылдылар. Аларның икесе** [ягъни ирләре] **Аллаһыдан бернәрсә белән дә аларга файдалы була алмадылар. Шулай итеп** [Кыямәт көнендә аларга]**: «**[Җәһәннәмгә] **Керүчеләр белән бергә икегез дә утка керегез!» – диеләчәк.**[2]
11. **Аллаһы иман китерүчеләр өчен фиргавеннең хатынын үрнәк итеп китерә. Менә ул: «Ий, Раббым! Җәннәттәге хозурыңда минем өчен бер өй сал! Мине фиргавеннән һәм аның** [көферлегеннән, Синнән башкага гыйбадәт һәм кешеләрне гаепсез хәлдә җәзалау кебек] **гамәленнән коткар! Залим кешеләрдән дә мине коткар!» – дигән иде.**[3]

---

[1] «Нәсух» сүзе артыклык дәрәҗәсендә, асылда, тәүбә итүчеләрнең сыйфаты булып, образлы рәвештә тәүбәнең дәрәҗәсен белдерә. Шуңа күрә мәгънә – «Тәүбә итәргә теләүчеләрнең үз-үзләренә тәүбә белән үгет биреп, аны тиешенчә үтәүләре». Шулай ук, «нәсух» сүзенә «гөнаһлар сәбәпле, кешенең дини тормышында ачкан ертыкларын ямаган бер тәүбә», «ихлас тәүбә», «тәүбә кылучыда әсәре беленеп торганы өчен, башка кешеләргә дә үрнәк булырлык сыйфатта булган үгетләп торучан тәүбә» кебек егермедән артык төрле-төрле мәгънә бирелгән.

[2] Нух (галәйһиссәлам) хатынының хыянәте – кешеләргә иренең тиле булганын сөйләве, Лут (галәйһиссәлам) хатынының хыянәте исә – өйгә килгән кунаклар турында начар ниятле кавеменә белдерүе. Имам Дәххактан (рәхимәһуллаһ) риваять ителгәнчә, аларның икесенең дә хыянәтләре – Аллаһы Тәгаләнең вәхиләрен мөшрикләргә хәбәр итеп, сүз йөртүләре. Намус ягыннан хыянәт турында сүз бара алмый, чөнки бер генә пәйгамбәрнең дә хатыннары зина кылуга төшмәгәне Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителгән (Алуси).

[3] Риваятьләрдән күренгәнчә, хатыны Асиянең Мусага (галәйһиссәлам) иман китергәнен аңлаган фиргавен, аны җәзалау өчен, чалкан яткырып, кулларын һәм аякларын дүрт казыкка бәйләткән, күкрәгенә зур бер тегермән ташы куйдырган һәм аны кояш астында калдырган. Сакчылар аның янынннан киткәч, фәрештәләр аңа күләгә ясаганнар. Менә шул чакта ул бу аяте кәримәдә телгә алынган догасын кылгач, Аллаһы Тәгалә аңа җәннәттә энҗедән салынган сараен ачып күрсәткән һәм рухын Гыйльлийүнгә күтәреп, аны ул газаптан коткарган. Теге таш рухсыз бер тән өстендә калган. Моннан аңлашылганча, бик авыр вакытларда Аллаһы Тәгаләгә

12. **Гыймран кызы Мәрьямне дә** [радыяллаһу ганһә] Аллаһы мөэминнәр өчен бер үрнәк итте] **ки, ул гаурәт җирен** [һәртөрле җенси якынлыктан] **саклады. Без рухыбыздан аңа өрдек** [һәм Мәрьям радыяллаһу ганһәнең] карынында Гайсәне [галәйһиссәлам] бар иттек]**. Ул** [Мәрьям [радыяллаһу ганһә] **Раббысының** [Идрискә [галәйһиссәлам] һәм бүтән пәйгамбәрләргә иңдергән сәхифәләрдә булган] **сүзләрен һәм** [Тәүрат, Инҗил, Зәбур кебек] **китапларын хак дип тапты һәм гыйбадәт кылучылардан булды.**

### 67. Әл-Мүльк (Хөкемдарлык) сүрәсе

Мәккә чоры, 30 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. **Хөкемдарлык** [кодрәт] **фәрманында булган** [Аллаһы] **бөек, һәм Ул** [һәрнәрсәгә көче җиткән] **кодрәтле.**
2. **Ул, сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты** [сезнең кылачакларыгыз хакында әзәли гыйлемен уртага чыгарачак, соңыннан Үзенең гыйлеменә күрә түгел, кылганнарыгызга күрә әҗерләрегезне бирәчәк]. **Ул – Бөек** [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче.**
3. **Ул катлы-катлы итеп җиде күкне яратты.** [Ий, күрә белгән кеше! Никадәр генә эзләсәң дә, барлыкларын соң дәрәҗәдә кызганган] **Рахман яраткан нәрсәләрдә бернинди кимчелек күрә алмассың.** [Әгәр дә берәр шигең булса, күкләргә] **Тагын бер күз сал, бер-бер бозыклык күрә аласыңмы?**
4. **Шуннан соң тагын ике мәртәбә күзеңне төбәп кара.** [Нәтиҗәдә] **Күз сиңа** [эзләгән бозыклыкны таба алмыйча] **көчсез һәм алҗыган хәлдә кайтыр.**

---

сыену һәм Аңардан котылу сорау – изгеләрнең гадәтеннән һәм пәйгамбәрләрнең сөннәтеннән. Асия радыяллаһу ганһәне мактап телгә алган кайбер хәдис-шәрифләр бар. Мәсәлән, Ибне Габбас радыяллаһу ганһүмәдән риваять ителгән бер хәдис-шәрифтә Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): «Җәннәт әһеле булган хатыннарның иң өстеннәре – Хөвәйлид кызы Хәдичә, Мөхәммәд кызы Фатыйма, Фиргавеннең хатыны Мөзәһим кызы Асия һәм Гыймран кызы Мәрьям. Гайшәнең башка хатыннардан өстенлеге исә тириднең (итле ашның) башка ашамлыклардан өстенлеге шикелле», – дип әйткән (Әхмәд ибне Хәнбәл, әл-Мөснәд, № 2668, 4/409; Бохари, Әнбия: 33, № 3230, 3/1252). Табәранинең Сәгъд бине Җүнадә радыяллаһу ганһедән риваять иткән башка бер хәдис-шәрифтә Расүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): «Җәннәттә Аллаһы мине Гыймран кызы Мәрьямгә, Фиргавеннең хатынына һәм Мусаның (галәйһиссәлам) сеңлесенә өйләндерәчәк», – дип әйткән (Алуси).

5. **Без** [сезгә] **дөнья күген кандилләр** [кебек балкыган йолдызлар] **белән бизәдек. Аларны** [фәрештәләр арасында телгә алынган вәхиләрне ишетергә дип угрылык кылган] **шәйтаннарга атыла торган нәрсәләр иттек һәм аларга** [дөньяда йолдыз кисәкләре белән яндырылуларыннан соң, Ахирәттә] **ялкынлы ут газабы әзерләдек.**
6. [Шәйтаннар булсынмы, җеннәр яки кешеләрдән булсынмы] **Раббыларын инкяр итүчеләр өчен җәһәннәм газабы бар. Ул нинди яман бер бару урыны!**
7. **Алар** [зур бер учак эченә ташланган утыннар кебек] **аның эченә ыргытылган вакытта, аның** [казан кебек] **кайнаганда чыгарган үкерүен ишетерләр** [ул ишәк үкергән тавышны хәтерләтер].
8. **Ул** [җәһәннәм, кяферләргә булган] **ачуыннан шартларга тора. Аның эченә** [кяфер] **бер төркем тотып ташланган саен,** [Малик һәм аның ярдәмчеләреннән торган] **сакчылары алардан: Сезгә** [аятьләрен укыган] **кисәтүче килмәдеме?» – дип сорарлар.**
9. **Алар әйтерләр: «Әйе, безгә кисәтүче килгән иде, тик без аны ялганчы дип санадык һәм аңа: «Аллаһы бернәрсә дә индермәде, сез бит зур бер адашу эчендәсез», – дип әйттек».**
10. **Һәм** [гаепләрен таныр өчен]**: «Әгәр дә без** [кисәтүләрне] **ишеткән яки** [хакыйкатьләрне уйлап] **аңлаган булсак,** [бүген без] **ялкынлы ут әһелләре арасында булмас идек», – дип әйтерләр.**
11. **Шулай итеп, алар гөнаһларын таныдылар. Инде ялкынлы ут әһелләре** [Аллаһының рәхмәтеннән] **ерак булсын!**
12. **Һичшиксез, күрми торып, Раббыларыннан куркучыларга мәгъфирәт һәм зур әҗер бар.**
13. [Ий, кяферләр!] **Сүзләрегезне, теләсәгез, сер итеп саклагыз яки ачып салыгыз** [аерма юк]**. Һичшиксез, Ул күкрәкләрдә булганнарны белә.**
14. **Әллә** [һәрнәрсәне] **Яратучы** [яшеренне дә ачык кебек] **белмиме? Ул –** [колларга] **Мәрхәмәт итүче,** [һәрнәрсәдән] **Хәбәрдар.**[1]
15. **Ул җирне сезгә буйсындырды. Аның җилкәсендә** [тауларында һәм тигезлекләрендә] **йөрегез һәм Аның ризыгыннан ашагыз.**

---

1 Ибне Габбас радыяллаһу ганһүмәдән риваять ителгәнчә, мөшрикләр Расүлуллаһка (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) каршы яшеренеп кенә сөйләшә торган булганнар. Аллаһы Тәгалә ул серләрне Расүлуллаһка (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) хәбәр иткәч, ул әлеге хәбәрләрне аларның йөзләренә бәреп әйтә торган булган, бу исә аларны шаккаттыра торган булган. Саклык чарасы буларак, үзара: «Артык кычкырып сөйләшмик, Мөхәммәднең Раббысы ишетеп, аңа хәбәр итмәсен», – дип сүз куешканнар. Моңа карата шушы аяте кәримә иңгән (Алуси).

**Терелүегез** [һәм кайтуыгыз] **Аңа гына бит.** [Менә шулвакыт сездән бу нигъмәтләр өчен шөкердә булу-булмавыгыз соралачак].

16. **Аллаһы Тәгаләнең** [Карунны йоттырган кебек] **сезне җирдән йоттырмавыннан иминсезме? Шулчак ул** [туфрак сезне эченә алып] **бик каты селкенә.**
17. **Әллә Аллаһы Тәгаләнең өстегезгә ташлар яудыра торган давыл җибәрмәвеннән иминсезме? Кисәтүемнең ниндилеген тиздән беләчәксез.**
18. **Алардан алдагылар да** [пәйгамбәрләре] **ялган** [сөйли] **дип санаганнар иде, ләкин** [шундый көчле булуларына карамастан] **Минем** [аларны] **танымавым нинди булды!**
19. **Өсләрендәге кошларны күрмиләрме әллә? Алар** [канатларын] **бер ачып, бер җыеп очалар.** [Канатларын җәйгән һәм җыйган вакытларында] **Аларны Рахманнан башка беркем дә тотмый.** [Шуның өчен Ул аларны аерым бер шәкелдә яратты һәм аларга һавада оча алырлык хәрәкәтләрне илһам итте. Рәхмәте һәрнәрсәне каплаган Затның мәрхәмәте булмаса, табигатьләре җиргә тартылу булган авыр барлыкларның һава бушлыгында рәхәтләнеп тора алуларын уйлап та булмас иде]. **Һичшиксез, Ул бөтен нәрсәне дә** [бик яхшы] **күрә.**
20. **Рахман булмаса, кем гаскәрегез була ала һәм сезгә ярдәм итә ала соң? Кяферләр бит – бер алдану эчендәләр.**
21. **Сезгә Ул** [корылык бер сәбәп белән] **ризыгын туктатса, кем сезне ризыкландыра алсын? Әйе, алар** [да мондый беркемнең дә булмаганын белсәләр дә, хакка карата] **тәкәбберләнүне һәм** [хактан] **качуны дәвам итәләр.**
22. [Әбү Җәһел кебек] **Йөзтүбән капланып баручымы дөресрәк бара, әллә** [Расүлем кебек] **туры юлдан төп-төз баручымы?**
23. [Расүлем!] **Әйт: «Ул – бар итүче, сезгә ишетү куәте, күзләр һәм йөрәкләр бирүче. Сез бик аз шөкер кыласыз».**
24. [Расүлем!] **Әйт: «Ул сезне җирдә** [нәселләр итеп] **таратучы, сез** [үлеп терелүегездән соң, Кыямәт көнендә] **Аның хозурына тупланачаксыз».**
25. **Алар: «Әгәр чыннан да дөресен сөйлисез икән, ул** [газап турында] **вәгъдә кайчан** [киләчәк] **соң?» – диләр.**
26. **Әйт: «Гыйлем тик Аллаһыда гына. Мин исә** [Аның миңа белдергәннәрен] **аңлатучы кисәтүчемен».**
27. **Ләкин аны** [газапны] **якыннан күргәч, инкяр итүчеләрнең чырай-**

**лары бозылды һәм** [аларга]**: «Сез сораган нәрсә менә бу», – дип әйтеләчәк.**

28. [Расүлем!] **Әйт: «Аллаһы мине һәм минем янымдагыларны** [сезне җиңмичә] **һәлак итсә, яки безгә мәрхәмәт кылса** [да, үлемебездән алда сезнең һәлак булуыгызны безгә күрсәтсә]**, кем соң** [сезнең кебек] **кяферләрне тилмерткеч газаптан коткарачак дип уйлыйсыз?»**
29. [Расүлем! Аларның файдасыз теләкләренә җавап итеп] **Әйт: «Ул** [Аллаһы колларына карата ата-аналарыннан да ныграк кызганган] **мәрхәмәтле, без Аңа иман китердек һәм Аңа тәвәккәл кылдык.** [Ул безне дөнья вә Ахирәт газапларыннан коткарачак]. **Кемнең ап-ачык адашу эчендә булганын** [газапка төшкәннәрне күргәч] **беләчәксез.**
30. **Әйт: «Әгәр суыгыз** [чиләкләр җитә алмаслык чиктә] **тирәнгә китсә, кем сезгә агым су китерәчәк, дип уйлыйсыз?**[1]

1 Риваятьтән күренгәнчә, бу аяте кәримә Ибне Зәкәрия Әл-Мүтәтаййиб исемле бер зиндикъ янында укылгач, ул: «Китмәннәр китерәчәк», – дигән. Шул ук төнне аның күз суы кибеп сукырайган (Нәсәфи).

# Нәсыйхәт

# Үзен күңел төшенкелегендә дип уйлаучылар хакында

Еш кына, бигрәк тә, соңгы елларда күп тапкырлар күңел төшенкелеге сүзен ишетергә туры килә. Тыйб (медицина) галимнәре арасында «күңел төшенкелеге» чирме ул яки юкмы дигән бәхәсләр бар. Ләкин күп очракларда «күңел төшенкелеге» сүзе астында кеше үзенең эшсезлеген, күңел төшенкелеген, һөнәрсез йөрүен яшерә. Бүген сүзем чыннан да табиблар күзәтүе астында торучы, бик каты авырып төрле начар уйлардан иза чигүчеләр, тәрәзәгә карап сәгатьләр буена басып тора алырлык авырулар турында түгел. Аларга профессиональ табиблар ярдәм итәрләр, иншәАллаһ.

Бүген мин хәле җиңелрәк булган кешеләр турында сөйләргә телим. Менә шул кешеләр күп очракта: «Дөнья – авырлык, мәшәкать урыны. Яшәүнең тәме бетте», – дип әйтәләр.

Сөбеханаллаһ! Әгәр Коръәнне ачып карасак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә күз салсак, дөньяның эш урыны булуын, рәхәтләнеп кәеф таба торган урын түгел икәнлеген, изгелекләр эшләргә вакыт җиткәнлеген белербез. Һәм һәрбер мөселман дөнья тормышыннан соң мәңгелек Ахирәт киләчәгенә иманы камил булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي كَبَدٍ ﴿٤﴾

**«Һичшиксез, Без кешене михнәт эчендә яраттык».**

«Әл-Бәләд / Шәһәр», 90:4

Аятьтән аңлашылганча, кешенең тууыннан алып авырлыклар башлана. Адәм баласының шул авырлыкларны чишеп яшәве – олы хикмәт. Карагыз, ана баласын нинди авырлыклар белән дөньяга китерә. Баласы тугач озак та үтми, аның авырлыклары онытылып, ул сөенечкә, шатлыкка күмелә. Аның бит газиз нарасые туган. Шуннан соң бу сабый үсә:

укый, эшкә урнаша, аннары гаилә кора, йорт һәм башка хуҗалык кирәк-яракларын таба. Берсе дә җиңел генә кесәгә керми, тырышлык күрсәтергә кирәк. Менә шуңа күрә Аллаһы Тәгалә кешене авырлыкларда яраттык дип әйтә.

Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا ۚ وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ ﴿٢﴾

**«Ул, сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты [сезнең кылачакларыгыз хакында әзәли гыйлемен уртага чыгарачак, соңыннан Үзенең гыйлеменә күрә түгел, кылганнарыгызга күрә әҗерләрегезне бирәчәк]. Ул – Бөек [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче».**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:2

Сынар өчен дигән сүз – дөньяның сынау, имтихан урыны икәнлеген күрсәтә. Һәм менә шул сынау җиңел булмас, әлбәттә. Сынауны үтәр өчен тырышлык куярга кирәк.

Шулай ук хәдисләрдә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Пәйгамбәрләр иң зур сынауларга очраган Аллаһы коллары», – дип әйтә. Ләкин бик күп сынауларга дучар булсалар да, алар гомерләрен Аллаһы риза булган хәлдә үткәрергә тырыштылар.

Димәк, дөнья җиңел булмас. Җип-җиңел булган булса, без Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрнең тәмен дә сизмәс идек, кадерен белмәс идек. Эшләп тапкан акчаңа да күп тырышлыклар куелса, син аның кадерен күбрәк беләсең. Ләкин әгәр җиңел генә керсә, шулай ук җиңел генә чыгып та китә. Нәкъ менә шуңа күрә күп очракта тумыштан байлыкка күмелеп, гомерендә бер көн дә эшләмәгән кешеләр ахырда бик бәхетсез булалар, гомерләре

бик аяныч тәмамлана, тормышның тәмен югалталар. Кызганыч, күп кенә кешеләр үзләрен күңел төшенкелегендә дип уйлыйлар. Ләкин, чынлыкта, эшсезлектән килеп чыккан сагыш кына борчый аларны.

Бер галим турында болай дип язалар: «Әхмәд остаз кешеләргә ярдәм итәргә бик нык ашыкты. Ул болай дип әйтә иде: «Син кешегә ярдәм иткән саен Аллаһы да сиңа ярдәм итәчәк. Нәкъ менә шул сәбәпле ялкаулар иң бәхетсез, иң кәефсез, иң боек кешеләрдер. Аларның бер сөенечләре, бер шатлыклары юктыр. Һәм аларга капма-каршы як кешеләр – аларга бер дә охшамаган эш ияләре. Нәрсә белән шөгыльләнсәләр дә, алар гел башка төрле булырлар».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә бер хәдисендә болай дип әйтте: «Кем кардәшенә ярдәм итүдә булса, Аллаһы да аңа ярдәм итүдә булыр».

Шуңа күрә әгәр нинди дә булса хәрәкәт белән мәшгуль булсаң, башыңа кәефне төшерә торган фикерләр килмәс.

Халык арасында киң таралган бер кыйсса бар. Ул кыйсса бер карашка көлке булса да, анда бик зур гыйбрәт бар. Бер хатын-кыз елап утыра икән. Ник елыйсың дип сорагач, менә килер бер вакыт һәм мин кияүгә чыгармын. Кияүгә чыккач малай табармын. Ул малай әзрәк үскәч иптәшләре белән су буена барыр. Шунда уйнар һәм суга батып үләр. Шуңа кайгырып елап утырам, дигән. Бу бит күңел төшенкелегенә бирелеп утыруның ачык бер чагылышы. Бер нәрсә эшләмичә утыргач, башка уй-фикерләр килә башлый. Ә без кешеләрнең баш мие шулай ясалган ки, әгәр берәр уй килеп керсә, без аны күпертергә яратабыз. Ахыр чиктә гади генә бер фикер зур кайгыга әверелергә мөмкин. Нәкъ менә теге хатын кебек. Башта кияүгә чыгармын. Аннары бала туар. Бала шундый матур булыр, яратырмын. Аннары үсәр, аннары уйнар да, аннары суга батыр. Менә шул вакытта әгәр без тик утырыр урынга нинди дә эш белән мәшгуль булсак, ул уйларны уйларга вакыт калмас иде. Баш мие башка әйберләр турында уйлар иде. Хәзер инде

күңел төшенкелегән бетерә торган берничә киңәшне бирәсем килә:

1. Аллаһыдан ярдәм сорагыз. Бөтен тормыш авырлыкларында да иң элек сыену урынын Аллаһыдан эзләгез. Ничек кенә булмасын, нинди генә авырлыклар, уй-фикерләр килмәсен, Аллаһы Тәгалә ул авырлыкларны бетерергә кодрәтле.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

... إِنَّهُ لَا يَيْأَسُ مِن رَّوْحِ اللَّهِ إِلَّا الْقَوْمُ الْكَافِرُونَ ﴿٨٧﴾

**«Һичшиксез, [Раббыларының чиксез нигъмәтләрен инкяр иткән] кяферләр кавеме генә Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзә».**

«Йосыф», 12:87

Коръәндә пәйгамбәрләрнең сүзләре дә китерелә. Алар «кайгымны һәм сагышымны бары тик Аллаһыга гына юллыйм», «Күркәм сабырлык күрсәтәм, бәлки Аллаһы улларымның барысын да кайтарыр» диделәр. Бу ике аять Ягъкуб галәйһиссәлам сүзләре иде. Шулай ук Әюб галәйһиссәлам хакында Коръәндә болай дип искә алына:

وَأَيُّوبَ إِذْ نَادَىٰ رَبَّهُ أَنِّي مَسَّنِيَ الضُّرُّ وَأَنتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ ﴿٨٣﴾

**«[Расүлем!] Әюб галәйһиссәламне дә искә ал]! Менә ул [каты чир белән авырып, еллар буена сабыр иткәннән соң, намазга тора алырлык та көч таба алмагач] Раббысына [дога белән] эндәште: «Һичшиксез, миңа бер зарар кагылды. Син исә мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесесең».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:83

2. Күңел дәвасы – намаздыр. Аллаһы Тәгалә безне намазда тынычлык табырга өйрәтте. Намазыбыз безне тынычландыра торган бер дәва булып тора. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اسْتَعِينُوا بِالصَّبْرِ وَالصَّلَاةِ ۚ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الصَّابِرِينَ ﴿١٥٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша [Аллаһы Тәгаләдән] ярдәм сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы сабыр итүчеләр белән».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:153

3. Кешегә файда китерү, изгелектә булу.

Хәдистә әйтелә: «Аллаһыга иң сөекле кешеләр – иң күп файда китерүчеләр. Аллаһыга иң сөекле гамәл – мөселман йөрәгенә сөенеч, шатлык китерә торган гамәл, аның кайгысын бетерә торган гамәл яки аның бурычын түләп бетерү яки аны ашатып ачлыгын бетерү. Миңа бер ай буена мәчеттә игътикяф кылудан да якынрак эш – мөселманның мәшәкатен бетерүдә булган эштер».

4. Килеп чыккан проблемаларны чишүдә хикмәт иясе, гыйлем иясе, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган акыл иясе белән киңәшләшү. Чөнки нәрсә генә әйтсәк тә, ничек кенә заманабыз үзгәрсә, кулыбыздагы айфоннар, андроидлар пәйда булса да, машиналарның гади бензин белән эшли торган гына түгел, ә электр белән йөри торганнары булса да, безнең арабызда килеп чыга торган проблемалар – алар бөтенесе бик борынгы. Вакыт үзгәрә бара, ә безнең проблемалар шул ук кала. Шуңа күрә тәҗрибә туплаган хикмәт ияләре Аллаһының рәхмәте белән чыгу юлларын күрсәтерләр, иншәАллаһ. Һәм инде ахыр сүземдә, әлбәттә, зикерләр – Аллаһыны искә алу, Аллаһыга дога кылу – бөтен кайгы-хәсрәтне бетерә торган дәва булып тора.

Аллаһы Раббыбыз безне бәла-казалардан сакласа иде! Тормышларыбызны күркәм һәм сөенечле кылса иде. Әәмин.

*Сәлимҗан хәзрәт Домнин,*

*Кабан арты мәчете имамы*

# Җәннәт рәвеше һәм җәннәт әһелләре бүлеге

Дөрес иснәд белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул Пәйгамбәребездән: «Җәннәт нидән яратылды?» – дип сораган. Пәйгамбәребез: «Судан», – дип җавап биргән. Без: «Җәннәтнең бинасыннан безгә хәбәр бир», – дидек. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Бер кирпече алтыннан, бер кирпече көмештәндер. Ул җәннәтнең балчыгы бик исле яфәрдән, туфрагы шафрандыр[1], вак ташлары энҗе һәм якут ташыдыр. Ул җәннәткә кергән кеше нигъмәтләнер һәм курыкмас, анда мәңге калыр – үлмәс, аның киемнәре искермәс, яшьлеге фани булмас». Моннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Өч кешенең догасы кайтарылмас, ягъни кабул булыр. Болар – гадел патша, ураза тотучының ифтар вакытында кылган догасы, золым ителгән кешенең догасыдыр, чөнки ул золым кылынган кешенең догасы болыттан югары күтәрелер, ул догага Аллаһы карар һәм: «Үземнең җәләлем һәм олуглыгым белән ант итәм, әй золым кылынган бәндәм, әлбәттә, сиңа, гәрчә бераз заманнан соң булса да, ярдәм бирермен», – дип әйтер.

Факыйһ үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребездән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Җәннәттә агач булыр, атка менгән кеше ул агачның күләгәсендә йөз ел йөрер, аны йөреп бетермәс. Әгәр теләсәгез әлеге аятьне укыгыз:

وَظِلٍّ مَّمْدُودٍ ﴿٣٠﴾

**«[Ат белән баручы йөз елда да үтә алмаслык] Сузылган күләгә».**

«Әл-Вакыйга», 56:30

---

[1] Ризыкка төс бирә торган тәмләткеч.

Җәннәттә күз күрмәгән, колак та ишетмәгән һәм күңелләргә кермәгән нәрсәләр булыр. Әгәр теләсәгез, бу аятьне укыгыз:

فَلَا تَعْلَمُ نَفْسٌ مَّا أُخْفِيَ لَهُم مِّن قُرَّةِ أَعْيُنٍ جَزَاءً بِمَا كَانُوا يَعْمَلُونَ ﴿١٧﴾

**«[Дөньяда] Кылган [хәерле] эшләре өчен, күзләргә куаныч [китерүгә сәбәп] булачак нәрсәләрнең алар өчен яшерелгәнен һичкем [хәтта иң олуг фәрештәләр дә, пәйгамбәрләр дә] белми».**

«Әс-Сәҗдә», 32:17

Җәннәттә булган бер камчы урын – бөтен дөньядан һәм анда булган нәрсәдән изгерәк. Әгәр теләсәгез, бу аятьне укыгыз:

فَمَن زُحْزِحَ عَنِ النَّارِ وَأُدْخِلَ الْجَنَّةَ فَقَدْ فَازَ ۗ

**«Кем дә кем Уттан ераклаштырыла һәм җәннәткә кертелә, һичшиксез, ул котылган булыр».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:185

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул болай дип әйткән: «Дөреслектә, җәннәттә хурлар булыр. Алар дүрт нәрсәдән: яфәрдән, анбәрдән, кәфурдан һәм зәгъфраннан[1] яратылдылар. Һәм аның балчыгы тереклек суы белән язылып оештырылган. Аллаһы Тәгалә аларга: «Бул!» диде һәм алар булды. Хурларга барчасы гашыйк булырлар. Әгәр ул хур кызы диңгезгә бер төкерсә, бөтен диңгез татлы суга әйләнер иде. Күкрәгенә: «Берәү минем шикелле хурны теләсә, Раббымның тәгате белән гамәл кылсын», – дип язылган булыр.

Мөҗәһид радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Җәннәтнең җире көмештәндер һәм ул җәннәтнең туфрагы яфәрдер. Җәннәт агачларының тамырлары көмештер. Ул агачларның ботаклары энҗе һәм зөбәрҗәттер.

[1] Тәмләткечләр.

Яфраклары һәм җимешләре бу ботаклар астындадыр. Әгәр бер кеше басып ашаса, бу агачны рәнҗетмәс, утырып ашаса да, аны рәнҗетмәс, ятып ашаса да, аны рәнҗетмәс». Моннан соң Мөҗәһид радыяллаһу ганһе бу аятьне укыды:

ظِلَالُهَا وَذُلِّلَتْ قُطُوفُهَا تَذْلِيلًا

**«Җимешләре дә [сузылып алуы җиңел ителеп] тулысынча буйсындырылган».**

«Әл-Инсан / Кеше», 76:14

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Ул болай дип әйткән: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Коръәнне иңдергән Зат белән ант итеп әйтәм, дөреслектә, җәннәт әһеле гүзәллекне һәм матурлыкны алар дөньяда картлыкны арттырган кебек арттырырлар».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Сөһәеб радыяллаһу ганһедән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр җәннәт әһеле – җәннәткә һәм ут әһеле утка керсә, бер тавыш ишетелер: «Әй, җәннәт әһеле, дөреслектә, сезнең өчен Аллаһы каршында вәгъдә кылынган урын әзердер. Аны күрергә телисезме?» Алар: «Ул нәрсә? Әллә безнең үлчәнгән гамәлләребез авыр булмадымы? Әллә йөзләребез агармадымы? Әллә җәннәткә кертелмәдекме, уттан чыгарылмадыкмы?» – дип әйтерләр. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Пәрдә ачылыр һәм алар Аллаһы Тәгаләгә карарлар. Минем нәфесем Аның кулында булган Зат белән ант итәм, аларга Аллаһы Тәгаләгә караудан сөеклерәк булган бернәрсә булмас».

Әнәс бине Мәлик болай дип риваять итә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Җәбраил галәйһиссәлам кара нокталы ак көзге китерде. Пәйгамбәребез аннан: «Әй, Җәбраил, бу ак көзге нәрсә?» – дип сорады. Җәбраил галәйһиссәлам: «Бу (көзге) – җомга, ә кара нокта җомгада каим була торган, ягъни анда хасил була торган вакыт. Дөреслектә, ул җомга

көне хөрмәтенә син һәм синең кавемең, сезгә кадәр булган кешеләргә караганда, артык кылынды. Ул җомга көнендә адәмнәр – сезгә иярүчеләр, ягъни яһүд белән насара халкы, җомгада була торган шул сәгатне тели һәм максат итәдер. Аллаһы Тәгаләдән хәерлелек тели торган мөэмин ул вакытка туры килсә, Аллаһы Тәгалә ул мөэминнең догасын кабул итәр. Явызлыктан сыгынды исә, Аллаһы Тәгалә ул бәндәне начарлыктан саклар. Җәбраил галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Ул җомга безнең каршыбызда арттыру көнедер. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Арттыру көне нәрсә ул?» – дип сорады. Җәбраил галәйһиссәлам: «Дөреслектә, синең Раббың Фирдәвес җәннәтендә «Уйсу» дип аталган җирне барлыкка китерде. Ул җирдә яфәрдән булган кечкенә таулар булыр. Җомга көне җитсә, нурдан булган ул минбәрләрдә пәйгамбәрләр утырыр. Янә якут һәм зөбәрҗәт белән тукылган минбәрләр булыр. Ул минбәрләр өстендә сиддыйклар, шәһитләр һәм изгеләр булыр. Чарлаклы[1] кешеләр чарлакларыннан иңәрләр, минбәр ияләре артындагы кечкенә таулар өстенә утырырлар. Аллаһы Тәгалә өчен җыелырлар һәм Аллаһыны мактарлар, Аның өчен хәмед-сәна әйтерләр. Аллаһы Тәгалә аларга: «Миннән сорагыз», – дип әйтер. Алар: «Синең ризалыгыңны сорыйбыз», – дип әйтер. Аллаһы Тәгалә: «Дөреслектә, сездән разый булдым, Минем ризалыгым сезне Минем йортыма кертте, сезгә кәрамәтемне[2] таптырды». Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларга пәйда булыр, хәтта алар Аллаһы Тәгаләне күрерләр. Аларга кәрамәттән арттырган өчен, җомга көненнән сөеклерәк башка көн булмас.

Икенче хәбәрдә янә риваять ителде, Аллаһы Тәгалә Үзенең фәрештәләренә әйтер: «Миңа якын кешеләрне ризыкландырыгыз. Ашамлыкның төрлесен китерегез, һәрбер кисәктә икенче кисәктәге ләззәттән башка ләззәтне табарлар. Әгәр ашаудан бушансалар, Аллаһы Тәгалә әйтер: «Минем колларыма эчертегез». Эчемлекләрне китерерләр,

1 Чардак.

2 Намус, хөрмәт.

һәр сулыш, тын алганда икенчесеннән аерым ләззәт табарлар. Һәркайчан бушансалар, Аллаһы Тәгалә әйтер: «Мин сезнең Раббыгыз. Дөреслектә, сезгә яхшы вәгъдәмне дөрес кылдым. Миннән сорагыз, әгәр сорасагыз – бирермен». Әйтерләр: «Әй Аллаһыбыз! Синнән ризалыгыңны сорыйбыз». Ике яки өч мәртәбә әйтерләр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Дөреслектә, сездән разый булдым, Минем каршымда бу көн артыграктыр. Сезне боларның бөтенесеннән зуррак булган кәрамәт белән хөрмәтләрмен». Шуннан соң пәрдә ачылыр һәм алар Аллаһы теләгән кадәр аңа карарлар, Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кылган хәлдә егылырлар. Һәм Аллаһы Тәгалә теләгән кадәр сәҗдәдә булырлар. Моннан соң Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Башларыгызны күтәрегез, бу гыйбадәт урыны түгел. Аллаһы Тәгаләне күргәнче бирелгән барлык нигъмәтләрне онытырлар. Бу карау аларга бөтен нигъмәтләргә караганда сөеклерәк булыр. Моннан соң кайтырлар һәм ак яфәрдән булган таулар өстенә Гареш астыннан җил исәр. Бу мускус аларның башларына, янә аларның атларының маңгай чәчләренә куелыр, ягъни таратылыр. Әгәр үзләренең әһелләренә кайтсалар, хатыннары аларны матурлыкта һәм күркәмлектә артыграк итеп күрер. Аларга хатыннары әйтер: «Дөреслектә, сез киткән вакыттагыга караганда матуррак булып кайткансыз».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Пәрдә күтәрелү»нең мәгънәсе, ягъни аларга булган, аларны Аллаһы Тәгаләгә караудан каплый торган пәрдә. Әмма «Аңа карарлар» дигән сүз, кайбер имамнар әйтүенчә: «Моңа кадәр күрмәгән кәраматкә карарлар», – дигәнне аңлата. Яшерен гыйлем ияләренең күбесе: «Аңарга карарлар» дигән сүзне: «Тышкы тарафтан Аллаһы Тәгаләне күрерләр һәм Аллаһы Тәгаләне дөньядагы һичбер нәрсәгә һәм һичкемгә охшашлы итеп тапмаслар», – диделәр.

Гакрәмә болай дип әйткән: «Җәннәт әһеленең ирләре дә, хатыннары да утыз өч яшьлек кебек, буйлары аталары Адәм галәйһиссәламнең буе кебек – алтмыш аршын. Сакалсыз, мыексыз егетләрдер, күзләре сөрмәле.

Алар өчен җитмеш хөллә[1] булыр, һәрбер хөлләнең төсе һәр сәгатьтә җитмеш төскә үзгәрер. Үзләренең йөзләрен аның йөзендә, ягъни үзенең хатыны йөзендә, күкрәгендә һәм хатынның балтырында күрерләр. Ул хатын йөзен иренең йөзендә, күкрәгендә һәм балтырында күрер. Җәннәттә алар төкермәсләр, сеңгермәсләр һәм ул җәннәт кешесе рәнҗүдән, моннан өстен булганнардан ерактыр».

Хәбәрдә риваять ителде. Дөреслектә, җәннәт әһеленнән булган бер хатын күктән очкын чыгарса, җир һәм күк арасында булган нәрсәне яктыртыр иде.

Факыйһ үзенең иснәде белән Зәед бине Әркамнән риваять итә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә китап әһеленнән бер ир килде һәм: «Әй, Әбү Касыйм, җәннәт кешеләре ашарлар һәм эчәрләр дип уйлыйсыңмы?» – дип сорады. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөрес, ашарлар да, эчәрләр дә, үзем аның кулында булган Зат белән ант итәм, дөреслектә, җәннәт әһеленең берсенә ашауда, эчүдә һәм женси мөнәсәбәт кылуда йөз ирнең куәте бирелер». Китап әһеле: «Дөреслектә, ашаган һәм эчкән кеше өчен хаҗәт булыр, әмма җәннәт пакьтер, анда рәнҗү юк», – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аларның берсенең хаҗәте тирдер, ул тир яфәр исе кебек булыр».

Факыйһ радыяллаһу ганһе үзенең иснәде белән Могътәб бине Сәмийдән Аллаһының сүзләрен риваять итә:

طُوبَىٰ لَهُمْ وَحُسْنُ مَآبٍ﴿٢٩﴾

**«Иман китергән һәм изге гамәлләр кылган кешеләргә – сөенеч һәм күркәм кайту урыны».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:29

[1] Кием.

Ул болай дип әйтте: «Тубә – җәннәттәге бер агачтыр». Җәннәттә йорт булмады, мәгәр ул йортны күләгәләр һәм ул тубә агачының ботакларыннан булган бер ботакта төрле җимешләр булыр. Ул тубә агачына дөя муеннары кебек кош төшәр. Әгәр җәннәт әһеленең берсе ул кошны теләсә, аны чакырыр. Ул кош кешенең җәймәсенә төшәр һәм кеше аның бер тарафыннан кисәкләгән хәлдә, икенче тарафтан кыздырылган хәлдә ашар, моннан соң ул янә кошка әверелеп очып китәр».

Әгъмәш Әбү Салихтан, ул Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Минем өммәтемнән булган җәннәткә керүчеләрнең беренче төркеме ундүртенче кичтәге ай төсендә булыр, ә алардан соң ук керүчеләрнең төсе иң якты йолдыз кебек булыр. Моннан соң аларга мәнзилләр (урыннар) булыр. Анда алар бәвел кылмаслар, бәдрәфкә бармаслар, ягъни йомышларын үтәмәсләр, төкермәсләр һәм какырмаслар. Аларның тараклары алтындыр, аларның хуш ис чыгару өчен булган күмер савытлары үлүүвәтдер[1], ягъни гуд агачыдыр. Аларның тирләре яфәрдер һәм аларның яратылышлары бер ирнең яратылышы кебектер, буйлары аталары Адәм галәйһиссәламнеке кебек, алтмыш аршын булыр».

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителә: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, җәннәт кешеләре сакалсыз, мыексыз егетләрдер. Аларда йон булмас, мәгәр башында, ике каштa, ике күзнең керфекләрендә генә булыр. Аларның касык һәм култык астында йоннары булмас, алар Адәм галәйһиссәламнең озынлыгында – алтмыш аршын булырлар. Һәм Гайсә бине Мәрьям яшендә, ягъни утыз өч яшьтә булырлар. Төсләре ак, киемнәре яшелдер. Үзенең ике кулы арасына маидәне (ашъяулык) куяр, аңа кош килер һәм: «Әй, Аллаһының дусты, аң бул, мин сәлсәбил чишмәсеннән эчтем, Гареш астында булган җәннәт бакчаларыннан һәм җимешләрдән ашадым», –

1 Үлүүвәт – пыскып янганда хуш ис чыгара торган агач төре.

дип әйтер. Кош итенең ике тарафының берсе пешерелгән, икенче тарафы кыздырылган булыр. Һәм ул коштан теләгән кадәр ашарлар. Ул Аллаһының дусты өстендә җитмеш хөлләдер, һәрберсе үзенең төсе белән аерылып торыр. Аларның бармакларында ун йөзек булыр. Беренче йөзектә: «Түзгәнегез өчен сезгә сәлам», – дип, икенче йөзектә: «Ул җәннәткә тыныч булган хәлдә, сәламәтлек белән керегез», – дип, өченче йөзектә: «Бу җәннәт сезгә кылганыгыз өчен мирас ителде», – дип, дүртенче йөзектә: «Сездән көенечләр һәм кайгылар күтәрелде», – дип, бишенче йөзектә: «Сезгә зиннәтләрне һәм киемнәрне кидердек», – дип, алтынчы йөзектә: «Сезгә хурул-гыйнны өйләндердек», – дип, җиденче йөзектә: «Ул җәннәттә сезнең өчен нәфесләр теләгән һәм күзләр ләззәтләнә торган нәрсәләр. Сез ул җәннәттә мәңгегә калырсыз», – дип язылган. Сигезенче йөзектә: «Сез пәйгамбәрләргә һәм сиддыйкларга охшашлы булдыгыз», – дип, тугызынчы йөзектә: «Картаймый торган егетләр булып әверелдегез», – дип, унынчы йөзектә: «Шул кешенең күршесендә күршеләрне рәнҗетмичә тордыгыз», – дип язылган булыр.

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Берәү бу кәрамәтләргә ирешүне теләсә, аңа биш нәрсәне даими кылу лязем булсын.

Беренчесе: бөтен гөнаһлардан үзен тыю. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَأَمَّا مَنْ خَافَ مَقَامَ رَبِّهِ وَنَهَى النَّفْسَ عَنِ الْهَوَىٰ ﴿٤٠﴾ الْجَنَّةَ هِيَ الْمَأْوَىٰ ﴿٤١﴾

**«Кем исә Раббысының хозурында басып торудан курка һәм [бертуктаусыз начарлыкка әмер иткән] нәфесен начар теләкләрдән тыя. Һичшиксез, [мондый кеше өчен] сыеныр урын җәннәт [булыр]».**

«Ән-Нәзигәт / Йолкып алучылар», 79:40-41

Икенчесе: дөньяда аз булганына нәрсәгә разый булу, чөнки хәбәрдә болай дип риваять ителде: «Дөреслектә, җәннәткә бу дөньяны ташлаучы ирешәчәк».

Өченчесе: һәр итагатькә сакчыл булу, һәр итагатькә ябышу. Шаять, итагатьтә тырышлык күрсәтүчегә җәннәт вәҗиб булыр. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

وَتِلْكَ الْجَنَّةُ الَّتِي أُورِثْتُمُوهَا بِمَا كُنتُمْ تَعْمَلُونَ ﴿٧٢﴾

**«Бу җәннәт сезгә кылган нәрсәләрегез сәбәпле мирас ителде».**

«Әз-Зүхруф / Зиннәтләнү», 43:72

Икенче аятьтә болай дип әйтелә:

جَزَاءً بِمَا كَانُوا يَعْمَلُونَ ﴿١٤﴾

**«... кылганнары өчен әҗер итеп...»**

«Әл-Әхкаф / Ком таулары», 46:14

Ирешкән нәрсәләргә итагатьләрдә тырышу белән ирешәләр.

Дүртенчесе: изгеләрне һәм изгелек ияләрен сөю, аларга катышу, алар белән утыру, чөнки аларның берсе Аллаһы тарафыннан ярлыканса, ул иптәшләренә һәм кардәшләренә шәфәгать кылыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять кылынганча, дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Кардәшләрне күбәйтегез, чөнки һәр кардәш өчен Кыямәт көнендә шәфәгать булыр».

Бишенчесе: доганы күп кылу, Аллаһы Тәгаләдән җәннәт белән ризыкландыруын һәм ахыргы сулышыбызны иман белән үтүне сорау.

Акыл ияләренең кайберләре болай дип әйткән: «Дөньяга ышану, саваплы булган нәрсәнең күренеп торган вакытында дөньяны ярату – наданлыктыр. Дөреслектә, җәннәт – ул ләззәт. Ул ләззәткә итагать белән мәшәкатьләнгән кеше генә ирешер. Хакыйкатьтә, җәннәт – ул байлык.

Ул байлыкка бу дөньяда авырлыклар күрмәгән кеше ия булмас. Бары тик дөньяның ләззәтләрен ташлаган кеше генә җәннәткә ия булыр».

Заһидлардан булган берәү икмәктән башка ясмык һәм тоз гына ашый иде. Аңа бер ир: «Нигә син үзеңне яхшырак ризык ашаудан мәхрүм итәсең?» – дип әйтте. Ул заһид болай дип әйткән: «Мин Раббыма итагать итәр өчен ашыйм һәм җәннәткә өметләнәм. Ә син, алар тирескә әйләнсен өчен яхшы ризык ашыйсың».

Ибраһим бине Әдһәм радыяллаһу ганһедән хәбәр ителә. Дөреслектә, ул мунчага керергә теләде һәм аны мунча хуҗасы керүдән тыеп: «Кермәссең, мәгәр түләү белән генә керерсең», – дип әйтте. Ибраһим бине Әдһәм елап, болай дип әйтте: «Әй, Аллаһым, миңа түләмичә шәйтаннар йортына керергә рөхсәт бирелми. Ничек минем өчен, пәйгамбәрләр һәм сиддыйклар йортына акчасыз, хаксыз керү булыр?»

Болай дип хәбәр ителгән: Пәйгамбәрләрнең берсенә Аллаһы Тәгаләдән әлеге сүзләр индерелгән: «Әй, Адәм улы, тәмугны олуг акчага сатып аласың, әмма җәннәтне аз акчага да сатып алмыйсың». Моның тәфсире: әгәр бозык кеше үзе кебек бозыкларны кунак итәргә теләсә, күп вакытта ул йөзне яки ике йөзне (акчаны) сарыф итә һәм аңа бу җиңел була. Шул рәвешле, күп акча сарыф итеп, тәмугны ала. Әгәр ул, авырлыкларга карамыйча, Аллаһы ризалыгы өчен, бер яки ике дирһәм (көмеш тәңкә) тотып, мохтаҗларның кайберсен кунак итсә, ул, әлбәттә, җәннәткә лаек булыр.

Әбү Хәзимнән риваять ителә. Ул болай дип әйткән: «Дөреслектә, әгәр кеше дөнья ләззәтләрен калдырса, аңа җәннәткә керү җиңел булыр».

Яхъя бине Могаз Әр-Рази болай дип әйткән: «Дөнья нигъмәтләреннән баш тарту авыр, җәннәттән баш тарту аннан да кыенрак. Дөреслектә, җәннәтнең мәһәре – ул дөньяны ташлау».

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять ителә, ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән тапшырган. Дөреслек-

тә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бер кеше Аллаһы Тәгаләдән өч мәртәбә җәннәтне сораса, җәннәт: «Әй Аллаһым, ул бәндәне җәннәткә керт», – дип әйтер. Әгәр бер кеше өч мәртәбә җәһәннәмнән котылуны теләсә, җәһәннәм: «Әй, Аллаһы, ул бәндәне җәһәннәмнән коткар», – дип әйтер. Без Аллаһыдан безне уттан коткаруны һәм җәннәткә кертүне сорыйбыз.

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Җәннәттә базарлар бар. Анда сату да, алу да булмас. Ул базарларда табын-табын җәннәт әһелләре җыелыр. Алар дөньяның ничек булганы, Аллаһы Тәгаләгә үзләренең ничек гыйбадәт кылганнарын, дөнья әһеленең фәкыйрьләрен һәм байларын, үлем нинди булганын һәм җәннәткә ничек ирешкәннәрен искә алып сөйләшерләр».

Безгә ышанычлы кеше үзенең иснәде белән Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһедән хәбәр бирде. Дөреслектә, ул болай дип әйткән: «Кешеләрнең барысы Сират күперенә килерләр, тәмуг тирәсендә торырлар. Моннан соң үзләренең гамәлләре хисабынча Сираттан үтәрләр. Араларыннан кайберләре яшен кебек янә икенчеләре җил кебек, башкалары кош кебек, кайберләре ат кебек үтәр. Янә алар җөмләсеннән яхшы дөя кебек, аккан су кебек, җәяүле кебек үткәннәре булыр. Һәм аларның иң соңгысы аягының ике баш бармагында үтә торганыдыр. Моннан соң ул ирне Сират күпереннән төшерми үткәрерләр. Сират – аяк тая торган урындыр. Ул Сиратның үткенлеге кылыч үткенлеге кебек, аның хозурында тигәнәк чәнечкесе кебек чәнечкеләр булыр. Ул Сиратның ике тарафында фәрештәләр торыр, аларда уттан булган кисәүләр булыр. Ул кисәүләр белән кешеләрне алырлар. Алар арасында юлны үтүче һәм котылучылар булыр, бары тик тырналган һәм котылган кешеләр булыр һәм шулай ук утка егылганнары булыр. Соңгы кеше күпердән үткәндә фәрештәләр: «Әй, Аллаһым, сәламәт ит, сәламәт ит», – дип әйтерләр. Һәм ул кеше күпердән

үтәр. Аннары аңа лаек булган җәннәтнең ишеге ачылыр. Ул җәннәттә үзе өчен әзерләнгән урынны күрмәс һәм җәннәткә карап: «Әй, Аллаһым, бу урынга мине иңдер», – дип әйтер. Шунда аңа Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Әгәр сине бу урынга иңдерсәм, шаять, син ул урыннан башканы сорарсың». Ул ир болай дип әйтер: «Олуглыгың белән ант итәм, юк, сорамам». Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аны ул урынга иңдерер. Моннан соң Аллаһы Тәгалә аны җәннәтнең дүртенче баскычына кадәр күтәрер. Монда һәрнәрсә җыелыр һәм әзерләнер. Һәм ул тик торыр, бернәрсә дә сорамас. Аллаһы Тәгалә аңа әйтер: «Миннән берәр нәрсә сорарга телисеңме?» Ул: «Сорадым, хәтта оялып калдым», – дип әйтер. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Синең өчен дөньяга охшашлы һәм дөньяның ун өлеше кадәр булган бу урын – җәннәт әһеленең иң түбән урыныдыр».

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм моны сөйләми торган иде, мәгәр сөйләде исә – көләр, хәтта аның азау тешләре күренер иде».

Хәбәрдә зикер ителде. Дөнья әһеленең хатыннары җәннәткә кертелсә, дөньяда булган гамәлләре өчен хур кызларына караганда артыграк булырлар. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّا أَنشَأْنَاهُنَّ إِنشَاءً ﴿٣٥﴾ فَجَعَلْنَاهُنَّ أَبْكَارًا ﴿٣٦﴾ عُرُبًا أَتْرَابًا ﴿٣٧﴾ لِّأَصْحَابِ الْيَمِينِ ﴿٣٨﴾

**«Без аларны [бер ата-анадан туу турында сүз дә күтәрмичә] юктан бар итү белән барлыкка китердек. Аларны [алар белән никадәр генә якынлык кылынса да] гыйффәтле иттек. [Ирләренә] Гашыйк булган [сөйкемле, назлы һәм барысы да утыз өч яшьлек] яшьтәшләр».**

«Әл-Вакыйга», 56:35-38

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан*

# Адәм баласының биш сыйфаты

Адәм баласын Яратучысыннан яхшырак белүче юк. Әйе, безне бу дөньяга яраткан Раббыбыз безнең хакта барысын да белә. Хәтта без белмәгән якларыбыздан, сыйфатларыбыздан да Ул хәбәрдар. Гаҗәп, әмма кеше гомер буе да үзен тулысынча өйрәнеп бетермәскә мөмкин. Бары тик Раббыбыз гына безнең барлык кимчелекләребезне, зәгыйфь якларыбызны белә һәм шуңа да безнең өчен кайбер нәрсәләрне әмер итә, ә кайберләреннән тыя. Кем ул адәм баласы? Ул нинди сыйфатларга ия? Кеше үзе хакында каян белә ала? Бу сорауларга җавапны Изге Китабыбыздан табарга тырышыйк.

1. Адәм баласы зәгыйфь итеп яратылган

**“...кеше [шәһвәтле тойгыларга каршы] зәгыйфь буларак яратылган”.**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:28

Без зәгыйфь халәттә бу дөньяга киләбез һәм шул ук халәттә бакыйлыкка күчәбез. Әмма бу очракта зәгыйфьлек тәнгә генә кагылмый. Кеше рухи яктан да зәгыйфьлеккә дучар. Шуңа да ул Раббысына сыенырга, Ислам дине нуры астында яшәргә тиеш. Дога, зикер, гыйбадәт, һәрдаим шөкер кылу һәм гөнаһлардан, хата-кимчелекләрдән ерак булу кешене ныгыта, бу дөньяның авырлыкларына каршы торырга ярдәм итә.

2. Адәм баласы ашыгучан итеп яратылган

**“Кеше ашыгучан итеп яратылган. [Болай итеп ашыгу, аның табигатенең аерылмас бер төсен алган...”.**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:37

Еш кына ашыгу, сабырсызлану адәм баласына зыян сала. Ул шул рәвешле хаталар җибәрергә мөмкин. Дөнья дип, гамәл-гыйбадәтләребездә, бигрәк тә намазыбызны укыганда ашыгу да моңа керә. Вакыйгаларны ашыктырып, сабырсызлык күрсәтүебез дә Раббыбызга тәвәккәл итүебезгә

комачау итә. Юкка гына өлкәннәр: “Сабыр төбе сары алтын”, – дип әйтмәгән. Сүз дә юк, ашыктырырга кирәк булган гамәлләр дә бар. Мәсәлән, намазны вакыты кергәч тә укырга тырышу. Шуңа күрә әлеге сыйфатыбызны белеп, аны дөрес итеп куллана алсак иде.

3. Адәм баласы сабырсыз итеп яратылган

**“Һичшиксез, кеше сабырсыз буларак яратылган”.**

«Әл-Мәгариҗ / Баскычлар», 70:19

Бу сыйфат югарыда искә алынган “ашыгучан” сыйфатыбыз белән тәңгәл. Әмма бу очракта сабырсыз булуны тагын бер ягыбыз белән чагыштырырбыз. Адәм баласы еш кына авырлык килгәндә сабырлык күрсәтми, шул рәвешле үзенә зыян сала һәм Раббысының рәхмәтеннән ерагая. Бу урында Раббыбызның әлеге аятен дә искә алып үтик:

**“Ий иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша [Аллаһы Тәгаләдән] ярдәм сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы сабыр итүчеләр белән”.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:153

Димәк, сабыр итүчеләрне Аллаһы Үз ярдәменнән, рәхмәтеннән мәхрүм итми. Бу аятьтә безгә нинди хәлдә булсак та аннан чыгу юлы барлыгы хакында әйтелгән – ул сабырлык һәм намаз белән Раббыбыздан ярдәм сорау. Моннан чыгып, сабырсыз булуның безгә берничек тә ярдәм итә алмавын аңлыйбыз.

4. Адәм баласы шөкерсез итеп яратылган

**“...Һичшиксез, кеше – Раббысына шөкер кылмаучы”.**

«Ән-Нәср / Ярдәм», 100:6

Кешенең чираттагы сыйфаты – ул аның шөкер кыла белмәве. Әйе, адәм баласы авыр вакытта сабырлык күрсәтә белмәгән кебек, рәхәт вакытта шөкер дә әйтә белми. Расүлебез: «Кем иртә белән иминлектә, саулыкта, бер көнлек ризыгы булган халәттә йокыдан уянса, ул җир йөзенең бөтен

байлыгына ия кеше кебек булыр»[1], – дигән Бу хәдисне барыбыз да белсә дә, күпләр аңа тиешле игътибар бирми. Галимнәр адәм баласының рәхәткә сабыр итә алмаганын ассызыклаган. Шөкер кыла белмәүгә икенче яктан да карарга кирәк. Без шөкерне бар яктан да җитеш булганда гына түгел, ә гомумән, нинди хәлдә дә кылырга тиеш, чөнки нинди кыен вакытларда да шөкер итәр өчен сәбәпләр бар һәм Раббыбыз берәүгә дә күтәрә алмаслык йөк йөкләми. Ул: "**...шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә [нигъмәтләрне тагын да] арттырачакмын**", – дип әйткән.

«Ибраһим», 14:7

5. Адәм баласы онытучан итеп яратылган

**"Кешегә [авыру һәм фәкыйрьлек кебек] бер яманлык кагылса, янтыкка яткан килеш, утырып яки аягөсте Безгә ялвара. Әмма Без аңардан ул бәлане алгач, үзенә кагылган бәла турында Безгә һич дога кылмаган кебек [тәкәббер хәлендә булуын] дәвам итә".**

«Юныс», 10:12

Бу сыйфат та шөкерсез булу белән тәңгәл. Кеше, кызганычка, Раббысының биргән нигъмәтләре хакында бик тиз оныта, әмма килеп туган кыенлыкларга бик тиз канәгатьсезлек белдерә һәм үзенә бирелгән нигъмәтләрне онытканлыгы аркасында шөкерсезлек белдереп, гафләттә яши башлый. Биредә адәм балаларының Коръәндә килгән кайбер сыйфатлары гына искә алынды. Кызганычка, кешегә тәкәбберлек, көнчелек, башкалар турында начар уйлау, гайбәт сөйләү, яла ягу һәм башка бик күп начар гадәтләр дә хас була ала. Еш кына кеше алардан котыла алмаска да мөмкин. Әмма ул бу сыйфатларны белеп, үзенең хата-кимчелекләрен төзәтергә тырышып яшәсә, һичшиксез, уңышка ирешәчәк. Раббыбыз безнең көчле рухлы, сабыр, шөкер итүчән, күркәм холыклы булып яшәүләребезне насыйп итсә иде.

*Айсылу Юлдашева*

[1] Имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

# Әдәби сәхифә

# Расүлебезнең тормышыннан сабак алырлык гыйбрәтле кыйссалар

## Күркәм холык нәтиҗәсе

Бу хәл пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдә ислам динен тарата башлаган чорда була. Иман китермәгән олы яшьтәге бер әби базарда шактый күп әйберләр сатып алып көч-хәл белән өенә кайтып барганда, аңа күркәм кыяфәтле бер ир кеше дәшә һәм үзенең ярдәмен тәкъдим итә. Карчык бу тәкъдимне сөенеп кабул итә һәм алга таба алар юлны инде бергәләп дәвам итә. Әйтергә кирәк, бу вакытта мәккәлеләр ике капма-каршы төркемгә бүленгән була: Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөйләгәннәрен кабул итүчеләр һәм кабул итмәүчеләр. Икенче төркем тарафдары булган карчык аңа ярдәм итеп барган яшь иргә зар-интизарын белдерә башлый:

– Өемә кадәр әле шактый ерак – бераз сөйләшеп алсак та була. Шәһәрдәге хәлләрдән хәбәрдәрдер бит? Габдулла улы Мөхәммәд исемле кеше үз фикерләрен тарата башлагач, тормыш әллә нишләп китте бит әле: безнең бабаларыбыз динен кире кага, янәсе, гыйбадәткә бер Аллаһ кына лаек, фәкать Аңа гына буйсынасы, Аны гына зурлыйсы! Ә без гомер буе табынган илаһлар дөрес түгел, имеш! Менә сиңа мә! Тапкан нәрсә сөйләргә! Тыныч яшәдек моңарчы, ә хәзер?

Шулай сөйләнә-сөйләнә, әби Габдулла улы Мөхәммәдне тиргәп-әрләп, аның хакында бик начар, мыскыллы сүзләр әйтеп, юл буе дулап кайтты. Аны озата баручы ир исә дәшмичә тыңлап кына барды. Үз йорты янына килеп җиткәч, карчык аңа ярдәм иткән иргә дәшеп, ахыргы нәсыйхәтен бирде:

– Син, улым, мин әйткәннәрне онытма: шул Мөхәммәд атлы кешене тыңлама, аңа берүк иярә күрмә! Аңладыңмы? Ярый, улым, мин кайтып җиттем, зур рәхмәт сиңа! Бу шәһәрдә безнең кебек өлкәннәргә ярдәм

итәм дип атлыгып тормыйлар шул... Бөтенесе үзен генә кайгырта... Ә син – менә нинди ярдәмчел, олы күңелле кеше булып чыктың! Үзең кем буласың соң, исемең ничек?

Әбине озата барган ир аның әйберләрен капка янындагы эскәмиягә куеп, елмаеп җибәрә дә, башын аска иеп, әкрен генә тавыш белән әйтә:

– Габдулла улы Мөхәммәд мин...

Шушы исемне ишетүгә, әби сискәнеп куя, аннары каушаудан калтырап, дерелдәгән тавыш белән сорый:

– Ничек?... Исемең ничек дисең??...

– Габулла улы Мөхәммәд! – дип инде ышанычлы тавыш белән кабатлый яшь ир.

Әллә оялудан, әллә бик нык дулкынланудан карчык үзе дә сизмәстән тезләнә һәм ике кулын да күккә таба күтәреп, кычкырып куя:

– Шәһадәт бирәм ки, юк илаһ Аллаһтан башка һәм шәһадәт бирәм ки, Мөхәммәд Габдулла улы Аның колы һәм илчесе!!!

Шулай итеп, мөселманнарга, аларның пәйгамбәренә тискәре, хәтта агрессив мөнәсәбәттә булган кеше ислам динен кабул итә. Моның сәбәбе, әлбәттә, пәйгамбәребезнең күркәм холкы. Шулай ук бу кыйссадан тагын шундый сабаклар да алырга мөмкин:

– Әби Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм турында гайбәткә, имеш-мимешләргә нигезләнеп фикер йөрткән, шуңа күрә аның турында начар фикердә булган. Безгә моннан сабак алып, беркайчан да фактларны тикшермичә, кеше сүзенә генә ышанып кемдер яки нәрсәдер турында нәтиҗә ясарга ярамый.

– Әгәр кемдер безгә йөзебезгә бәреп начар, авыр сүз әйтсә, сабыр булып калырга кирәк. Шушы тасвирланган хәлдә Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әбинең әрләү, мыскыллау сүзләренә түзмичә, аңа тупас итеп җавап биргән булса, ул, әлбәттә, ислам динен кабул итмәс иде.

## Өметкә хакы бар

Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сахәбәләре белән урамнан барганда юл кырыенда яткан бер исереккә юлыга. Сахәбәләр бу шыксыз бәндәне күрүгә, җирәнүдән башларын читкә борып, тизрәк үтеп китмәкче булалар, әмма Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм кинәт туктап кала. Җирдә йоклап яткан ирнең чуалып беткән чәчләре, килбәтсез тырпаеп торган сакалы, пычранып беткән ертык киеме һәм бик ямьсез, хәтта куркыныч ачылып калган авызы чыннан да ифрат кызганыч, рухи мәгънәдә бик авыр халәтне чагылдыра иде.

Бераз вакыт тынлыкта узды. Сахәбәләр шул кеше өчен оялудан нишләргә, нәрсә әйтергә дә белмичә: «Нәрсә дияр инде рәсүлебез? Әй әләгәчәк инде хәзер бу адәм актыгына...» – дип уйлап куярга өлгерми, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм юлдашларын шаккатырып болай ди:

– Карагыз әле, бу кешенең тешләре нинди матур!

Шуннан соң пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм башын аска иеп бераз уйланып тора да, борылып юлын дәвам итә. Хәйран калган сахәбәләр исә «Мәә шәә Аллаһ! Сүбехәнәллаһ!» – дия-дия аның артыннан юнәләләр.

Шулай итеп Аллаһның илчесе сахәбәләргә үзенчәлекле дәрес бирә: бик күп начар сыйфатларга ия булган кешедә дә ниндидер яхшы сыйфаты була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең начарлык арасында шул яхшы якны күреп ала белүе бик түбән дәрәҗәгә төшкән бәндәнең дә ӨМЕТКӘ, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕККӘ, ИГЕЛЕКЛЕ МӨГАМӘЛӘГӘ, БӘХЕТКӘ ХАКЫ БАР булуын күрсәтте. Өметсез шайтан гына. Ә кешедә – ул нинди хәлдә булуга карамастан – гел өмет бар. Бу Адәм балаларына булган Аллаһның олуг РӘХМӘТЕ.

## Синеке дә дөрес

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәдән Мәдинәгә күченеп килүе Мәдинә шәһәре халкы өчен зур бәйрәмгә әверелде: барысы ихлас шатланды, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылды, рәсүл әкрамның Мәдинәгә күченүен ансарлар аларга ирешкән Аллаһның олуг рәхмәте булуын яхшы аңлый иде. Әмма Адәм балаларының холык-табигатьләре төрле булу сәбәпле, шушы гомум сөенечле көннәрдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә «мәрхәбә» тойгыларын гына түгел, салкынчарак мөнәсәбәт белдерүчеләр дә була.

Көннәрдән бер көнне Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм сахәбәләре белән бергә утырганда, аның янына килгән бер ансар, киң елмаеп әйтә:

– Безгә күченеп килүегез бик әйбәт булган, чөнки безнең шәһәрдә олы күңелле, инсафлы, бик яхшы кешеләр яши. Әлхәмдүлилләһ!

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә ихлас елмаеп, аңа болай җавап бирә:

– Сүзең хак. Дөрестән дә, бу шәһәрдә бик яхшы кешеләр яши!

Күпмедер вакыт узгач, шул ук урынга икенче кеше килеп керә. Йөзен кара болыт каплагандай, сүрән чырайлы бу бәндә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә канәгатьсез, төксе итеп карап болай ди:

– Безгә күченеп килүегез бер дә әйбәт булмаган. Беләсегез килсә, бу шәһәрдә бик начар кешеләр яши.

Сахәбәләр Аллаһ рәсүле бу кешенең сүзенә ничек җавап бирер икән дип эчтән генә уйлап, тын калдылар. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә ирен читләре белән елмаеп, кыска гына бер җөмлә әйтте:

– Синеке дә дөрес.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шушы ике кеше белән сөйләшүеннән хәйран калган сахәбәләр аптырап болай диләр:

– Йә рәсүлүллаһ! Ни өчен шәһәребездә яхшы кешеләр яши дигән кардәшебезгә җавап биргән кебек, шәһәрдә начар кешеләр яши диючегә дә «сүзең дөрес» дип җавап бирдең?

– Моның хикмәте бик гади, – диде Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. – Кеше күңелендә нәрсә йөртә – шуны табачак. Әгәр кешеләр турында яхшы уйлыйсың икән, алар сиңа яхшы булып күренәчәк, ә инде башкалар турында начар фикердә булсаң, алар да синең өчен начар булачак...

Мөбарәк хәдисләрнең берсендә шундый бер хәл риваять ителә. Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сахәбәләр белән мәчеттә утырганда аларга әйтә: «Хәзер монда керәчәк кеше – Җәннәт әһеле». Шуннан соң мәчеткә бер кеше килеп керә дә алар барысы бергә намаз укый. Намаздан соң кайтканда, сахәбәләр бу кешедән: «Җәннәткә кертерлек нинди гамәлең бар?» – дип сорыйлар. Теге кеше башта аптырап кала, соңыннан исә әйтә: «Әллә ни артык гамәлем юк. Шуны гына әйтә алам: мин кешеләр турында начар сөйләгәнем генә түгел, хәтта начар уйлаганым да юк».

Менә шулай, җәмәгать! Башкалар турында начар уйламыйча яхшы фикердә булсаң, күңелең гел тыныч, йөзен нурлы, әйләнә-тирә якты, дөнья матур, ә тормыш бәхетле булып тоелыр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә моны үзенең күркәм үрнәгендә бик яхшы аңлатты.

## Виноград[1]

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу гәләйһи вә сәлләмне яраткан, бик тә хөрмәт иткән мөселманнар ничек тә аның күңелен күрергә, нинди дә булса яхшылык эшләргә тырышалар иде. Бер көнне Аллаһның рәсүле сахәбәләре белән бергә утырганда, аның янына фәкыйрь кыяфәтле бер

[1] Виноград – йөзем җимеше (ред.).

ир килә. Кулында бер савыт виноград тотып торган бу бәндә пәйгамбәрне күргәч, ничектер оялып, каушап кала, һәм килүенең максатын аңлатып:

– Әй рәсүлүллаһ! Сиңа берәр игелек эшләргә теләдем, шуңа күрә менә шушы виноградны күчтәнәч итеп алып килдем. Рәхим итеп кабул кылчы! – дип әйтә дә, калтыраган кулы белән савытны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм алдына куя.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм баш ишарәсе илә рәхмәтен белдереп, бер виноград җимешен ашап куя да, елмаеп җибәрә. Шуны күргән ир дә елмая башлый. Соңыннан Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче җимешне ашый, аннан соң өченчесен, дүртенчесен, һәм һәр җимешне йоткан саен аның йөзен нурлы елмаю яктырта иде. Шулай итеп, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бөтен виноградны ашап бетереп, савытын кире тапшыра, ә теге ир шатлыгын йөрәгенә сыйдыра алмыйча, бөтен әйләнә-тирәне бәхетле йөзе белән яктыртып, кайтып китә. Әмма сахәбәләр бу хәлгә бик аптырап калалар, чөнки башка вакытта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә нинди генә ризык алып килсәләр дә, ул һәрвакытта иптәшләре белән бүлешә иде. Ә бу юлы бирелгән күчтәнәчне беркемгә дә тәкъдим итмичә, үзе генә ашады… Сахәбәләрнең берсе соңрак моның сәбәбен сорагач, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай җавап бирде:

– Бу ир кеше алып килгән виноград бик әче булып чыкты. Әгәр мин сезнең белән бүлешкән булсам, арагыздан берегез бу хакта әйтеп, виноградны алып килгән кардәшебезнең күңелен төшерер иде. Ә болай ул өенә бик шатланып кайтып китте…

## Гаҗәеп көрәш

Мәгълүм булганча, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә шәһәрендә туып үскән. Пәйгамбәрлекнең беренче 13 еллык чоры да шул шәһәрдә үтә. Әлеге вакыт аралыгында Пәйгамбәребез

салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бик күп авырлыклар кичерергә туры килә: аңа иярүчеләр булса да, мөшрик булган халыкның күпчелеге аның дәгъватына колак салмый, алай гына да түгел – ачулана, тирги, мыскыллы сүзләр әйтә, кайберләре исә яный, хәтта төрле начарлыклар эшли. Әмма мөшрикләр аңа шундый рәхимсез, явыз мөгамәлә күрсәтүгә карамастан, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм барлык кыенлыкларны сабырлык белән кичереп, үзенә хас булган шәфкатьлелеген югалтмый.

Исламга өнди башлауга инде 10 ел тулган көннәрдә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән кызыклы да, гыйбрәтле дә бер хәл була. Дәгъват эшләре буенча ул Мәккә шәһәре чикләрен узып бер авылга юнәлгән чакта аның каршысына Мәккәнең мәшһүр көрәшчесе, алагаем авыр гәүдәле Рукан исемле баһадир очрый. Бу кеше Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәккәлеләргә сөйләгәннәрен аңламый һәм шуңа күрә аны яратмый иде, шул сәбәпле өндәү-нәсыйхәтләрен дә гел кире кага иде. Шәһәрнең күренекле шәхесен очраткач, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа сәлам бирә һәм әйтә:

– Рукан, синең белән бераз сөйләшеп алырга мөмкинме?

Баһадир исә, сәләм кайтарып та тормыйча, кавемдәшенә горур карап, болай ди:

– Сөйләшербез, ләкин башта минем белән көрәшеп кара!

Аңлашыла ки, инде 50 яшен тутырган өлкән кешегә яшь, типсә тимер өзәрлек, моңарчы беркем дә җиңә алмаган көчле көрәшче белән бил алышу мәгънәсез гамәл кебек... Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм фикере белән Раббысына мөрәҗәгать иткәннән соң, Руканның күзенә туры карап, әйтә:

– Яхшы, көрәшик. Ләкин башта җиңүчегә тиешле нәрсә булачагын килешик.

Ярышны оттырган кеше җиңүчегә бер сарык бирергә тиешлеген сөйләшкәннән соң, ике көндәш көрәшә башлый. Бер минут та узмый,

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Руканны егып аркасына сала. Нәрсә булганын аңлап та бетермәгән ир җиңелүен танырга мәҗбүр була, әмма моның ялгыш кына килеп чыккан очраклылык булуын әйтеп, тагын бер тапкыр көрәшеп карарга тәкъдим итә.

– Яхшы, ә бу юлы җиңүчегә бүләккә нәрсә була? – дип сораган пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Рукан янә «сарык» дип җавап бирә.

Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гайрәтен арттырамы, әллә тәкәббер көрәшчене зәгыйфьләндерәме — безгә мәгълүм түгел, шулай да, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яңадан өстен чыгып җиңә. Аннары тагын берничә мәртәбә көрәшеп карыйлар һәм кабат-кабат җиңелгәннән соң, хәйран калган Рукан әйтә:

– Әй Мөхәммәд, гаҗәпләндердең... Моңарчы мине берәү дә калак сөягенә әйләндереп сала алмады... ә син... Гаҗә-әп...

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә нурлы күз карашы илә елмаеп, болай ди:

– Әй Рукан, әйдә мин сиңа моннан да гаҗәебрәк булган бер нәрсә күрсәтәм! Күрәсеңме теге агачны?

Рукан күрсәтелгән тарафка борылгач, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм күркәм, әмма ышыныччлы, нык тавыш белән боера:

– Әй агач! Аллаһ ризалыгы өчен кил минем яныма!

Шул ук мизгелдә куе ботаклы карт агач як-якка авыша-авыша селкенә башлый һәм тамырлары белән бергә җирдән аерылып, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә таба юнәлә. Моны карап торучы Рукан күзләрен зур итеп түгәрәкләп, авызын ачып шаккатып телсез кала. Агач исә Аллаһ рәсүле янына килеп җиткәч, бераз иелә дә итагатьле туктап кала. Шуннан соң, Мөхәммәд пәйгамбәр әмер биргәч, агач үз урынына барып, ничек элек торган – шулай урнаша.

Таң калган Рукан ни әйтергә дә белмичә бермәл сүзсез басып тора. Соңыннан тезләнеп пәйгамбәрне салләллаһу галәйһи вә сәлләм кулларыннан тотып ала да, кычкырып җибәрә:

– Шәһадәт бирәм ки, Аллаһтан башка илаһ юк!!! Һәм шәһадәт бирәм ки, син – Аллаһның илчесе!!!

Әлеге кыйссадан шуны аңлап була: пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм башкаларга хакыйкатьне җиткергәндә, аның каршыда булган әңгәмәдәшнең холкын, сәләтен, дәрәҗәсен исәпкә алып аралашырга тырышкан, ул аңлый торган телдә сөйләшкән. Җиңүчегә тиешле сарыкларны да ул, әлбәттә, алмый: әлеге шарт дөнья мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүче, мин-минлек сыйфатына ия булган көрәшченең күңеленә керү, аны кызыктыру ысулы буларак кына әйтелә... Ә инде иң мөһиме – башкаларны дингә, иманга өндәгәндә сөекле пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ихлас Аллаһка тәвәккәлләп, йомшак сүзе, хикмәтле гамәле ярдәмендә кешенең акылына гына түгел, йөрәгенә дә тәэсир иткән.

*Ришат хәзрәт Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире,*

*«Яшәеш сабаклары» китабыннан*